«Алабуга муниципаль районының  34 нче «Салават күпере» балалар бакчасы»
мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия - белем бирү муниципаль оешмасы.

# Дәү әбидә кунакта.



**Балаларның танып-белү эшчәнлеген һәм әхлак – патриотик сыйфатларын үстерүдә музей педагогикасының роле.**

«Үткәнен белмәгән, милли тәрбия алмаган кешенең киләчәге юк» ди күренекле мәгрифәтче Шиһабетдин Мәрҗәни. Халкыбызның тарыхын белү, аңлау, гореф-гадәтләрен, телен-динен хөрмәт итү, милләт өчен борчылу, аның җыр-моңнарын күңел аша кичерү бала зиһенен баета, күңел офыгын киңәйтә. Без шуңа күрә әби-бабаларыбызның мәгънәле тормышын күрсәткән шөгыльләрен, һөнәрләрен, гореф-гадәтләрен балаларның күңеленә кечкенәдән салып калдырырга кирәк диеп саныйбыз.

Без борынгы һәм тарихка бай шәһәрдә яшибез. Бакчага йөрүче нәниләр өчен гомергә Алабуга туып-үскән шәһәрләре булып калачак. Сабыйлар киләчәктә аның данын арттыручы, туган халкына лаеклы шәхесләр булып үссеннәр өчен алар күңеленә тәрбия орлыкларын бүген үк, ягъни кечкенәдән салырга кирәк. Шәһәребез тарихи урыннарга һәм музейларга бик бай, ләкин мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән “тарих белән күзгә-күз очрашуларны”,кызганычка каршы, бакчадан читтә оештыруы читен. Шуңа күрә без үзебезнең “Салават күпере” балалар бакчасында Туган якны өйрәнү музеен оештырдык. Ул рәсми рәвештә 1998нче елда ачылды һәм 1999нчы елда теркәлеп, Мәктәп музее таныклыгы алды. Музеебыз- шәһәрдәге балалар бакчалары музейлары арасында рәсми рәвештә теркәлү узган бердәнбер музей. Аның төп юнәлеше: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны милли мәдәният белән таныштыру аша аларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, әхлак һәм зәвык тәрбиясе бирү,

Яңа социаль икътисади шартлар балаларда милли аң һәм үзаң тәрбияләү, нәниләрне үз халкының тарихы, традицияләре, мәдәнияте белән таныштыру бурычын куя. Балалар иң беренче чиратта, үзе яши торган төбәкнең табигате һәм аның үзенчәлекләрен, шулай ук туган халкының үзенә генә хас гореф-гадәтләрен, сәнгатен, әдәбиятын , мәдәниятен аеруча яхшы белергә тиешләр. Тәрбия эше «үз туган халкының мәдәниятеннән – бергә яшәүче халык , ә

аннары – дөнья культурасына» дигән методологик принципка нигезләнеп алып барабыз..

Бүгенге көндә музей фондында экспонатларнын гомуми саны 265, төп фонд 252, ярдәмче фонд 13. Экспонатлар арасында көнкүреш әйберләре, эш кораллары , бизәнү әйберләре, китаплар , акчалар , Идел буе халык киемнәре һәм бүләкләр бар. Алар барсы да тапшыру- кабул итү актлары буенча кабул ителәләр һәм  төп исәпкә алу китабында теркәләләр. Музей бүлмәсе өч өлешкә бүленгән : өй, мәдрәсә, экспонатлар күргәзмәсе. Экспонатлар республикабызның төрле районнарыннан җыелган, ул районнар музейга эленгән Татарстан  картасына билгеләнеп барыла. Иң күп әйберләр Алабуга, Мамадыш, Менделеев,  Мөслим, Сарман Чистай районнарыннан алып киленгән һәм шулай ук  Башкортстан республикасыннан .

Безнең балалар гади музейга гына килмиләр , ә әбигә кунакка баралар, чөнки өйдә алар өчен кадерле, һәрвакыт аларны көтеп торучы Кеше – әбиләре  ягьни дәү әниләре яши.  Ул балаларны яшь үзенчәлегенә карап татар халкының авыз иҗаты  белән таныштыра, көнкүреш турында сөйли, уеннарын уйната һәм һәрвакыт тәмле күчтәнәчләре белән сыйлый, шул ук вакытта халыкка хас әдәп кагыйдәләрен аңлата, төрле яклы тәрбия- үсеш бирә.

Тотырыклы шәхес тәрбияләү – ул балаларда башка милләт кешеләренә , аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыру дигән сүз. Без нәниләрдә үз халкыбызга  , туган ягыбызга , илебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән генә чикләнмичә, аларны шәһәребеэдә яшәүче башка милләт халыкларын да яратырга өйрәтәбез. Үз мәдәниятләре белән беррәттән балалар күрше халыкларның да мәдәниятен белергә тиешләр. Бу эштә безгә музей фондының Идел буе халыклары киемнәре бүлеге экспонатлары һәм бакчабызның рус теленә өйрәтү тәрбиячеләре ярдәм итәләр. Бакчабызның педагоглар советы көче белән музеебызның 5 елга перспектив эш планы, перспектив планга таянып экспозицион – тематик план , һәм һәр уку елына эш планы төзелде. Перспектив план төп программа «Балалар бакчаларында тәрбия һәм укыту программасы»на (төзүчеләре К.В.Закирова , Р.Ә.Борһанова ) һәм

Р.Ә.Борһанованың «Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру программасы»на таянып төзелде. Планга таянып кечкенәләр төркеме балалары айга 1 тапкыр музеебызга экскурсияга киләләр.Ә уртанчылар төркеменнән башлап балалар атнага 1 тапкыр шөгыль-экскурсиягә йөриләр.Нәниләр экспонатларның гадиләре, аларның атамалары белән танышалар. Ә зурлар төркемендә аларның эзлеклелеге күрсәтелә: мәсәлән чабата- галуш – чүәк – читек – туфли; кер үтекләү өчен сырлы таяк - чуеннан ясалган күмер үтүге – электр үтүге . Музейда шулай ук комплексы шөгыльләр үткәрелә: сөйләм телен үстерү һәм музыка, әйләнә -тирә белән танышу һәм рәсем, әвәләү яки кисеп ябыштыру һәм башкалар. Бу юнәлештә алып барылган чаралар балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерүгә зур ярдәм итә.Үз эшебезне педагогиканың төп принципларына таянып алып барабыз:

-музей экспонатлары белән танышуда эзлеклелек (гадидән – катлаулыга)

-экскурсияләрнең вакытын саклау (баланың игьтибарын күз алдында тотып)

-күрсәтмәлелек

-материалның аңлаешлы булуы

-эчтәлеклелек ( материал тәрбияви юнәлештә булуы)

- экспонатлар сакчыл караш тәрбияләргә тиеш.

-тарихилык ( үткәнне һәм булачак тормыш турында күзаллауны үстерү)

Балалар әбинең ишек алдында татар халык уеннарын уйныйлар, төрле бәйрәмнәр үткәрәләр. Мәсәлән: «Карга боткасы», «Яңгыр боткасы», «Җир бәйрәме», «Йомырка бәйрәме», «Боз озату» бәйрәмнәре безнең бакчада гадәти гә әверелде.. Балалар музейда үткәрелә торган һәр чарада да актив катнашалар, мәктәпкә әзерлек төркеме экскурсоводлары, бакча һәм һәттә бакчага килгән кунаклар өчен үзләре экскурсияләр үткәрәләр. Бала үзен Кеше итеп тойсын өчен анарда милли горурлык тәрбияләргә кирәк.Милли тәрбия алган бала гына үз милләтенә, теленә, тарыхына, мәдәниятенә ихтирамлы була. Бу максатларны тормышка ашыруда тәрбия – белем бирү процессында милли һәм җирле төбәк өлешләрен куллану ярдәм итә һәм бакча музеебыз бу эштә

безгә зур терәк.  Планлы һәм системалы рәвештә үткәрелгән бу  чаралар , тәрбия- белем бирү процессында уңай нәтижәләргә китерде:

- балаларның эшчәнлеген интеграцияләштерде.
- балаларның  тирә-юньгә карашларын үстерде.
- балалар эшчәнлеген активлаштырды.
- җиһазлар тарихы белән таныштыру аша , балаларның буыннар тәҗрибәсе турындагы белемнәре тулыланды.
- педагогик эшчәнлектә яңа алым – чаралар барлыкка килде .

Туган ил, туган җир, туган төбәк, туган шәһәр, туган авыл… Һәркемнең күңел кылларын тирбәтүче иң изге  төшенчәләр алар. Милләтпәрвәрлек хисләре тәрбияләүдә без шушы мөмкинлекләрдән файдаланмасак, гонаһ булыр.


**Тәрбия – укыту процессында төп чаралар.**



**Ата – аналар белән  эш төрләре.**



## Педагогик кадрлар белән эш



## ТЕМАТИК – ЭКСПОЗИЦИОН ПЛАН.

| Тема. | Экспозиция эчтәлеге. | Күрсәтү формасы. | Экспозиция урыны. |
|---|---|---|---|
| 1.Алабугам – ак калам. | Алабуга шәһәре тарихы матбугатта, китапларда, открыткаларда, буклетларда. | Китаплар, открыткалар, буклетлар, газета-журналлар. | Өстәл – витринада. |
| 2.Күңел җәүһәрләребез. | Хезмәткәрләрнең кул эшләре. | Чигүләр, ыргак белән бәйләүләр, сөлгеләр, | Өстәл-витринада, күчмә ширмада. |
| 3.Казан сөлгеләре. | Сөлгеләр тарихы. | Сөлгеләр. | Күчмә ширмада. |
| 4.Әбиемнең савыт – сабалары. | Көнкүрештә кулланылган һәм кулланыла торган савыт-сабалар,алар ни өчен кирәк һәм алар белән нәрсә эшлиләр? | Самовар,чынаяк тәлинкәсе, чынаяк,шикәр савыты, чәйнек,тәлинкәләр, кружка, чүлмәк,таба,чокыр, аш чүмече, чәй савыты,графин. | Өстәл – витринада. |
| 5.Әби – бабамның эш кораллары. | Көнкүрештә кулланылган һәм кулланыла торган эш кораллары,алар ни өчен кирәк һәм алар белән нәрсә эшлиләр? | Гөбе,сырлы бәләк,пычкы,урак, иттарткыч,үлчәүләр, герүтүк, орчык,балта,кыргыч эрләү станогы, ләгән,табагач,иләк. | Өстәл – витринада. |

## ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕНДА БАЛАЛАР БЕЛӘН ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАРНЫҢ ПЕРСПЕКТИВ ПЛАНЫ.

| № п/п | Вакыты. | Чаралар. | Төре. |
|---|---|---|---|
| | | 1 нче кечкенәләр төркеме. | |
| 1 .<br>2.<br>3. | 1 квартал<br>2 квартал<br>3 квартал. | Хуш киләсез,оланнар.<br>Әкияттә кунакта.<br>Дәү әбидә кунакта. | экскурсия<br>шөгыль,күңел ачу<br>сәхнәләштерү |
| | | 2 нче кечкенәләр төркеме. | |
| 1. | сентябрь. | Хуш киләсез,оланнар. | экскурсия. |
| 2. | октябрь | Әлли-бәлли бәү итә. | сөйләм үстерү шөгыле |
| 3. | ноябрь | Әбиемнең серле сандыгы. | экскурсия |
| 4. | декабрь<br>январь | Табышмаклар сандыгы. | сөйләм устерү шөгыле |
| 5. | февраль<br>март | Без тату гаилә. | экскурсия |
| 6. | апрель<br>май | Сиңа бабам бүләге. | экскурсия, әвәләү,рәсем шөгыльләре. |
| | | Уртанчылар төркеме. | |
| 1. | сентябрь | Дәү әбигә бүләккә. | экскурсия |
| 2. | октябрь | Табын тулы сый./көзге муллык/ | комплекслы шөгыль |
| 3. | ноябрь | Әкияттә кунакта. | сәхнәләштерү |
| 4. | декабрь | Кышның көмеш бизәге. | сынлы сәнгать шөгыле |
| 5. | январь | Хуш киләсең,Нардуган! | күңел ачу кичәсе |
| 6. | февраль | Дәү әтием медале. | экскурсия,сөйләм устерү шөгыле. |
| 7. | март. | Алтын куллы әнием. | күргәзмә, бәйге. |
| 8. | апрель | Без әкият яратабыз./Г.Тукай туган көненә/ | комплекслы шөгыль яки сәхнәләштерү |
| 9. | май. | Дуслык бәйрәме. | күңел ачу кичәсе. |
| | | Өлкәннәр төркеме. | |
| 1. | август | Котлы булсын туган көнең! | экскурсия. |
| 2. | сентябрь | Әкият иленә сәяхәт./А.Алиш әкиятләре/ | комплекслы шөгыль яки сәхнәләштерү |
| 3. | октябрь<br>1 атна | Әбием-дәү әнием.<br>Алтын башак | комплекслы шөгыль<br>күңел ачу кичәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2 атна<br>3 атна | Әкият иленә сәяхәт<br>Кич утырып җырлар җырлыйк. | музыка шөгыле |
| 4. | ноябрь | Каз канаты каурый-каурый. | күңел ачу кичәсе |
| 5. | январь | Тылсымлы кыш.<br><br>Әкияттә кунакта. | комплекслы шөгыль<br>сәхнәләштерү |
| 6. | февраль | Оста куллы әтием.<br>Мин-нәни Чапай. | күргәзмә<br>шигырь кичәсе |
| 7. | март | Әбиемнең күнел сандыгы.<br>Алтын куллы әнием. | экскурсия.<br>күргәзмә. |
| 8. | апрель | Күңелле соң бәйрәмнәр.<br>Карга боткасы.<br>Кулга оста,телгә оста.<br>/Г.Тукай шигырьләре/ | күңел ачу.<br>бәйрәм кичәсе.<br>шигырь кичәсе. |
| 9. | май. | Дәү әтинең кадерле бүләге. | комплекслы шөгыль,<br>экскурсия. |

| Мәктәпкә әзерлек төркеме. | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | август. | Үз илем-алтын бишек. | экскурсия |
| 2. | сентябрь<br>2 атна<br>3атна | Алабугам туган төбәгем.<br><br>Без Алишны яратабыз.<br>Хуш киләсең,Сөмбелә! | сөйләм устерү шөгыле<br>шигырь кичәсе<br>ата-аналар белән күңел ачу кичәсе. |
| 3. | октябрь<br>3атна<br><br>4атна | Алтын башак үскән кырларым.<br>Дәү әбинең серле төенчеге./яшелчә-җимешләр белән/<br>Тәгәри китте йомгагым./Әкиятләр/ | комплексլы шөгыль<br>сынлы сәнгать шөгыле.<br><br>сәхнәләштерү |
| 4. | ноябрь<br><br>3 атна<br>4 атна | Каз канаты каурый-каурый,хатлар язарга ярый./Каз өмәсе/<br>Эш беткәч уйнарга ярый.<br>Без әкият яратабыз. | ата-аналар белзн күңел ачу кичәсе<br><br>уен эшчәнлеге.<br>сәхнәләштерү шөгыль |
| 5. | декабрь<br>2 атна<br><br>3атна | Тәңкә-тәңкә кар ява.<br>Кич утырып әкият тыңлыйк.<br><br>Мөселман бәйрәмнәре. | рәсем шөгыле<br>матур әдәбият белән танышу шөгыле<br>күңел ачу кичәсе. |
| 6. | январь<br>2 атна<br>3 атна | Табышмаклар иленә сәяхәт.<br>И аулак өй,аулак өй!<br>Тылсымлы кәгазь бите. | викторина<br>күңел ачу кичәсе<br>рәсем яки кисеп ябыштыру шогыле. |
| 7. | февраль<br>2 атна<br>3атна | Оста кулдан эш курка.<br>Әбемнең күңел сандыгы.<br>Әкият иленә сәяхәт. | күргәзмә ,бәйге<br>экскурсия<br>сөйләм устерү шогыле |
| 8. | март<br>2 атна<br>3 атна | Әниемнең күңел бизәге.<br>Уйныйбыз да,җырлыйбыз да.<br>Кәләпүшем-калфагым. | рәсем шөгыле<br>күнел ачу кичәсе<br>комплекслы шогыль |
| 9. | апрель<br><br>2 атна<br>3 атна<br>4 атна | Түбәләрдән тама тамчылар./кошлар турында/<br>Без театр яратабыз.<br>Күктә елмая кояш.<br>Челтәр элдем читәнгә. | шөгыль<br><br>сәхнәләштерү<br>комплекслы шөгыль<br>экскурсия. |
| 10. | май.<br>2 атна.<br>3 атна. | Бабамның медальләре.<br>Аллы-гөлле туган илем.<br>Сау бул,дәү әни. | шөгыль,экскурсия<br>шигырь кичәсе.<br>экскурсия,комплексл ы шөгыль |

**2006-2007нче уку елына«Туган якны өйрәнү музее»ның эш планы**

**Максаты**: 1.Туган шәһәребез Алабуганың 1000 еллыгын лаеклы каршылау.

2. Татар халкының мәшһүр композиторы Сара Садыйкованың 100 еллыгына багышланган чараларны үткәрүгә ярдәм итү

**Бурычлары:** 1. Туган шәһәрләре турында кузаллауларын киңәйтү аша аның белән горурлану хисләре һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларда милли рух тәрбияләү.

2. Исемнәре Алабуга белән бәйле атаклы кешеләр һәм шәһәребезнең талантлы кешеләре белән таныштыру аша мәктәпкәчә яшьтәге баланы танылган шәхесләрне һәм халык талантларын хөрмәтләргә өйрәтү.

| № т/б | Төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| I | **Оештыру эше:** | | |
| | 1.Музей советы әгъзаларын билгеләү. | Август | Музей |
| | 2.Музей советы утырышларын үткәрү. | Айга бер | җитәкчесе |
| | 3.Секцияләр эшен оештыру: | тапкыр | Музей |
| | а) эзләнү-җыю эше | | җитәкчесе |
| | б) экспозиция эше | | |
| | в) экскурсион-масса эше | Айның I | Гәбделбәрова |
| | г) Музей советына | атнасы | С.К. |
| | булышлык итү секциясе | II атнасы | Сибәгатуллина |
| | **Секцияләр эше:** | III атнасы | Р.И. |
| | 1. Эзләнү- җыю эше: | IV атнасы | Козлова С.Ә. |
| | Алабуга каласы белән бәйле | | Халикова Г.Р. |
| | экспонатлар җыю | | |
| | а) Алабугада эшләнгән әйберләр | Сентябрь- | Гәбделбәрова |
| | б)Алабуга шәһәрендәге вакыйгаларга, | октябрь | С.К. |
| | истәлекле даталарга чыгарылган | I кв. | Сибәгатуллина |
| | значоклар, открыткалар, эмблемалар, | | Р.И. |
| | буклетлар | | |
| | в) Алабуга шәһәрендә һәм районында | | Сибәгатуллина |
| | кулланышта булган әйберләр | IIкв. | Р.И. |
| | 2. Экспонатларны теркәү. | | Гәбделбарова |
| II | **II Экспозиция эше** | | С.К. |
| | а) тематик-экспозицион план төзү | | Халикова Г.Р. |
| | б) «Чулман» талантлары (җирле | III кв. | Сибәгатуллина |
| | шагыйрьләрнең портретлары һәм | | Р.И. |
| | китаплары) | | |
| | в )Алабугага багышлана (китаплар). | Ел буе | Козлова С.Ә. |
| | г)Алабуганың атаклы шәхесләре | сентябрь | Халикова .Г.Р. |
| | (китаплар,буклетлар,открыткалар,газета | октябрь | |
| | материаллары) | | |
| | д) Алабуга бизәкләре(фотосүрәтләр | | Сибәгатуллина |
| | открыткалар, альбомнар) | ноябрь | Р.И., |
| | е) Дан җырлыйм сиңа (ата-аналар | | |
| | берлектә рәсемнәр) | гыйнвар | Сибәгатуллина |
| | ж) Алабуга- 1000 яшьлек кала | | Р.И |
| | з) Алабуга-гүзәл кала. | февраль | Сибәгатуллина |
| | III **Экскурсион -масса эше** | март | Р.И. |
| | 1)Экскурсия текстларын төзү | | Сибәгатуллина |
| | 2)Экскурсоводлар әзерләү | апрель | Р.И. |
| | 3) Экскурсияләр оештыру: | май | өлкәннәр һәм |
| | а) **Балалар белән:**Фазыл Шәех музеена | ел буе | мәктәпкә |
| | Интернациолист - солдат һәйкәленә | февраль- | әзерлек төркеме |
| | Хәтер мәйданына | март | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Шишкин буасына<br>б) **Хезмәткәрләр белән:**<br>Туган якны өйрәнү музеена<br>Сәнгать салонына<br>И.И.Шишкин музеена<br>4. Татар төркемнәрендә эшләүче тәрбиячеләр өчен ММБ утырышы:<br>5.Музейда шөгыльләр үткәрү<br>6.Туган тел көне<br>7. Халыкара музейлар көнен билгеләп үтү<br>8. Татар халкының мәшһүр композиторы С.Садыйковага 100 яшь<br>IV Музей советына булышлык итү секциясе<br>а) экспозиция һәм музей фонды материалларын өйрәнү<br>б) музейда үткәрелә торган чараларның план коспектларын туплау<br>в) тәрбия-өйрәнү процессында музей материалларын куллану буенча консультацияләр үткәрү<br>г) музейда шөгыльләр, күңел ачулар үткәрү: | май<br>февраль<br><br>май<br>май<br><br>апрель<br><br>март<br>май<br>май<br><br>перспектив<br><br>план<br>буенча<br><br>май<br><br>сентябрь<br><br>ярты елга бер тапкыр<br>ел буе | музей советы әгъзалары<br><br><br>ММБ житәкчесе<br><br>Козлова С.Ә.<br>Сибәгатуллина Р.И.<br>Сибәгатуллина Р.И.<br>музей советы әгъзалары<br>Тәрбиячеләр, белгечләр, өлкән тәрбияче<br>"—"<br>Музей житәкчесе<br><br>Тәрбиячеләр,белгечләр |

**Татар халык мәдәнияте турында балаларның белемнәрен тикшерү .**

**/ өлкәннәр һәм хәзерлекләр төркемнәре/.**

| Баланың исеме,фамилиясе. | Балаларның белемнәрен билгеләү критерийлары. | Дәрәҗә. | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 1б | 2б | 3б |
| | 1. Нәрсә ул музей? | | | |
| | 2. Музейда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белә. | | | |
| | 3.Бакчабызның туган якны өйрәнү музееның тарихын белә. | | | |
| | 4.тематик экөпозисияләр турында күзаллаулары бар. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 5. Татар халкынаң гореф-гадәтләрен belә . | | | |
| | 6. Татар халык бәйрәмнәре ,аларны бәйрәм итү үзенчәлекләре турында белемнәре бар . | | | |
| | 7.Татар халык әкиятләренең геройларын белә. | | | |
| | 8. Сөйләмдә халык авыз иҗатын куллана /әйтемнәр,тизәйткечләр,табышмаклар,сынамышлар, мәкаль/. | | | |
| | 9.Татар халык уеннарын белә. | | | |
| | 10.Татар халкының җырлы-биюле уеннарын белә. | | | |
| | 11.Татар халкының өй төзелешен белә | | | |
| | 12.Татар халык ашларын атый белә. | | | |
| | 13.Татар халкының көн-күрештә куллана торган савыт-сабаларны атый , алар ни өчен кирәклеген , кулланышын белә. | | | |
| | 14.Татар халкынын көн-күрештә куллана торган эш коралларын атый, алар ни өчен кирәклеген белә. | | | |
| | 15.Татар халкының һөнәрчелек төрләрен белә.шөгыле турында белемнәре бар. | | | |
| | 16. Татар халкының киемнәрен ,аларның төрләрен һәм бизәлешләре турында белемнәре бар / хатыннар,ир-ат киемнәре/ | | | |
| | 17.Татар халык орнаменты бизәкләрен таный,дөрес итеп атый һәм куллана белә. | | | |

**Белем дәрәҗәсен билгеләү өчен якынча җаваплар.**

1.-

2.-

3.-

4. “ Алабугам Ак калам!”, “Күңел җәүһәрләребез”, “ Казан сөлгеләре”,
“ Әбиемнең серле сандыгы”, “ Әби-бабамның эш кораллары”.

5. Әдәплелек сыйфатлары: кунакчыл,пөхтә,уңган,тырыш, олыларны хөрмәт итә...

6. “Сабан туй” (кыр эшләре беткәч үткәрелә,көрәшәләр, ат чабыша, колгага менәләр), “Сөмбелә” , (Сөмбелә-көз кызы килә,уңыш җыялар)“Нардуган “,
“ Нәүрүз”( Яна ел килә, Нәүрүз килә кунакка йөриләр,көн белән төн тигез),
“ Карга боткасы “(каргалар кайта, ботка пешерәләр,сыйлашалар), “ Боз озату
( Яз җитә,боз китә,җылыта),
“ Җир бәйрәме”.

7. 5 герой -3 балл, 3 герой – 2 балл, 2 герой – 1 балл.

8. 1-әр халык аваз иҗаты төрләрен атаса – 3 балл, 3 төрен – 2 балл, 2 төрен – 1 балл.

9. 5 уен – 3 балл, 3 уен – 2 балл, 2 уен – 1 балл.

10. 5 уен – 3 балл, 3 уен – 2 балл, 2 уен – 1 балл

11. Тәрбияче күзлегеннән һәм өй төзелешеннән чыгып.

12. 5 татар халык ашы – 3 балл, 3 – 2 балл, 2- 1 балл.

13. 10 савыт-саба – 3 балл, 5 – 2 балл,3 – 1 балл.

14. 10 эш коралы – 3 балл, 5 – 2 балл,3 – 1 балл.

15. Игенчелек,чигү чигүче,тукучы,тегүче,балта осталары,тимерче,итекче, читекче,шәл бәйләүче,чүлмәкче.

10 һөнәр төре – 5 балл, 5 – 2 балл, 3 – 1 балл.

16.хатын-кыз киеме- бәби итәкле күлмәк,алҗяпкыч,яулыклар,ефәк шәл,камзул, калфак,күкрәкчәләр,читек, чүәк,галош.

Ир-ат киеме – күлмәк,чалбар,түбәтәй,билбау,камзул, итек.

5 кием -3 балл, 3 – 2 балл, 2 – 1 балл.

17. Программа таләпләре буенча.

**Балаларның туган шәһәребез турындагы белемнәрен тикшерү.**

| Баланың исеме,фамилиясе. | Балаларның белемнәрен билгеләү критерийлары. | Дәрәҗә. | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 1б | 2б | 3б |
| | 1.Үз шәһәренең тарихын белә. | | | |
| | 2.Шәһәребезнең символикасын белә. | | | |
| | 3.Шәһәребездә яшәүче халыклар турында белемнәре бар. | | | |
| | 4. Шәһәребезне урап алган урман һәм елгалар исемен белә | | | |
| | 5.Шәһәребезнең тарихи урыннарын белә. | | | |
| | 6.Шәһәребезнең күренекле шәхесләре,аларның туган ил алдындагы хезмәтләре турында белемнәре бар. | | | |
| | 7.Балаларның туган ягыбызның тарихи байлыкларына карата мөнәсәбәтен ачыклау. | | | |

**Белем дәрәҗәсен билгеләү өчен якынча җаваплар.**

1.Алабуга борынгы шәһәр,1000 ел тула.

2. Герб- авторы Риф Фәрхетдинов. Барс – ирек сөюче җанвар, аның калканы да бар,ул халкыбызны явыз көчләрдән сакларга тиеш, барс яшел чирәмдә яши.

Иң өстә-милләтебезнең ярата торган чәчәге-лалә чәчәге. Гимн.

3.Рус,татар, чуваш,марий,башкорт,украин...

4.Чулман,Тойма,Кривуша ,Танай елгалар, Танай урманы.

5.Ак мәчет,Шишкин ,Дурова,Цветаева музейлары,университет,Шишкин буасы һәм урманнары.

6.Шишкин-рәссам, Дурова-кавалерист, Цветаева-шагыйрж,Гөлзада Әхтәмова, Таҗи Гыйззәт, Дибәҗә Каюмова-язучылар,Владимир Мироваев-композитор.

7.Горурлана,сакларга кирәклеген белән.

**Шөгыльләр эшкәртмәләре.**

**Сөйләм үстерү.**

**Габдулбарова С.К.**

**1категорияле тәрбияче.**

**Тема**: **Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел.**

**Максат:** Балаларның сөйләм телен баету, сугыш турында вакыйгаларны матур итеп сөйләргә өйрәтү, туган илгә, өлкәннәргә мәхәббәт, сугышчыларның батырлыклары белән горурлану хисе тәрбияләү, аларга карата кызыксыну уяту, сүзлек өстендә эш: биштәрле капчык, такта чәй, күн итек һ.б.

**Шөгыль барышы:**

Т. Балалар, карагыз әле, безгә бүген бик күп кунаклар килгәннәр. Әйдәгез, алар белән исәнләшик тә ,матур итеп келәмгә утырыйк.

Утыралар.

Т. Балалар, бүген көн нинди?

Б. Кояшсыз, әкрен генә җил исә, суык (һ.б. җаваплар)

Т. Ә бүген атнаның ничәнче көне?

Б. Бишенче, җомга көн.

Т. Иртәгә нинди көн?

Б. Ял көне.

Т. Сез ял көнне нәрсәләр эшлисез?

(Төрле җаваплар)

Т. Әйе, балалар, ял көне һәр кешенең үз эше. Ә менә 1941нче елның 22нче июнендә - ял көнендә фашистлар безнең илгә сугыш башлыйлар. Бу куркыныч хәбәр тиз арада бөтен дөньяны аякка бастырды. Елаш башлана, нәфрәт уяна халык күңелендә. Сугышка китә алган һәрбер кеше сугышка озатыла.

Без дә сезнең белән сугыш турында җыр өйрәндек. “Солдатлар” Роберт Мөхәммәдиев сүзләре, Фәтхрахман Әхмәдиев көе (җырлыйлар).

Сугыш дәвам иткән.

Алабуга шәһәре һәм районыннан 6500 сугышчы батырлыклары өчен медаль һәм орденнар белән бүләкләнгәннәр. Ә 14 якташыбызга Советлар Союзы Герое исеме бирелгән. Менә алар: Фролов Павел Геннадьевич, Гаврилов Аким Гаврилович, Говоров Леонид Александрович, Белоусов Василий Игнатьевич, Шабалин Борис Сергеевич һ.б.

Сугыш көне - төне барган. Сугыш туктап торган арада сугышчылар ял итәргә дә тырышканнар. Музеебызда сугышчыларның ял итү урыны күренеше эшләнгән. Әйдәгез, якын килеп шуны карыйк. Әзрәк сөйләшеп алыйк. Балалар, сез нәрсәләр күрәсез?

Т. Менә, балалар, сез итек дидегез. Итекләр күп бит алар. Сез нинди итекләр беләсез?

Б. Резин итек, йон итек.

Т. Ә менә бу күн итек. Әйдәгез әле бергәләп кабатлап алыйк.

Б. Күн итек.

Т. Сез капчык дип тә әйттегез. Бу, балалар, биштәрле капчык. Әйдәгез кабатлап карыйк.

Б. Биштәрле капчык.

Т. Әйтегез әле миңа, сугышчыларга нәрсә өчен кирәк икән биштәрле капчык? Анда нәрсә бар микән?

Б. Төрле җаваплар.

Т. Ә хәзер капчыкны капшап карыйк.

Капшыйлар.

Т. Әйдәгез ачып карыйбыз. Сез әйткән әйберләр бар микән?

Ачалар.

Б. Ипи, тушенка, сохари, чәй.

Т. Беләсезме, балалар, элек менә шушындый такта чәйләр булган. Бу – такта чәй. Кабатлагыз – такта чәй.

Кемнең биштәрле капчыкны киеп карасы килә? (киеп карыйлар)

Бер бала сугышчы булып киенә.

Т. Әйдәгез әле гармун белән кулъяулык турында күбрәк итеп сөйләшик.

Гармун белән кулъяулык турында сөйләшү.

Т. Балалар, әйтегез әле миңа: кайсыларыгызның әби – бабалары бар?

Б. Төрле җавап.

Т. Әйе, балалар, күрәсезме, һәркайсыгызның әби – бабасы бар. Ә кемнең әби – бабасы сугышта катнашкан?

Т. Күбегезнеке. Безгә Лилия дәү әтисе турында сөйләп алсын .

Балалар, Лилиянең дәү әтисе исән – сау. Илданны тыңлыйбыз.

Ниһаять, балалар, Җиңү көне килеп җитте. Кайчан әле ул?

Б. 9 майда.

Т. Һәрбер сугышчының йөзендә елмаю, сөенечтән елау, бер – берсен тәбрикләү, горурлык хисе. Әйдәгез әле без дә җиңүче солдатлар булып карыйк.

(психологик гимнастика)

Сез монда мәңгелек ут күренешен күрәсез. 9нчы май көнне һәрбер исән кайткан содат һәлак булган дусларын искә алырга монда килә, чәчәкләр куя. Әйдәгез әле без дә үзебезнең ерак туганнарыбызны, әби – бабаларыбызны искә алып, аларга чәчәкләр куйыйк. Безгә шушындый матур тормыш биргәннәре өчен 1 минутлык тынлык белән искә алыйк.

Кунакларга дә ләлә чәчәкләре бүләк итәбез.

Шөгылебез тәмам. Сау булыгыз!

**Миркасимова Г.Г.**

**1 категорияле тәрбиясе.**

**Батар яуда беленер.**

**Максат:** Балаларның батырлык турындагы белемнәрен Бөек Ватан сугышы чоры белән бәйләп тирәнәйтү: совет сугышчыларының батарларча сугышулары һәм илне дошманнан саклап калулары турындагы күзаллауларын милли һәм жирле-төбәк геройларының батырлыклары аша киңәйтү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Сүзлек байлыгын арттыру: ветеран, Советлар Союзы герое, орден, медаль, куен букчасы (кошелек)

Балаларда Ватаныбызга карата мәхәббәт тәрбияләү.

Музей истәлекләре аша бәйләп, куен букчасын кәгаздән бөкләү юлы белән ясау.

**Шөгыльгә әзерлек:** сугыш турында хикәяләр, шигырьләр уку, музейда булу; Хәтер мәйданына барып, мәңгелек ут янына чәчәкләр кую; ветераннар белән очрашулар үткәрү, балаларның сугышта һәм тылда катнашкан әби-бабайларын барлау, истәлекләрен музейга тапшыру, сөйләү. “Спутник” кинотеатрында сугыш турындагы “Кыз этисен эзли” дигән кино карау. Бакчада эшләүче

хезмәткәрләребезнең әти-әниләренең сугышта катнашулары һәм истәлекләре белән балаларны таныштыру.

**Материал:** Сугыш турындагы картиналар. Орден, медаль, куен букчасы. Погоннар (приз өчен). Кул эше өчен : куен букчасы ясау өчен турыпочмаклы аксыл- көрән төстәге кәгазьләр.

**Шөгыль барышы.**

"Сез кайсы халыктан ?" – дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын дип, Ватаным".
Р.Вәлиев.

- Батырлар.Батырлык.Нәрсә соң ул батырлык? Балалар,сез ничек уйлыйсыз,нәрсә ул батырлык?

-Батырлык ул-көчлелек,акыллылык.

-Кирәк вакытта куркып калмау.

-Бәлага очраган вакытта ярдәмгә килү.

-Үзеңнән кечкенәләрне яклау.

-Кызларны кыерсытмау.

-Батыр кеше-илне яклаучы кеше.

-Солдат та батыр була.

Безнең төркемебездә дә "батыр"солдат бар.( Шигырь " Солдат булдым" Җ.Дәрдзаман.)

Батырлык турында мәкальләр дә күп беләбез.Нинди мәкальләр әйтә аласыз?

-Батырлыкта матурлык.

-Батырларга юл туры.

-Батырга үлем юк.

-Батырга яра да килешә.

-Батыр егет-ил күрке.

-Батыр үзе үлсә дә,даны үлми.

Кош һавада,ат тауларда,

Егет яуда сынала.

-Батыр яуда беленер.

Безнең бүгенге шөгылебезнең темасы да “ Батыр яуда беленер”.Балалар,әле күптән түгел генә нинди бәйрәм булды?(Җиңү бәйрәме ). Җиңү бәйрәме кайчан булды? ( 9 нчы май көнне).

Әйе,без 9 нчы май көнне Җиңүнең 60 еллыгын бәйрәм иттек.Менә 60 ел күгебез аяз,тормышыбыз тыныч. Ә без,сезнең белән,сугыш турында күп сөйләштек.Сугышның нинди авыр , куркыныч булганан беләбез. Ә хәзер мин сезгә сөйли барам, ә сез миңа басып йөзләрегез белән ( психологик бушану гимнастикасы) күрсәтә барырсыз.

Сугыш башланды.Кадерле әниләребез ирләрен,улларын борчылып Бөек Ватан сугышына озатып калдылар.( Борчылу)

Аналар! Ялны белмичә эшлиләр дә эшлиләр. Газизләренән ,улларыннан хатлар көтәләр.Хатлар килә.Ул хатларда сагыну хисләре дә ,шатлыклы хәбәрләр дә була.Шатлыктан әниләр елмаеп алалар.(Елмаю)

Ә кайберләре хатларны укыганда моңсуланып,елап алалар. ( Елау).

Сугыш бетте.Җиңү килде.Урамнарны,бөтен җирне шат көлү авазлвры тутырды.

( Шатлану,көлү)

Барысы да сугыш беткәнгә шатланып “ Ура” кычкырдылар. ( “ Ура” тавышлары)

Балалар утыралар.

-Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм батырлыклар күрсәткән сугышчыларга,шулай ук тылда күрсәткән батырлыклары өчен бик күп кешеләрне орден,медальләр белән бүләкләнгәннәр. Иң зур батырлык күрсәткән кешеләргә Советлвр Союзы герое исеме биргәннәр. ( Орден,медаль, Советлар Союзы герое сүзләре кабатлана)

- Алабуга шәһәре һәм районыннан да Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары өчен 6500 алабугалы орден, медальләр белән бүләкләнәләр. Ә

14 якташыбыз Советлар Союзы герое исеменә лаек булалар.Кайберләренең исемнәрен әйтеп үтәбез:

Белоусов Василий Игнатҗевич

Гайнуллин Рифкатҗ Хайрулла улы.

Говоров Леонид Александрович.

Сафронов Петр Сергеевич.

Фролов Павел Григорҗевич.

Шабалин Борис Сергеевич.

Безнең Бөек Ватан сугышы ветераннарына хөрмәтебез зур,рәхмхтебез чиксез. Илебез азатлыгы өчен көрәшкән солдатларны,батырларны беркайчан да онытырга ярамый.

Безнең Алабуга шәһәрендә дә,башка шәһәрләрдәге кебек, Җиңү бәйрәме Җиңү мемориалларында – Хәтер мәйданында тантаналы шартларда үтте. Җиңү көнен барлык кешеләр дә көтеп алганнардыр һәм хәтер мәйданына барганнардыр.

Без дә,гаиләбез белән,Хәтер мәйданында булдык. Безнең төркемгә йөрүче балалар арасында да Хәтер мәйданына баручылар бар. Сүзне аларга бирик әле.Нәрсәләр күрделәр икән алар?!

Бала: - 9 нчы май-Җиңү бәйрәмендә мин әнием белән Хәтер мәйданына бардым. Анда күкрәкләренә орден-медальләр таккан бабайлар,әбиләр күп иде. Туган илебезнең азатлыгы өчен һәлак булган сугышчылар хөрмәтенә куелган һәйкәлне,мәңгелек ут янганын күрдем.Аның янында 2 солдат абый сакта тора иде. Мәңгелек ут янына бик күп чәчәкләр куйдылар.

Тәрбияче:-Балалар,бездә төркемебез белән Хәтер мәйданына төшеп тере чәчәкләр куеп кайттык һәм инде немец фашистларына каршы көрәштә яу кырында һәлак булган һәм сугыштан соң үлгән сугышчыларның исемлеге таш плитәләргә уелып язылган фамилияләр бик күп иде анда.

Күкрәкләренә орден-медаль таккан бабайлар күп иде,диелде. Аларны ветераннар дип йөртәләр.( Ветеран сүзен кабатлау)

(Балалар үзләренең күргәннәре белән уртаклашалар).

Физкультминут

1,2,3 – бездә арта көч,

1,2,3-бездә дуслык,бездә көч.

Тәрбияче: Ветераннар дибез,безнең төркемгә йөрүче балаларның әби-бабайлары да ветеран булган.Алмаз үзенең бабасы турында сөйләргә әзерләнеп килде.( 3-4 бала сөйли)

Тәрбияче: Батырлык,сугыш турында без “ Спутник” кинотеатрында караган кино буенча да беләбез.Бу кино турында кемнең сөйлисе килә?( 1 бала сөйли)

Тәрбияче: Хәрби киемнәр күргәзмәсе,сугыш турындагы истәлекәр , сугышчыларның кыска вакытлы ялга тукталган урыннарының күчермәсен без инде музейда күрдек,өйрәндек.

Сугыш ветераннары Гыйззәтуллина Әминә әби һәм Василий бабайлар,һәм тыл ветераннары белән очраштык. Ветераннар безгә сугыш,батырлык турында күп сөйләделәр.Сүзебезне йомгаклап,батырлык ул – батыр булу, Бөек Ватан сугышында батырларча,куркмыйча сугышу,тылда батырларча,арымыйча – талмыйча көне-төне эшләү.

Без музейда булдык дидек.Музейда сез нәрсәләр күрдегез?

-Палатка,фонарь,карта,биноколь,калак,биштәр,орден-медальләр күрдек .Һидая апаның әтисенең куен букчасын күрдек.( Бергәләп куен букчасы әйтелә.)

Хәзер без шушы куен букчасын кәгазьдән бөкләп,эшләп карарбыз. Куен букчасы көрән кәгазьдән эшләү.(музыка астында)

1. Турыпочмаклы формадагы кәгазь алабыз өске һәм аскы почмакларын уртага таба бөклибез.

2. Барлыкка килгән почмакларны турыпочмаклар урнашкан ноктага яртылаш бөклибез..

3. Шушы ук якларны тагын бер кат урта сызыкка бөклибез.

4. Уң һәм сул якларны артка бөклибез.

5. Кесәләре өстә калырлык итеп яртылаш бөклибез.

6. Бер кесәдән куен букчасын каплар өчен бер почмагын чыгарабыз.

Куен букчаларын килгән кунакларга бүләк итү.

Тәрбияче: Балалар, миндә сезгә бүгенге шөгыльнең истәлеге итеп бүләкләр әзерләдем. Без сезнең белән пагоннарны өйрәнгән идек инде. Һәрберегезгә дә үзегез сайлаган пагоннарны бүләк итәм.

Илебез тыныч. Батыр солдатларыбыз ил чигендә хәзер дә сакта торалар.

Балалар мин дә сезне батыр, акыллы, кыю булып үсәрсез дип ышанам.

Хөрмәтле апалар! Безнең сезгә дә әйтер сүз бар

Дәшәбез сезгә өлкәннәр,
Без – дөнбя балалары.
Балаларның сарылары
Аклары, каралары.
Әрни әле сугышлардан,
Калган җир яралары.
Төзелсен иске яралар,
Булмасын яңалары.
Сез чәчәкләр дисез безне,
Аларны сулдырмагыз.
Сез бит көчле, сугышларны
Моннан соң булдырмагыз.
Өзмәгез сез чәчәкләрне,
Безсез нишләр киләчәк?!
Без булмасак җиребез бит
Суыначак , кибәчәк.
Кояшлы булырга тиеш
Безнең һәрбер иртәбез.
Без сездән тынычлык һәм
Бәхет тәлап итәбез.

**Тема: Сугышчыларның ял итү урыны.**

**Максат:** а) “Бөек Ватан сугышы елларында Ватанны саклаучы солдатлар батырларча сугыштылар һәм илне дошманнардан саклап калдылар” дигән фикерне җиткерү; хәтерләү, истә калдыру сәләтен үстерү.

б) сөйләмдә тиңдәш кисәкләрне (хәбәрләрне ) кулланырга өйрәтүне дәвам итү;

в) палатка, кыр сумкасы, каска, пилотка, котелок, фляжка, күн итек, чолгау, биштәр – сүзлек эше.

Экспонатлар(күрсәтү обьекты): “ Сугышчыларның ял итү урыны” экспозициясе экспонатлары.

**Шөгыль барышы.**

1.Экскурсия “ Сугышчыларның ял итү урыны”.Аны экскурсовод бала үткәрә.

2. -Рәхмәт,Булат.Балалар,сез сугышчыларның ял итү урыннары белән таныштыгыз.Әйдәгез,искә төшерик әле,сугышчылар ял вакытында нәрсәләр эшләгәннәр?

3.Экспозициядәге экспонатларны карау,исемнәрен атау,алар белән нәрсә эшләүләрен искә төшерү.

Палатка

Гармун

Кыр сумкасы

Карта

Каска

Пилотка

Котелок

Фляжка

Күн итек

Аяк чолгавы ( портянка)

Фонарик

Кружка

Тәлинкә

Калак

Биштә

Саклагыч сетка – җәймә.

4.Дидактик уен “ Мин әйтәм – син эшлә”( ягъни “ Без-солдатлар”).

Солдатлар йоклыйлар, гармунда уйныйлар, хат язалар, каска ( пилотка)кияләр, күн итек кияләр,картадан карыйлар ( күзләрен йөртәләр), ашау

пешерәләр, ашыйлар, кайнар -өрәләр, юыналар, кырыналар, чәчләрен тарыйлар, яраларына өрәләр, яраларын бәйлиләр,көзгедән карыйлар- чистарганнар,матурайганнар- сез дә йөзегез белән чиста,матур булуны күрсәтегез.

5. Уен “ Капшап таны”

Биштәрне капшап, кипкән ипи һәм такта чәйне белү.

6.хәрәкәтле уен “ Мин – солдат булдым”.

Балалар биштәр асып, пилотка киеп йөреп күрсәтәләр. Теләгән балалар солдат итегендә киеп йөреп карыйлар.

7.Магнитофон тасмасыннан җыр тыңлау: “ Җырлар бәйләме “ №1 ( җыентык )

А) Солдат булдым ( Р.Еникеев көе,Җ.Дәрзаманов сүз)

Б) Солдатлар ( М. Минһаҗев көе, К.Булатова сүз).

**Тема: Безнең данлы армия.( синең сакчыларың).**

**Максат**: Балаларның армия,Ватанны саклаучылар турында күзаллауларын киңәйтү:

армиядә пехотачылар,танкист,диңгезче,очучы,ракетчик,артиллерия,чик сакчылары бар.Ил сакчыларына карата ихтирам хисе , кыю һәм батыр булу теләге тәрбияләү.

Җиһазлау: а) Экспонатлар: солдат киеме һәм “ Сугышчыларның ял итү урыны”

экспозициясе экспонатлары.

б) хәрби һөнәрләр турында рәсемнәр.

1. Шөгыль “Сугышчыларның ял итү урыны” экспозициясе янында үткәрелә. Иң элек балалар белән экспозиция турында белгәннәре искә төшерелә.

2. “ Синең сакчыларың” хикәясен уку.

Син төнлә рәхәтләнеп йоклыйсың, ә чик сакчылары,безнең җиребезгә беркем дә явыз ният белән яшеренеп кермәсен дип,төн буе сакта торалар. Безнең

күгебезне күзәтүчеләр дә төн буе үзләренең постларында уяу торалар.Иртән,әле кошлар да уянмас борын , кызыл йолдызлы самолетлар күккә югары күтәреләләр. Тәҗрибәле командирлар яшь очучылырны очарга өйрәтә.Таң белән безнең кораблар да флагларын җилфердәтеп , диңгезгә чыга. Карт капитаннар, яшь матросларны диңгез хезмәтенә өйрәтә.Иртән син әле рәхәтләнеп йоклап ятканда , танкистлар инде танкларының маторларын кабызалар. Пехота солдатлары да поход җырлары җырлый-җырлый , кырга сугыш һөнәрен өйрәнергә чыгылар.

Очучыларның да, морякларның да, пехота солдатларының да – барысының да бүрекләрендә кызыл йолдызлар янып тора. Бу кызыл йолдызларның төсе җир йөзендәге барлык кешеләргә дә билгеле. Данлы ул безнен батыр совет солдатлары.

( Л.Камиль “Синең сакчыларың”)

3.Текст эчтәлеге буенча әңгәмә:

- Текста сүз кемнәр турында бара ? Текст ничек дип атала.
- Кемнәр төн буе сакта торалар?
- Самолетта кемнәр күккә күтәрелә ?
- Таң белән нәрсәләр диңгезгә чыга?
- Яшь матросларны кемнәр өйрәтә?
- Әле рәхәтләнеп йоклап ятканда , кемнәр танкларны кабызалар?
- Кемнәр поход җырларын җырлый-җырлый кырга сугыш һөнәрен өйрәнергә чыгалар?

Балалардан тулы җавап талап ителә.

4. Физкультминут а) “Без булачак солдатлар” (солдатлар булып атлап йөриләр).

б) “Солдат булдым” (Р.Еникеев көе “Ж.Дәрзаманов сүзләре), “Солдатлар” (М.Минһаҗев көе , К.Булатов сүзләре) җырларын тыңлау ( атлап йөрергә дә мөмкин) (Җырлар бәйләме №1 а/к).

5. Һәрби һөнәрләр турында рәсемнәр карау. Пехотачы, танкист, диңгезче, очучы, ракетчик, артелерист, чик сакчылары- сүзләрен аерым һәм бергә кабатлау. Бу сүзләр белән җөмләләр төзү.

6. Музейда саклана торган солдат киемен (тәрбияче Гатина Рәвия Салих кызының  улы Раилнең киеме) карау.

7. Йомгаклау. С.Сәйдәшевның “Совет Армиясе маршы”н тыңлау.

**Сибагатуллина Р.И.**

**Тема: Әбиемнең савыт-сабалары.**

**Максат** :-савыт-сабалар белән таныштыру ,аларның нәрсәдән эшләнүләрен , кайда

сaклануларын һәм төрләре турында белешмәләрен тирәнәйтү.

-“Савыт- саба”темасына кагылышлы сүзләрне актив сүзлеккә кертү; сүзләрне саннар,фигылҗләр белән бәйләп ,җөмләләр төзергә өйрәтү.

-милли савыт- сабалар (чулмәк, касә һ.б.) белән таныштыру, аларны аера белергә өйрәтү.

-туган халкына ихтирам тәрбияләү

Җиһазлау: а) Төлке , торна рәсемнәре һәм “Төлке белән торна” әкиятенә иллюстрацияләр.

б) Экспонатлар: савыт-сабалар, тәлинкәләр.

**Шөгыль барышы:**

1.Оештыру өлеше.

- Әйдәгез әле музейда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшерик:

- Күзләр карый, колаклар тыңлый, куллар тими.

2. “Төлке белән торна” татар халык әкиятен уку.

3. Эчтәлеге буенча әңгәмә:

- Бервакыт Төлке нәрсә белән дуслашкан?
- Нинди сүзләр белән Төлке Торнаны кунакка чакырган?
- Төлке нәрсә пешергән һәм аны нәрсәгә салган?
- Торнаны ул нинди сүзләр белән сыйлаган?
- Торна нишләгән?
- Ботканы кайсы ашап бетергән?

- Торна нинди ашау әзерләгән?
- Торна Төлкене нинди сүзләр әйтеп сыйлаган?
- Төлке нишләгән?
- Борчакны кайсы ашап бетергән?
- Төлке белән торнаның дуслыгы ни өчен беткән?

Физкультминут : Төлке бока ялый,
Торна тәлинкә чукый.
Төлке йөри, исни,
Торна йөри.

4. “Бәйрәм ашы- кара-каршы.”мәкаленең мәгънәсен аңлату һәм мәкальне яттан өйрәнү.

5. Савыт-сабалар карау.

6. “Нәрсә кирәк?” уены.

- Балалар , чәй эчәргә нинди савыт-сабалар кирәк? .......... Ашарга ( ягъни ашау өчен) ..........., кофе эчәргә .......... һ.б.

7. Йомгаклау.

- Без бүген нинди әкият тыңладык?
- Нинди мәкаль өйрәндек?
- Тагын нәрсәләр карадык?
- Ә хәзер савыт-сабалар турында табышмакларның җавабын кем табар икән?

1). Өй эчендә түгәрәк күл. (тәлинкә)

2). Бәләкәй генә тай,
Төбе чеп-чи май. (таба)

3). Шар чаклы күзе бар,
Йодрык чаклы үзе бар. (чинаяк).

4). Эче кайнар, борыныннан агар,
Бер кулы бар,
Ул да аркасында (Чәйнек)

5). Башы да тишек,
Төбе дә тишек,

Уртасында ут,

Читендә су. (Самавыр)

6).Үзе бер дә ашамый,

Ашаганда бушамый. (Кашык)

7).Үрдәк чума китәр,

Койрыгы чыга китәр. (Чүмеч)

8).Башы суда, койрыгы чөйдә. (Чүмеч)

**Тема: Әбиемнең эш кораллары.**

**Максат:** Балаларны хуҗалыкта кулланыла торган эш кораллары белән таныштыру, аларның ни өчен кирәклеген аңлату. Хезмәт яратучы халыкка хөрмәт тәрбияләү.

Җиһазлау: а) "Тавык, тычкан һәм көртлек" әкиятенә рәсемнәр. б) Экспонатлар-

эш кораллары: ярма яргыч, гөбе, каба һәм орчык ,эрләү станогы, туку

станогының бер өлеше, сырлы бәләк, урак, үтүк, көянтә һ.б.

**Шөгыль барышы:**

1. "Тавык, тычкан һәм көртлек" татар халык әкиятен уку.
2. Әкиятнең эчтәлеге буенча әңгәмә.

- Әкиятнең исеме ничек?
- Бөтен эшне кем эшләгән?
- Тавык нәрсәләр эшләгән? (арпа тапкан, тегермәнгә барган, он тарттырган, алып кайткан. Ипи изгән, мичкә яккан. Мичкә икмәкне куйган.)

3. Физкульминут.

а) Без ипи изәбез.

б) Шырпыны өреп сүндерәбез . Мичкә ягу өчен нәрсә кирәк? Әйдәгез шырпыны сыздык, яна һәм өреп сүндерәбез. Шырпы белән уйнарга ярыймы? Ни өчен?

в) Тәмле икмәк исен иснибез (икмәкләр бик уңдылар- кабарып, кызарып пештеләр) Икмәкне тотып карыйбыз – пешерә! Икмәкне ашап карыйбыз – тәмле! (психогимнастика)

4. Уен “Кайсы мәкаль әкияткә туры килә?”

“Бәйрәм ашы – кара-каршы.”

“Кем эшләми – шул ашамый”.

5. Ярма яргычны карау. Аның эшләү тәртибе белән танышу, әйләндереп карау. Балаларга арпа ярмасын күрсәтү, татып карау.

6. Әбинең эш коралларын карау, ничек кулланыларын аңлату:

гөбе, каба һәм орчык, эрләү станогы, туку станогының бер өлеше,сырлы беләк, үтүк, урак.

7. Уен “Күрсәтегез әле , эшне ничек эшлиләр?”

8.Табышмак әйтәм җавабын тап:

а) Бәләкәй генә әби,
Йөгерә, йөгерә йон җыяр. (Орчык)

б) Бер әйләнсә һаман әйләнә.
Әйләнгән саен байый һәм калыная. (Орчык)

в) Йөгерә-йөгерә йөк җыяр. (Орчык)

9. Шөгыльне йомгаклау.

- Без бүген шөгыльдә нәрсәләр эшләдек?
- Нинди эш коралларының исемнәре исегездә калды?

Без бүген әбиебезнең эш кораллары белән таныштык. “Әбинең , әбиемнең әбиебезнең” эш кораллары дибез, чөнки элек бу эш кораллары белән күбесенчә хатын-кызлар эшләгәннәр

## Тема: Бабамның эш кораллары.

**Максат:** Балаларны хуҗалыкта кулланыла торган эш коралларыбелән таныштыруны
дәвам итү, аларның ни өчен кирәклеген аңлату. Эш яратучы халыкка карата
хөрмәт тәрбияләү.

Җиһазлау: Экспонатлар : пычкы, балта, калыплар, сәнәк, кыргыч.

### Шөгыльнең барышы.

1.Әбинең эш коралларын искә төшерү.

2. Уен "Ул кайда? Күрсәт."

(Әбинең эш кораллары "өй" экспозициясенә урнаштырылган, балалар аларның исемнәрен атыйлар һәм күрсәтәләр)

3. Уен "Күрсәт әле, үскәнем."

Ничек май язалар?

Ничек йон эрлиләр?

Ничек урак уралар?

Ничек ярма яралар ?

Ничек кер үтүклиләр? һ.б.

4. Бабайның эш кораллары белән танышу.

- Без хәзер санап киткән, күрсәткән эш кораллары белән хатын кызлар эшләгәннәр. Бүгенге шөгыльдә танышачак эш кораллары кулларының көче күбрәк. Ягъни көчле кешеләр өчен. Гаиләдә алар кемнәр? Әйе, әтиләр ягъни ир-атлар.

Пычкы, балта, сәнәк, кыргыч, калыплар белән танышу.

5. Уен "Эшләсәң эш табыла".

Оста иртән үк,

Эшкә кереште.

Эш кораллары

Юксынган эшне.

Сөенде ышкы

Балалар: -Эш –эш - эш – эш!

Шатланды пычкы,

Балалар парлап утын кисәләр: -Тыр-рыш, тыр-рыш!

Очынды чүкеч

Балалар чүкеч кагалар: - Шәп! Шәп! Шап! Шәп!

Талпынды балта

Балалар утын яралар : -Шак! Шак! Шалт! Шалт!

6. Табышмак әйтәм- җавабын тап!

1). Авызы юк , тешле. (Пычкы)

2) . Аягы юк, кулы бар,

Авызы юк, теше бар.

Таш тегермән булмаса да,

Ярма ярыр эше бар. (Пычкы)

3). Җырлый – җырлый әйбер кисә,

Әйтеп бирче, бу нәрсә? (Пычкы)

4). Авызы юк, теше бар,

Ашаганын йоталмый,

Кулы белән тота алмый. (Пычкы)

7. Йомгаклау.

- Без бүген нинди эш кораллары белән таныштык?

- Бу эш кораллары белән, балалар, күбрәк ир-атлар эшләгәннәр. Алар белән эшләү өчен көч күбрәк булу кирәк булган. Утын кисү һәм яру , сәнәк белән эшләү- авыр эш, шуңа күрә бу эшләрне ир-атлар башкарганнар. Шуңа күрә бу эш коралларын без “бабамның эш кораллары” дип атыйбыз.

## Тема: Нәүрүз бәйрәме.

**Максат**: -Балаларның халкыбызның изге бәйрәмнәренең берсе булган “Нәүрүз” бәйрәме турында күзаллауларын тирәнәйтү.

-Һәр халыкның тормыш көнкүрешен тагын да ямьлерәк итә торган матур йола һәм бәйрәмнәре булуын аңлату, ул бәйрәмнең асылын аңлату.

- Халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

## Шөгыль барышы.

1.Оештыру өлеше.

- Елның кайсы вакыты? (фасылы)
- Кайдан белдегез?
- Көн нинди?
- Ни өчен җылы?

2. “Нәүрүз” бәйрәме турында сөйләү.

I вариант- уртанчылар төркеме өчен.

Элек татарлар Яңа ел бәйрәмен 22 мартта уздырылган. Аны Нәүрүз бәйрәме дип атаганнар. Бу көнне малайлар һәм кызлар матур киемнәрен кигәннәр. Аннары һәр өйгә кергәннәр , матур җырлар җырлаганнар, биегәннәр. Хуҗаларны бәйрәм белән котлаганнар. Балалар мондый такмак әйткәннәр:

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Бытбылдан аваз килде-
Нәүрүз мөбарак булсын.

II вариант - өлкәннәр, мәктәпкә әзерлек төркемнәре өчен.

XVIII гасырга хәтле татар халкы Яңа елны март аеның 21ендә, көн белән төн тигезләшкән вакытта каршы алган. Бу көн Иран календаре нигезендә “Нәүрүз” дип аталган, ул “Яңа көн” дигән мәгънәне аңлата.Күп мөселман илләрендә Яңа елны хәзер дә март аенда каршы алу гадәте яшәп килә. Бу кызны озату, язны

каршы алу га багышланган йола бәйрәме. Бу көнне яшьләр, балалар өйдән-өйгә кереп, бәет, шигырь әйткәннәр. Моны “Нәүрүз әйтү” дип атаганнар. Бу эшнең үз осталары да булган. Бу көнне йорт хуҗаларына, аның гаиләсенә исән-саулык, иминлек-байлык, башланган яңа елның мул һәм тыныч булуын, бәхет китерүен теләгәннәр. “Нәүрүз “ әйткән өчен яшүсмерләргә хуҗалар йомырка, кәнфит яки вак акчалар биргәннәр.

Нәүрүз әйттек без сезгә,
Хакын бирегез безгә.
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә,
Нәүрүз мөбарәкбад!

Нәүрүз мөбарәкбад! – Яңа ел котлы булсын дигән мәгънәне аңлата.Бу көнне авыл халкы бергә җыелып күңел ачкан, биегән, җырлаган, уеннар уйнаганнар. Сүз осталары, мәзәкчеләр, шамакайлар, кәмит күрсәтүчеләр чыгыш ясаганнар. Яз кызы – Нәүрүзбикә килгән. Нәүрүзбикә итеп озын толымлы, матур кызны сайлаганнар. Безнең әби-бабайларыбыз шулай кызык итеп уздыра торган булганнар бәйрәмнәрне.

3. Физультминут. Уен “Утыр, утыр, Мәликә”

(Балалар түгәрәккә басалар. Берәү , күзен бәйләп түгәрәк уртасына утыра. Калганнар, кулга кул тотынып, түгәрәктә җырлап әйләнәләр.

Утыр, утыр, Мәликә, алмагачның төбен
Кем утырган каршыңа, әйтеп бирче үзеңә.

Берәү аның каршына килеп утыра. Уртадагы бала, аны капшап, кем икәнен белергә һәм исемен әйтергә тиеш. Әгар белмәсә аңа җәза бирелә. Уен шулай дәвам итә.)

4. “Кояш чык” эндәшен бергәләп өйрәнү.

Кояш чык, чык,чык!
Майлы ботка бирермен,
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.

Әти китте базарга,

Тәти кашык алырга.

Тәти кашык саф алтын

Безгә кирәкми салкын.

5. Магнитафон язмасында а) Нәүрүз турында җыр тыңлау (“Нәүрүз һәм балалар”) һәм кушылып җырлау. а) “Нәүрүз” җырын тыңлау. (“Җырлар бәйләме” №2 а/к) М.Имашев көе, Ә.Гадел сүзләре.

**Тема: Карга боткасы.**

**Максат:** Татар халык бәйрәмнәре белән таныштыру дәвам итү. “Карга боткасы” бәйрәменең асылын аңлату. Халкыбызның гореф- гадәтләренә, йолаларына ихтирам һәм мәхәббәт тәрбияләү.

**Шөгыль барышы.**

1. Оештыру өлеше.

2.”Карга боткасы” бәйрәме белән таныштыру.

Борын-борын заманда кешеләр ни өчен яз булганын белмәгәннәр ди. Алар ямьле язны кара каргалар алып килә дип уйлаганнар. Шуның өчен, кар эрегәч, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясаганнар. Аны “Карга боткасы” дип атаганнар. Авыл балалары халыкны бәйрәмгә чакырганнар такмаклар әйткәннәр:

Карга әйтә: кар-кар.

Туем җитте , бар,бар!

Ярма, күкәй алып бар,

Ипи-итең алып бар,

Карр, карр, карр!

Шунан соң авыл халкы су буенада ботка пешергән, уеннар уйнаган, биегән. Соңыннан ботка ашаганнар.

Каргалар кешеләр кайтып киткәч:

- Кар, кар,

Әйбәт дуслар бар,бар, - дип калган ботканы чукыганнар.

3. Такмакны өйрәнү.

- Балалар , бәйрәмгә чакырып, такмаклар әйткәннәр дидек. Әйдәгез, без дә ул такмакны өйрәник әле.

4. Уеннар уйнау.

- Бу бәйрәмдә уеннар уйнаганнар, җырлаганнар, биегәннәр. Әйдәгез без дә уйныйк, җырлыйк, биик.

а) “Ефәк элдем читәнгә” (җырлы- биюле уен)

б) “Яшерәм яулык” (җырлы –биюле уен).

в) Бармак уены.

- “Карга боткасы” бәйрәмендә авыл халкы су буенда ботка пешерик.

Карга килә, казан аса.

Торна килә, тоз сала.

Песнәк килә, пешерә.

Чыпчык килә, тикшерә.

Әдип ашап бетерә.

Кап та коп!

г) “Ватык телефон”

д) Балалар үзләре яраткан җырларны җырлыйлар, бииләр.

е) “Кәвешче” (хәрәкәтле уен)

ж) “Йомырка отышлы”

з) “Очты-очты”

5. Йомгаклау.

- Балалар сезгә бәйрәм ошадымы?

- Ни өчен бәйрәм “Карга боткасы” дип атала?

- Бәйрәм нәрсәсе белән сезгә ошады?

**Тема: Сабан туе.**

**Максат**: Татар халык бәйрәмнәре белән таныштыруны дәвам итү. Сабан туе турында өстәмә мәгълүматлар бирү. Халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына мәхәббәт, ә тырыш уңган, сәләтле халыкка ихтирам тәрбияләү

Җиһазлау : Колга. Чиккән һәм кызыл башлы сөлгеләр, кулүяулыклар, яулыклар, кашыклар, йомыркалар, “чүлмәк”, “атлар”, капчыклар, аркан. Сабан туе сурәтләнгән рәсемнәр.

**Шөгыль барышы.**

1. Оештыру өлеше.

- Балалар, исегезгә төшерегеә әле, җәй башында- июнь аенда матур һәм күңелле нинди бәйрәм үткәрелә?

2. Сабан туе бәйрәме турында сөйләү.

Сабан туе – татар халкының иң яраткан бәйрәме. Ул язгы кыр эшләре (сабан) беткәч уздырылган, шуңа күрә Сабан туе ( туй – зур бәйрәм) дип атала. Ул июнь аенда була.

Сабан туе гадәттә матур урман аланында, яшел болында уза. Һәркайда җыр, уен-көлке яңгырый.

Әнә бер читтә озын колга бар. Аның очына әтәч куйганнар. Мен дә ал! Тик колга бик шома. Аның очына бик сирәк кеше генә менә ала.

Бер җирдә халык бик күп җыелган. Монда ике малай капчык белән сугыша. Бүрәнәдән егылып төшмәсәң, сине бүләк көтә.

Сабан туенда аркан тартыш, чүлмәк вату (разбивание горшка), кашыкка йомырка салып йөгерү (бег с яйцом в ложке), ат чабышы кебек милли ярышлар да үткәрелә.

Сабан туеның төп ярышы – татарча көрәш. Анда җиңүчегә хәзер бик зур бүләк белән бергә тәкә дә бирәләр.

3. Бүләкләр җыю өчен кулланыла торган колганы, аңа эленгәнчиккән кулүяулыкларны, сөлгеләрне карау.

- Сабан туе бәйрәменә дә бер яки берничә көн алдан өйдән өйгә кереп бүләк җыепйөргәннәр. Бүләк җыючылар кулларына менә шундыйколга тотканнар

һәм биргән бүләкләрне шул колгага бәйләп элеп куйганнар. Әйдәгез бүләкләр арасында нәрсәләрбар икән, карыйк әле. (Колгага эленгән әйберләрне карыйлар, исемнәрен атыйлар, бизәкләрен күзәтәләр).

4.Уеннар уйнау ( Уеннар импровизациягә корылган, зурларның сабантуй уздыруына ияру рәвешендә уйнала)

а)Чүлмәк вату.

б) Капчык белән сугышу.

в) Кашыкка йомырка салып йөгерү.

г) Шигырьләр сөйләү, җырлар җырлау.

д) “Ат” чабышы

е) “Көрәш” (2 бала – малайлар ничек көрәшүләрне күрсәтәләр)

5. Йомгаклау.

Магнитофонтасмасыннан “Сабантуй” җырын тыңлау.

**Тема: Хуш киләсез, рәхим итегез!**

**Максат:** Балаларны аралашу, кунакта үз-үзеңне тоту, исәнләшү әдәбе белән таныштыруны дәвам итү һәм өйрәтү. Бу темага кагылышлы сүзләрне активлаштыру. Аралашу, исәнләшү, кунакта үз-үзеңне тоту әхлагы тәрбияләү.

Җиһазлау: “Өй” экспозициясе.

**Шөгыль барышы.**

1. Балаларны каршы алу.

Әби балаларны:

- Исәнмесез, оланнарым, хуш киләсез, рәхим итегез. Әйдүк, әйдүк! Түрдән узыгыз! – дип каршы ала.

- Балалар мин сезне нинди сүзләр белән каршы алдым?

- Олы кешеләр, әби-бабайлар тагын “Әссәләмәгәләйкүм” дип тә исәнләшәләр. Әйдәгез бергәләп һәм аерым- аерым әйтеп карыйк әле.

2. Балалар белән танышу.

- Рәхим итегез, утырыгыз, оланнар! Әйдәгез танышыйк инде. Минем исемем Рәсимә әби. Ә синең- ? Сез миңа матур итеп: Минем исемем .......” – дип җавап бирегез.

3. Физкультминут. “Күрешү”

Олы кешеләр бер-берсе белән кул биреп тә исәнләшәләр , күрешәләр. Олы кешеләр белән басып , ике куллап , ягъни ике кулны да биреп исәнләшәләр.

4.Тәмле сүзләр турында әңгәмә.

Безнең телебездә тәмле сүзләр би-хи-сап! Сез дә беләсез аларны.

Төн узып, көн туу белән әйтелә торганы нинди! Әйе, “Хәерте иртә!” Өйдәгеләрне , күршеләрне, дусларны “Хәерле иртә!” – дип сәламләшергә онытмыйсыз инде!

Әле тагын ниндиләре бар?

Әйе, әле тагын “Хәерле көн!” , “Хәерле кич!” – дигән сүзләребез бар. Алары да онытыла күрмәсен. Хәер , көн саен, кич саен кабатлап торгач , ничек онытылсын ди алар?

Хуш, көнне – кешеләргә яхшылык, дөньяга иминлек теләп башладык. Ә нинди теләк белән тәмамлыйбыз? Шу-лай! Тыныч йокы теләп:

“ Тыныч йокы , әнием!”

“ Тыныч йокы, әтием! “

“ Тыныч йокы, үземә,

Тыныч йокы күземә” – диябез.

Күпме генә тыңласаң да , күпме генә кабатласаң да, тәмле сүзнең кадере китми. Рәхәте әйткән кешегә дә , ишеткән кешегә дә җитә. (“Салават күпере” журналыннан).

Һәрвакыт тәмле телле булыгыз, оланнар, тәмле, матур сүзләр белән генә сөйләшегез.

5. Күчтәтәч белән сыйлау.

- Тәмле сүз ишеткәч , күңелгә рәхәт булса, тәмле әйбер ашагач, авызга рәхәт була. Минем дә сезгә күчтәнәчем бар. Аның нәрсә икәнен капшап белеп карагыз әле, ә җавабыгызны миңа колакка гына әйтегез.

- Күчтәнәч  алгач, нәрсә дип әйтерсез икән? Күчтәнәчне  алгач , нәрсә дип әйтерсез икән? Күчтәнәчне уң кул белән алабыз.Уң  кулыгызны күрсәтегез әле миңа.

- Ашавыгыз тәмле булсын, оланнар.

7. Әйтем, мәкаль өйрәнү.

- Кунакта әдәпле балаларны яраталар. Шуңа күрә олылар: “Кунак булсаң, тыйнак бул” – диләр.

- Бу сүзләр нәрсәне аңлата  икән?

- Әйдәгез, әйтемне бергәләп әйтик әле.

- Халкыбызның “Әдәп башы – тел” – дигән мәкале  дә бар. (Бергәләп әйтү)

8. Балаларны озату.

- Без бүген нәрсәләр турында сөйләштек?

- Кунакны “Гаеп итеп китмәгез. Тагын килегез”, - дип озаталар. Киткәндә кунаклар: “Рәхмәт”, - әйтеп китәләр.

- Оланнар, онытмагыз: Кунак сые  яхшы йөз, тәмле сүз.  Аннан кала ипи-тоз.

## Тема : Әбиемнең өе.
## Экскурсия шөгыль.

**Максат :** Татар  өенең  бизәлешен карау, андагы әйберләр   белән таныштыру; сүз байлыгын арттыру – сәке,чаршау, кашага.

Экспонатлар: “Өй” экспозициясе экспонатлары.

### Шөгыль барышы.

1. Оештыру өлеше.

- Сез бүген әбидә  кунакта. Әйдәгез, кунакта үзеңне ничек тотарга кирәк? Искә төшерик әле, халыкның нинди әйтеме бар? (Кунак булсаң тыйнак бул.)

2.Экскурсия “Дәү әнидә кунакта”  (Әдилә сөйли.)

3. Татар өенең бизәлешен карау, андагы әйберләр белән танышу.

Әйдәгез әле, әбинең өенең бизәлешен карыйк. Стенага нәрсәләр эленгән? Бу нәрсә? (Сөлге). Сөлгенең очларын – сөлге башы диләр. Сөлгенең баш-башлары нинди? (Кызыл) Бу сөлгеләр – кызыл башлы сөлгеләр. Ә хәзер аерым-аерым әйтәбез.

Ә бу сөлгедә нәрсәләр бар? (Чәчәкләр, кошлар). Әйе, бу сөлгеләргә чәчәкләр, кошлар чигелгән. Аларга рәсемнәрне җепләр (төрле төстәге) белән чиккәннәр. Болар – чигүле сөлгеләр.

4. Физкультминут. “Оста бармаклар” (Куллар белән чәчәк, кош ясау). “Кошлар оча”.

- Стенада тагын нәрсәләр бар? (көзге, сәгать, радио, чигү)
- Тагын сәгать кайда бар? Чигү тагын кайда бар?
- Сәгать ничек йөри? (келт- келт) Әйдәгез телләрне сәгать итеп йөртәбез.
- Тәрәзәгә нәрсәләр эленгән? (челтәр, пәрдә, телле пәрдә).
- Караватт кая?. Агачтан ясалган мондый йокы урыннарын сәке диләр, аларның караватт башлары юк.

“Сәке” сүзен аерым һәм бергә әйтү.

- Сәке янында нәрсәләр эленгән. (чаршау һәм кашага, телле кашага)

“Чаршау”, “кашага” сүзләрен бергәләп һәм аерым әйтү.

- Ә бу нәрсә?- әйе, мич. Ул нәрсә өчен кирәк?
- Идәнгә нәрсә җәелгән ? (Палас. Суккан палас.)
- Әбинең өендә түрдә нәрсә тора? (Өстәл, өстәл өстендә самавар, ипи, шикәр савыты)
- Өстәл янында урындыклар тора. Тагын нәрсәләргә утырырга мөмкин? (Сандык өстенә, сәкегә, эскәмиягә)
- Әбинең өендә тагын нәрсәләр бар?

5. Балаларга үз фикерләрен әйтү мөмкинлеге тудыру.

- Әбинең өе матурмы? Ул сезгә ошадымы? Нәрсәсе белән ошады?

6. “Кошның да туган оясы бар” дигән әйтемне аңлату, өйрәнү.

7. Уен “Син адресыңны беләсеңме?

- Балалар, ә сезнең “туган оягыз” нәрсә ?. Сез адресыгызны беләсезме? Хәзер “Син адресыңны беләсеңме?” дигән уен уйныйбыз.

8. Йомгаклау.

**Тема: Әби- бабайның йорт хайваннары.**

**Максат:**1.Уртанчы төркеме: йорт хайваннары, аларның тышкы кыяфәте белән таныштыруны дәвам итү. Кешеләрнең йорт хайваннарын карауларына бәйле хезмәте белән таныштыру.Йорт хайваннары һәм аларның балалары турында (үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре, хәрәкәтләнүләре ,нәрсә ашаулары, кешегә нинди файда китерүләре турында) күзаллаулары киңәйтү.Өлкәннәр төркеме: йорт хайваннары турында күзаллауларын системалаштыру. Мәктәпкә әзерлек төркеме: болан, дөя турында күзаллау бирү.

2. Әйберләрнең кайда, ничек урнашуын белдерә торган сүзләрне әйтү һәм сөйләмдә куллана белү күнекмәләре бирү. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл. Һәркем ишетерлек һәм аңларлык итеп җавап бирергә күнектерү.

Җиһазлау: йорт хайваннары һәм аларның балаларының рәсемнәре, уенчыклары,
сөйләм схемасы, чүлмәк.

**Шөгыль барышы.**

1. Оештыру өлеше.

- Менә без бүген тагын әбидә кунакта. Әйдәгез әле, кунакта үзеңне ничек тотарга кирәк, төшереп китик. Халыкның бу турыда нинди әйтемнәре бар?

2. Һ.Такташның “Тәүфиклы песи” шигырен уку һәм эчтәлеге буенча әңгәмә.

- Әби нәрсә дип малкайларына печән бирергә чыгып китә?
- Ә песи нәрсә эшли?
- Ә эт нәрсә ди?
- Чүлмәк нәрсә эшләгән?
- Эт нишли? Ул нәрсә кабып карый?
- Шул вакыт мыштым гына өйгә кем керә?
- Әби нәрсәне ачулана?
- Нәрсә гаепле? (чүлмәк төшеп китеп ватылуда һәм түгелүдә).

3. Рәсем буенча шигырьне сөйләү.

4. Физкультминут. а) "Чүлмәк кайда?" (башта күзегез белән генә табыгыз, соңыннан кул белән күрсәтегез).

б) "Чүлмәк нинди?" (карау).

- Бу чүлмәкне бик күптән безнең Алабуга шәһәрендә яшәүче Мәҗитов фамилияле бабай балчыктан ясаган.

в) "Нәрсә ничек кычкыра һәм ашый?" (песи, эт)

г) Уен "Песием, пес, перәс".

5. Уен "Песи кая качкан?"

- Мияу-мияу мырламас,
Мияу мияу җырламас
Тын да алмас, суламас,
Мияу-мияу, мин качам,- дип уенчык песи өй эчендә төрле урыннарга кача (мәсәлән: карават астына, урындык астына, чүлмәк эченә, сандык өстенә, сандык артына, мич кырыена, мич башына).

6. Йорт хайваннарының рәсемнәрен карау:

а) тышкы кыяфәтләре;
б) кешегә нинди файда китерәләр;
в) кешеләр аларны ничек карыйлар;
г) нәрсә ашыйлар;
д) балалары.

7. "Нәрсә, нәрсә эшли?"

Эт - өрә, песи- мияулый, ат- кешни, сыер- мөгри, кәҗә - мәэлди, дуңгыз – мыркылдый, сарык- бәэлди.

8. Уен “Әниләр һәм бәбиләр”.

9. Уен “Хайваннарны чакыру”.

Чакырабыз мәчене :
Пес-пес-пес,
Пес-пес-пес!
Чакырабыз Акбайны:
Маһ-маһ-маһ,
Маһ-маһ-маһ!
Чакырабыз бахбайны:
Бах-бах-бах,
Бах-бах-бах!
Чакырабыз кәҗәне:
Кәҗ-кәҗ-кәҗ,
Кәҗ-кәҗ-кәҗ

10. Йомгаклау. “Табышмак әйтәм – җавабын тап”

1) Кешенең дусты,
Йортның сакчысы. (эт)

2) Нинди аучы коралсыз
Җәнлек аулый көн буе,
Анан мыегын селкетеп,
Йоклап ята көн буе. ( мәче)

3) Табышмак әйтәм мин сезгә,
Йон бирә нәрсә безгә. (Сарык)

4) Үлән ашый сөт ташый (Сыер)

5) Сакалы бар – акылы юк (Кәҗә)

6) Калын арка, тарта да тарта ,
Ул тарткан саен табыш арта. (Ат)

7) Безнең өч дустыбыз бар: берсе ашата,
икенчесе эчертә,
өченчесе йөрт саклый . (Ат, сыер, эт)

8) Тимерче дә түгел,
Балта остасы да түгел,

Үзе авылда беренче эшче. (Ат)

## Тема: Беләзегем- йөзегем.

**Максат:** Хатын-кызларның бизәнү әйберләре белән белән таныштыру. (беләзек, йөзек)

Җиһазлау: 1) Экспонатлар: йөзекләр, беләзекләр, алкалар

2) Рәсемнәр: фил, мамонт, бизәнү әйберләре.

3) Татарстан картасы.

4) Альбом "Халкыбызның күңел бизәкләре"

**Шөгыль барышы:**

- Галиҗәнәп Кеше һәрчак матурлыкка, гүзәллеккә- сәнгать дөньясына омтылып яши. Ул борын - борын заманнардан үк инде бизәнү әйберләренә, зәркан (ювилер) сәнгате әсәрләренә бик зур игътибар биргән. Талантлы осталар фил, мамонт сөякләреннән, төрле ташлардан бизәнү вә куллану әйберләре ясый торган булганнар. Тора-бара еллар арты еллар, чорлар арты чорлар узган, осталарның да кул эшләре камилләшә, тагы да затлылана төшкән. Алар алтын-көмешләрдән, энҗе мәрҗәннәрдән төрледән-төрле, матурдан-матур әйберләр ясарга өйрәнгәннәр. Безнең Татарстан төбәгендәге Арча, Саба, Мамадыш, Тәтеш һәм Лаеш (картадан күрсәтү) осталарының даннары хәттә ерак җирләрдә дә мәгълүм.

- Балалар, сез өлкәннәргә, үзегезнең әниләрегезгә, әбиләрегезгә, апаларыгызга игътибар белән караганыгыз бармы. Исегезгә төшерегез әле , аларда нинди бизәнү әйберләре күргәнегез бар? (Балаларның җаваплары)

- Әйе, берегезнең әнисе алтын алка таккан, икенчегезнең әнисе беләгенә - көмеш беләзек, өченчегезнең әнисенең бармагында матур йөзекләр...

- Балалар, бизәнү әйберләре бик күп төрле: алкалар, беләзекләр, йөзекләр, муенсалар, чулпылар һ.б.

Бизәнү әйберләренең рәсемнәрен карау, исемнәрен бергәләп һәм аерым-аерым кабатлау.

- Балалар, безнең музейда җыелган, тупланган әйберләр арасында да бизәнү әйберләре бар. Музейга җыелган әйберләр экспонатлар дип атала. Менә бу өстәл-витринага бизәнү әйберләре куелган. Сез аларны якын килеп карагыз һәм анан соң мин сезгә ул әйберләрне берәм-берәм күрсәтермен, ә сез аның нәрсә икәнен, ягъни исемен әйтерсез.

Беләзек турында мәгълүмәт бирү, сөйләү.

Беләзек – иң киң таралган һәм иң борынгы бизәнү әйберләреннән берсе (таш гасырында, мәсәлән, мамонтның казык тешләреннән эшләнгән беләзекләр мәгълүм).

Татарстанда беләзек киемнең аерылгысыз өлеше булган. Аны бай хатыннарда ярлылары да, яше дә, карты да яратып кигән. Гадәттә беләзекне парлап: һәр кул да берәрне йөрткәннәр. Бу гаиләдә ир белән хатын арасында татулык яшәсен өчен шулай кабул ителгән.

Еш кына ювелирлар беләзекне көмештән, сирәк очракларда алтыннан, я көмеш белән алтын эретелмәсеннән ясаганнар. Беләзекләр тоташ та, ялгаулы да итеп эшләнгән. Киңлекләре исә 6 см. га җиткән. Яшь кызлар тар беләзекләрдән йөргән. өлкәнерәк ханымнар киңрәк беләзекләрне хуп күргән.

Беләзекләрне бизәү ысуллары күптөрле: материалга чүкеп, чокып, сырлап катлаулы бизәкләр яисә гарәп язуларын төшергәннәр. Асылташлар белән бизәлгән беләзекләр бигрәк тә затлы саналган. 3-5 таш – беләзекнең буена, ә вагыраклары шулар тирәсенә урнаштырылган. Топаз, аквамарны, сердолик кебек эре ташлар, вагыраклардан исә хризолит, энҗе, яхут файдаланылган. Фирәзә ташын аеруча яратканнар.

Йөзек турында сөйләү.

“Йөзек салыш” уены уйнау

**Тема: Әби-бабайларның хуҗалык әйберләре.**

**Экспонатлар:** үлчәүләр, гер, керосин лампалары, (сукыр лампа, куыклы лампа, шахта лампасы), лампа савыты, табагачлар, күмер савыты, кыскыч, кисәү таягы, самавар торбасы, керосин плитәсе.

**Экскурсия тексты.**

Без бүген дә сезнең белән әби һәм бабай янында кунакта булырбыз һәм аларның хуҗалык әйберләре турында сөйләшербез.Хуҗалык әйберләре дип хуҗалыкта кирәкле әйберләрне атыйбыз, йорт кирәк- яракларына бәйле, йортны алып баруга хезмәт итә торган әйберләр, ягъни йортта көнкүрештә кирәк булган предметлар.

Элек көнкүрештә кирәкле әйберләрнең берсе-лампа булган. Мондый лампалар керосин лампалары дип аталалар, чөнки аларның савытына керосин (яна торган сыеклык) салынган. Керосин пилтә (тасма) буенча өскә менә, шырпы сызып кабызыла һәм яна, өйне яктырта. Яна торган өлешен ( җирен) каплап тора торган пыяла куык дип атала. Куыксыз лампалар да була, андый лампаларны сукыр лампа дип атала. Сезнең алда торган лампаларның кайсы сукыр лампа була , бармакларыгыз белән күрсәтегез әле.( яңа аерым һәм бергәләп сүзләрне кабатлау)

Ә бу лампа – шахта лампасы. Игътибар итегез: аның куыгы (пыяласы) да калын, чөнки шахтерлар җир астында күмер ваталар, җир астында эшлиләр. Шуңа күрә, ватылмасын өчен бу лампа нык булырга тиеш.

Бу – лампа савыты. Лампаны йөртүе уңайлы булсын өчен бу савыттан файдаланганнар. Сарайга мал-туар янына чыкканда, урамда йөргәндә лампаны савытына куеп йөрткәннәр.

Үлчәүләргә әһәмият итегез. Аларнын икешәр тәлинкәсе, көянтәсендә 2 элмәге һәм тигезлекне күрсәтүче угы бар. Элмәккә тәлинкәсен элеп куйганнар.Бер тәлинкәгә үлчәнүче әйбер, ә икенче тәлинкәгә гер куелган. Герләрне карагыз әле: алар төрле зурлыкта, димәк төрле авырлыкта.

Бу – табагач. Исеменә әһәмият итегез: таба һәм агач. Ул мичтән табаларнын алу, мичкә кую өчен хезмәт иткән. Сабы-агач. Тагын чуеннарны тоту өчен

файдаланыла торганнары да булган. Ансының да сабы агач. Ләкин тоткычлары икесенеке ике төрле.

Бу савыт – күмер савыты. Утын мичтә янганда күмер барлыкка килә. Ул күмерләрне мичтән кисәү таягы белән тартып мич алдына китергәннәр һәм кыскыч белән алып, күмер савытына салганнар. Бу күмерне самавыр кайнату өчен кулланганнар. Кисәү таягын да, кыскычны да карагыз. Икесендә тимердән эшләнгәннәр, чөнки утыннарны янып торган кызу мичтән кызган күмерләрне алу өчен кирәк алар.

Күмер самавыр кайнату өчен кирәк дидек. Ә кумер янганда төтен чыга. Төтен өй эченә чыкмасын , мич аша урамга чыгып китсен өчен самавыр торбасыннан файдаланганнар.

Ашау пешерү өчен мичне генә түгел, ә керосин плитәсен дә кулланганнар. Аңа да керосин салганнар, шырпы сызып яндырганнар. Ул хәзерге газ плитәсенә әзерәк ошаган.

Ә сез газ плитәләрен кабыза беләсезме? Шырпы белән ничек эш итәргә кирәк? Эйе, шырпы уенчык түгел.

## Тема: Муса Җәлил – шагыйрь һәм сугышчы - солдат.
## ( өлкәннәр һәм мәктәпкә әзерлек төркеме өчен)

**Максат:** - Муса Җәлилнең иҗат юлын өйрәнүне дәвам итү.

-Сораулар ярдәмендә шигырҗләрнең идея-эчтәлеген аңларга өйрәтү, балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

-Муса Җәлил әсәрләренә кызыксыну уяту, балаларда патриотик хисләр тәрбияләү.

Экспонатлар: М.Җәлил портреты, “ Батыр куян” ( Казан, тат.китап нәшрияте,1998) китабы, һәйкәл – сувенир, пилотка, солдат киеме, күн итекләр, котелок, калак, кружка.

Ярдәм фонд экспонатлары: кыр сумкасы, фляжка, каска, мылтык, пушка, биштәр.

## ЭКСКУРСИЯ ТЕКСТЫ:

М Җәлил – халык герое, атаклы татар шагыйре.Ул балалар өчен дә, олылар өчен дә күп шигырьләр язган. Аның исемен Туган илебез халыклары гына түгел, башка чит ил халыклары да яхшы белә.

М Җәлил 1906 нчы елда Оренбург өлкәсендә Мостафа авылында туа. Мусаның Ибраһим исемле абыйсы була. Ул Мусадан дүрт яшькә зур. Көзен Ибраһим мәктәпкә җыена башлый. Ул сумкасын ала, аңа әлифбасын, дәфтәр һәм карандашларын сала. Муса әтисенә:

- Мин дә мәктәпкә барам. Минем дә укыйсым килә,- ди. Әтисе аның аркасыннан сөеп:

- Син әле бер-ике ел уйна!- ди.

Мусаның уйныйсы килми:

- Мин дә мәктәпкә барам. Мин дә укырга барам!- ди.

Шуннан әтисе Мусаны мәктәпкә алып килә.

- Менә бу кечкенә улыбыз да укырга тели ,- ди Мостафа абзый .- Аңа алты яшь кенә.

-Әйдә йөрсен, -ди укытучы.

Шулай итеп, Муса мәктәпкә йөри башлый.Тиздән ул абыйсы Ибраһимны куып җитә.

Беркөнне Мостафа абзый мәктәпкә килә дә укытучыдан сорый:

-Безнең кечкенә улыбыз ничек укый?

- Бик тырышып укый. Тиздән ул барысында узып китәчәк.

Муса бер елда башлангыч мәктәпне тәмамлый.

Муса Җәлил яшьтән шигырьләр яза башлый. 30 нчы елларда Мәскәүдә балалар журналы чыгара. Күп шигырьләр һәм поэмалар, либреттолар яза.

Ул балалар өчен дә бик күп шигырьләр язган дидек.Хәзер берничәсен искә төшереп һәм танышып үтик әле.Тыңлагыз әле:

Таң ата бугай,
Әтәч кычкыра:
-Кикрикүк,
Кикрикүк,
Йә сузып кына,
Йә бик еш кына:
-Кикрикүк,
Кикрикүк!
Аңа кушыла
Башка әтәчләр:
-Кикрикүк,
Кикрикүк!
Картлар артыннан
Шаулаша яшьләр:
-Кикрикүк,
Кикрикүк!

Без дә уяндык
Әтәч тавышына:
-Кикрикүк,
Кикрикүк!
Бакчага килдек,
Ашыга-ашыга:
-Кикрикүк,
Кикрикүк!

-Шигырьдә сүз нәрсә турында бара? Димәк, шигырьнең дә исеме нинди булыр инде? Әйе,
" Әтәч".
- Ә хәзер бер кош турында тыңлагыз әле.

Калын урманда
Гел кичкә каршы,
Ишетелә моңлы
Бер кошның тавышы:
-Кәккүк,кәккүк.
Кәккүк,кәккүк!
Ул салмак кына
Кабатлый шуны,
Шул аның җыры,
Шул аның моңы:
-Кәккүк,кәккүк.
Кәккүк,кәккүк!
Ул ялгыз яши,
Чыгармый бала,
Менә шунлыктан
Ямансу аңа!
-Кәккүк,кәккүк.
Кәккүк,кәккүк!

- " Кәккүк" дип нинди кош кычкыра? Шигырьнең исеме нинди булыр инде? Әйе,"Күке".

- Ә менә бу шигырь “ Куян” дип атала.( уенлы җыр)

Куян салкыннан
Туңган,куырылган,
Башы салынган,
Колагы шиңгән.
Әйдәгез, дуслар,
Аны терелтик;
Җылы бүлмәгә,
Мәктәпкә илтик.
Куян уянды,
Куркып уйланды,
Сикереп урманга,чабып югалды.
Куян,син кайда?
-Яшел тугайда.
Куян,син кайда?
-Ерак чүлләрдә.
Куян,син кайда?
-Калын урманда.
Куян,син кайда?
-Карлы буранда.
Әйдәгез,дуслар,
Карны,урманны,
Чүлне актарып
Куянны табыйк

Физкультминут:

- Әйдәгез,хәзер без әтәчләр булдык.(басып, кулларын җилпеп әтәч булып кычкыралар)

-Бармаклардан кош ясадык.

-Сезгә ничә яшь? Әфәрин, ә хәзер бармаклар белән күрсәтегез! Ә хәзер сезгә ничә яшь,күке шулкадәр кычкырсын.

-Ә хәзер куяннар булып сикерегез!.

Муса Җәлилнең шигырьләренә җырлар да язганнар. Мәсәлән, Фирзәр Мортазин аның
“ Маэмай” һәм “ Чишмә” шигырьләренә җырлар язган. Хәзер магнитофон тасмасыннан шуларны тыңларбаз.

- Хәзер бармакларыгыздан песи һәм күсе ясагыз һәм мин сезгә аның “ Карак песи” дигән шигырен укып күрсәтәм.

Чоландагы ак майга
Иялəшкəн күселәр,

Мин чоланны сакларга
Куштым ала песигә:
-Мияу,мияу,пескәем!
Барчы зинһар,чоланга,
Майны сакла күседән,
Оясыннан чыгарма!
Песи күргәч, күселәр
Койрыкларын кыстылар.
Йөрмәделәр чабышып,
Ярыкларга постылар.
-Мияу,мияу,пескәем!
Колак салдың сүземә!
Каравылдан бушагач,
Сөт бирермен үзеңә.
Иртә белән майга дип,
Керсәм күзем акайды:
Явыз песи берүзе
Ялт иттергән ак майны!
-Мияу,мияу,пескәем!
Хыянәтче икәнсең.
Саклый торган маеңны
Үзең ашап беткәнсең!

Бөек Ватан сугышы башлана. Муса Җәлил фронтка китә.Ул кулына мылтык тотып сугыша. Өстенә солдат киеме, башына пилотка,аягына кирза ( күн) итекләр киеп, аркасына биштәр иңенә кыр сумкасы асып йөри. Аның кыр сумкасы да була,чөнки ул әле гади сугышчы гына түгел,ә шагыйрь , журналист та.

( Хәрби темага багышланган экспонатлар карау)

Муса Җәлил дә шундый ук котелоктан ашагандыр,фляжкадан су эчкәндер. .

Муса Җәлил сугышта әсирлеккә төшә.Тик ул дошманнан куркмый. Фашистларга каршы яшерен оешма төзи,шигырьләр яза. Фашистлар Җәлилне җәзалап үтерәләр.Муса Җәлилнең батырлыгын халык онытмый.

Казан Кремле янында бер һәйкәл бар.Ул Муса Җәлилгә куелган. Һәйкәл янында һәрвакыт чәчәкләр була.Чөнки Муса Җәлил татар халкының батыр улы, яраткан шагыйре

**Тема: Габдулла Тукай – татар халык шагыйре.**

**Максат:** -Язучының тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыруны дәвам итү, аның иҗатына кызыксыну уяту;

-Г.Тукай шигырҗләренең төп идеясын аңларга өйрәтү.

-Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

-Г.Тукайның күпкырлы иҗатына мәхәббәт тәрбияләү.

Экспонатлар: “ Өй” һәм “ Мәдрәсә” экспозициясе экспонатлары, ” Чал тарихлы Казаным” экспозициясе экспонатлары.

**ЭКСКУРСИЯ ТЕКСТЫ:**

Габдулла Тукай - татар халкының бөек шагыйре.Ул 1887 нче елда Кушлавыч авылында туа.Габдулла кечкенәдән ятим кала: башта әтисе, аннан соң әнисе үлә. Күп авырлыклар күрә. Аның балачагы Кырлай авылында үтә.

( “Өй” экспозициясе экспонатларын карау)

Габдулланың Кырлай авылында кечкенә энесе туа.Габдулла аны карарга булыша, бишектә тирбәтә һәм йоклата.

Кырлай авылында ул беренче мәртәбә мәдрәсәгә бара. Мәдрәсәдә кызлар абыстайда, малайлар муллада укыйлар.

( “ Мәдрәсә” экспозициясе экспонатларын карау)

Габдулла Тукай - шагыйрь,ул шигырьләр яза.Аның балалар өчен язган шигырьләре бик күп,мавыктыргыч әкиятләре,кызыклы мәсәлләре бар.

Әйдегез, шигырьләрен искә төшерүне шигырь-табышмактан башлыйк. “ Бу кайчак була?” ( 4-5 яшь)

-Кырлар буш кала,

Яңгырлар ява,

Җирләр дымлана-

Бу кайчак була?

Һәр җир карланган,

Сулар бозланган,

Уйный җил,буран,

Бу кайчак, туган?

Боз һәм кар эреде,

Сулар йөгерде,

Егълап елгалар,

Яшьләр түгелде.

Көннәр озая,

Төннәр кыскара,

Бу кайсы вакыт,

Я,әйтеп кара?

Ашлыклар үсте,

Башаклар пеште.

Кояш пешерә,

Тиргә төшерә.

Халык ашыга,

Китә басуга,

Урагын ура,

Бу кайчак була?

**Ак бабай.**

**( 3-4 яшь)**

Бөтен дөнья ап-ак кар яуганда,

Ишегалды.урам,түбә агарганда,

Ап-ак булып кайтып килә безнең бабай,

Безгә төрле-төрле уенчыклар алган да.

( 4-5 яшь)  Габдулла Тукайның “ Бала белән күбәләк” шигыренә көй дә язылган һәм хәзер җырын тыңлагыз.

Габдулла Тукай татар халык уеннарын бик яраткан.Хәзер шул уеннарның берсен уйнап үтәрбез. Физкультминут : “ Йозаклы” уены.

( 5-7 яшь) Габдулла Тукайның “ Бичара куян”,”Кошларга”,” Күз”,”Җир йокысы”,

” Карлыгач”,” Шаян песи”,” Кызыклы шәкерт”,шигырьләре дә балаларга багышланган. Аның “ Шүрәле”,” Су анасы”, “ Кәҗә белән сарык” әкиятләре дә бик кызыклы. Габдулла Тукай тормышының соңгы елларын республикабызның башкаласы Казанда үткәрә. “ Чал тарихлы Казаным” стендында сез Казан шәһәре төшерелгән рәсемнәрне күрәсез.Казанда Габдулла Тукайга һәйкәл бар.

**Тема: Милли киемнәр.**

Экспонаталар:хатын-кыз күлмәге,альяпкыч,яулыклар,ефәк шәл,камзул,калфак,күкрәкчәләр,

башмак,читек,чүәк,галош.

## ЭКСКУРСИЯ ТЕКСТЫ:

Төрле милләт халыклары яшәү рәвеше,гореф-гадәтләре,кайсы дин вәкиле булуы,йөз сызыклары,киемнәр төрлелеге белән бер-берсеннән аерылалар. Ләкие төс-кыяфәт, кием-салым бер дә үзгәрми торган нәрсәләр түгел. Без 19 гасырдагы киемнәрнең дә күбесен музейларда гына күрәбез. Димәк,чорына карап , кешеләрнең киемнәре дә үзгәрә тора. Шуның өстенә, бер үк вакытта яшәгән кешеләрнең кием-салымында да аерымлыклар була. Әйтик, көндәлек кия торган , эшкә һәм, әлбәттә , кунакка барганда, бәйрәмнәрдә кия торган киемнәр була. Шул ук вакытта авыл кешесенен киеме дә шәһәрнекеннән

аерыла. Шулай кием теге яки бу милләтнең кайда яшәвенә дә,нинди хезмәт (эш) белән шөгыльләнүенә дә нык бәйле.

Татар халкы күп гасырлар буена уртача табигатьле урыннарда – Идел-Урал буйларында яшәгән. Габдулла Тукай әйткәнчә:

Анда бик салкын вә бик эссе түгел,урта һава;

Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.

Шуңа күрә биредә яшәүчеләргә кием елның һәр фасылы өчен аерым-аерым кирәк.Кыш кигәне җәйгә ярамый, яз-көз өчен тагын үзенә бер төрле кием булуы зарур.

Кием-салымның нинди булуы бу милләтнен ата-бабаларының ,әни-әбиләреннән килә торган яшәү үзенчәлекләренә, йолалар, гореф-гадәтләргә дә нык бәйләнгән.

Татар хатын-кызлары ситсыдан яки сатиннан тегелгән бала итәкле күлмәк,аның өстеннән альяпкыч кигән.Альяпкычның иң өстенә һәм итәкләренә дә бала итәкләр тегелгән, күкрәк турына ,итәгенә чәчәк чигелгән. Башларында дүртпочмаклап бәйләнгән ак яулык. Урамга йөрергә чыкканда , хатын-кызлар яулык өстеннән матур ефәк шәл бөркәнгәннәр.

Кызлар,апалар башларына матур чигүле калфак та кигәннәр.Калфак өстеннән шулай ук ефәк шәл япканнар.Хәзерге калфаклар бик кечкенә, аларны баш киеме дип әйтеп тә булмый , алар бизәнү әйберенә генә әйләнеп калдылар.

Башларына кызлар, апалар кәттәши дә кигәннәр.Ул – түбәтәй кебек баш киеме.Кәттәшиләр чигелмәгән шома гына булырга , энҗе һәм ука белән чигелгән була.
( рәсемен карау).

Татар апалары күлмәк өстеннән камзул кигәннәр.Кызлар-кыска камзул, ә олылар-итәге тезгә җитә торган камзул.Алар төймәләнми,яки бер генә төймәгә эләктерелә,яки каптырыла.

Хатын-кызлар түшләренә күкрәкчәләр дә кигәннәр. Ул түшне матурлап тотып торган. Күбрәк бәйрәмнәрдә киелә торган булган.

Аякларына чүәк башмак,читек киеп йөргәннәр.Чүәкләр матур төстәге күннән тегелгән,төрле бизәкләр белән бизәлгән. Башмаклар күннән яки бәрхеттән тегелгән, көмеш, алтын, матур җепләр белән чигелгән энҗеләр һәм укалар белән бизәлгән.

Читекләр төрле төстәге матур күннән тегелгән, бизәкләр белән бизәлгән, чигелгән. Кызлар биек үкчәле. ә апалар тәбәнәк үкчәле читек кигәннәр һәм читек өстеннән галош та кигерткәннәр.

**Сынлы сәнгать шөгыльләре.**

**Гыйззатуллина Н.З.**

**1**

**категорияле тәрбияче.**

**Гөлҗамал әбидә кунакта.**

**Максат** : 1. Балаларның үсемлек эчтәлекле орнамент турындагы белемнәрен киңәйтү.

2.Үзлектән татар орнаменты элементлары төзи белү сәләтен нygытырга, эштә лалә, ак чәчәк үрнәкләрен куллана белү күнекмәләре камилләштерү.

3. Кисеп ябыштыру шөгылендә кирәк булган техник күнекмәләрне камилләштерү. Төсләрне дөрес сайлап кулланырга өйрәтүне дәвам итү, сәнгать зәвыгын тәрбияләү, күңелләрендә халык сәнгате белән кызыксыну уяту.

**Шөгыль барышы.**

Ишек шакып балалар музейга керәләр.

Исәнмесез , саумысыз,

Нигә ишек ачмыйсыз?

Шакый- шакый арып беттек,

Нигә каршы алмыйсыз?

Өй күренешеннән Гөлҗамал әби чыга.

- Исәнмесез, балакайларым, минем алма бөртекләрем, хөрмә җимешләрем!

Балалар: Исәнмесез, саумысыз,

Нигә кәҗә саумыйсыз?

Сыерыгыз бозаулаган,

Нигә чыгып алмыйсыз?

Әби: И-и-и, шаярмагыз әле, балалар. Болай да борчылам. Чигү чигәргә дип утырган идем, күзләрем начар күрә башлаган. Кайда икән ул яшь чакларым?

Тәрбияче: Гөлҗамал әби, ниләр чикмәкче идең соң?

Әби: Оныкларыма калфак, түбәтәй, алъяпкыч чигәрмен дигән идем. Тиздән бәйрәмнәр җитә, кайткач, үзләрен сөендермәкче идем.

1 бала: Борчалма, Гөлҗамал әби. Без булышырга тырышырбыз.

Әби: Рәхмәт, балам, яхшы сүзеңә. Бераз ял итеп алыгыз, мин мичне генә карап чыгыйм, янып беткәндер инде (әби китә).

Тәрбияче: бик яхшы, балалар, сез Гөлҗамал әбигә ярдәм итәргә теләвегез. Әйдәгез алайса искә төшерик татар халык киемнәре нинди бизәкләр белән бизәлгән.

- Татар халык киемнәре татар халык орнаменты белән бизәлгән.

- Ә татар бизәкләрендә нинди чәчәкләрнең мотивларын очратабыз? (лалә, ак чәчәк, дәлия, тукранбаш һ.б.)

Тәрбияче: Уңган хатын кызларыбыз

Эшнең серен белгәннәр.

Кич утырып, җырлар- җырлап

Оста чигү чиккәннәр.

Балалар, ә сез нинди чәчәк булыр идегез?

- Мин лалә чәчәге булыр идем. Ул матур, аның аскы өлеше ай сыман түгәрәк, ә өске өлеше ялкын кебек телле-телле. Түгәрәк теллесе дә була.

- Ә миңа дәлия чәчәге ошый, әгәр мин чәчәк булсам, мин дәлия чәчәге булыр идем, чөнки аларны яратып әнием үстерә.

- Ә минем ак чәчәк буласым килә. Ак төс ул бик матур, чисталыкны, пөхтәлекне аңлата. Ләкин мине кешеләр өзмәсен, таптамасын иде!

- Минем кашкарый чәчәге буласым килә. Ләкин мин бакчада түгел, ә тәрәзә төбендә гел-гел чәчәк атыр идем...

(Балаларнын төрле җаваплары тынлана.)

Тәрбияче: Ә хәзер бирегә килегез. Балалар түгәрәккә тезләнәләр, уртада түбәтәй, альяпкыч, калфак силуэтлары белән поднос).

Тәрбияче: Балалар, әбигә ярдәм итәбез дидек, ә кем нәрсә бизәргә тели? Сайлап алыгыз.

- Нинди бизәкләр килешер икән? Нинди төсләр кулланырбыз? Эшкә керешкәнче бераз ял итеп алыйк.

Физкультминут:

Гөлчәчәкләр күренде ( балалар басалар)

Һәм кояшка үрелде (кулларны югары күтәрәләр)

Аларга җылы кирәк.

Кояш астында рәхәт( сузылалар)

Җил исте (чайкалалар)

Чәчәкләрне селкетте.

Уңга бөгелделәр ( бөгеләләр)

Сулга бөгелделәр.

Җиргә иелделәр (чүгәлиләр)

Бар син, җил (башларын калкыталар)

Моннан кит,(басалар)

Чәчәкләргә тими үт (куллар белән алга этү)

Алар зур булып үссен (сузылалар)

Безгә шатлык китерсен (утыралар)

- Әйдәгез, балалар, үзегезгә ошаган киемнәрне (силуэтларны) алыгыз да өстәлләр янына киләбез. Ә хәзер бармакларны эшләтеп алыйк, бераз язылсыннар.

- Балалар , искә төшереп үтик: чәчәкләр, яфраклар бертөрле булсын өчен нинди ысул белән кисәбез (турыпочмакны урталай бөкләп кисәбез). Кирәк дип тапсагыз, трафареттан да куллансагыз була.

Мөстакыйль эшчәнлек вакытында техник осталыкка, төсләрне сиземләүгә игътибар итү. Аяклар, арка торышына басым ясау. Балалар эшләрен тәмамлаганда тәрбияче әбине дәшә.

Тәрбияче: Гөлҗамал әби!

Әби: Әү, балам!

1 бала: Әбекәй, менә сезгә алъяпкыч, калфак, түбәтәй.

Әби: Менә, балалар, булдыргансыз, рәхмәт төшкерләре. (Эшләргә анализ)

Тәрбияче: Гөлҗамал әби, безнең балаларның сиңа тагын бүләкләре бар.

1 малай һәм 1 кыз "Кәләпүшем – калфагым" дигән җыр башкаралар.

1 кыз бала шигырь сөйли:

Алъяпкычымның бизәге
Нурлар сибә йөземә.
Чәчәк төшкән һәрбер кием
Килешәдер үземә.

Әби: Җырга да, шигырь сөйләргә дә оста икәнсез үзегез. Шундый уңган балаларыбыз булганда, күңелемдә безнең һөнәребезне дәвам итүчеләр бар икән дигән ышаныч туа. Мәңге сүнмәс безнең милли сәнгатебез , һаман шулай балкып, чәчәк атып торыр.

Тәрбияче: Синең янда шундый рәхәт булды, Гөлҗамал әби, вакытның үткәнен сизми дә калдык. Безгә төркемгә кайтырга вакыт.

Әби сиңа рәхмәт яусын
Исән- имин бул яме.
Әби белән шундый рәхәт,
Үзең безгә кил яме.

Гөлҗамал әби балаларны сыйлый, балалар рәхмәт әйтеп, саубуллашып, чыгып китәләр.

**Гыйззатуллина Н.З.**

**1 категорияле тәрбияче.**

**Татар рәссамнарының иҗаты аша зәвек тәрбиясе бирү.**

**Максат**:1.Балаларны бөек татар рәссамы Б.Урманче иҗаты белән таныштыру.

2.Рәсем сәнгатенең төрле жанрлары белән таныштыруны дәвам итү.

3.Төрле алым-чаралар аша балаларга зәвык тәрбиясе бирү.

4.Балаларның техник осталыкларын үстерү.

**Шөгыль .барышы:**

1. Тәрбияче : Хәерле иртә,агачлар!

Хәерле иртә,кошлар!

Хәерле иртә,табигать!

Хәерле иртә,дуслар!

- Балалар,бүген мин сезне күргәзмә залына сәяхәткә чакырам. ( күргәзмә залында төрле жанр әсәрләре)
- Ә нәрсә соң ул күргәзмә залы? Әйе,монда төрле картиналар урнашкан. Әйдәгез аларны якынрак карыйк. Бу картина нинди жанр икәнен әйтегез.(пейзаж,натюрморт,портрет)
- Ни өчен алай дип уйлыйсыз? Пейзажның берсе безнең Алабугада иҗат ителгән.Кем таный? Ул картинаның авторын әйтегез. (Әйе,дөрес, бу бөек рәссам И.И.Шишкинның “Наратлар” картинасы.)
- Ә мин бүген сезне бөек татар рәссамы белән таныштырам. Ул-Бакый Урманче.(портреты күрсәтелә)

Бакый Урманче күп еллар элек Буа районында туган. Башта Казанда, аннары Мәскәүдә укып белем ала. Аның рәсем сәнгатендә башкарган хезмәте искиткеч зур.Ул күпкырлы талант иясе. Бакый Урманче пейзаж,портретлар һәм натюрмортлар төшергән.Аның эшләре илнең күп почмакларында саклана. Ә

хәзер рәссамның берничә эшен карап үтик. Бу картинасы нинди жанрда башкарылган? (“Бүлдәнәж”)

-Ике натюрмортны чагыштырыгыз. Минем натюрморт якты, ачык төсләр белән язылган. Ә Бакый Урманченың кәефе нинди булган? Ул күбрәк нинди төсләр кулланган? Рәссам күбрәк тыныч, тонык, караңгы төсләр кулланган, ләкин чәчәкләр якты, ачык төстә, хәттә ап-ак урыннары да күп. Шушы төсләр, барысы бергә кушылып, чуарлык һәм матурлык
тудыралар, күңелгә рәхәтлек, шатлык өстиләр. Елның нинди фасылы? Картинада яктылык кайдан төшә? Чәчәкләр турында нинди матур сүзләр әйтеп була?(нәфис,хуш исле,горур,матур,ак,гүзәл,ак күбек төсле,назлы,җәйге һ.б.)

-Рәсемгә нинди исем бирер идегез?

- Нинди тавышлар ишетәсез?

-Нинди шигъри юллар исегезгә төшә?

Чәчәкләрем ал гына,
Ал гына бал гына,
Аңкып тора хуш исе,
Нинди матур,хуш исле.

-Балалар,сез бу рәсемдә нәрсә булыр идегез? Ни өчен? Бу натюрмортка нинди музыка туры килә? Нинди музыкаль инструментта уйнарга мөмкин? Ә хәзер мин сезгә бер уен тәгьдим итәм. Уен “Натюрморт төзе” дип атала. (Бер бала фланелеграфта җәйге,икенче бала көзге натюрморт төзи.)

Физкультминут.

Гөлчәчәкләр күренде
Һәм кояшка үрелде.
Аларга җылы кирәк,
Кояш астында рәхәт.
Җил исте,
Чәчәкләрне селкетте.
Уңга бөгелделәр,
Җиргә иелделәр,
Сулга бөгелделәр,
Җиргә иелделәр.
Бар син,җил,моннан кит,
Чәчәкләргә тими үт.
Алар зур булып үссен,
Безгә шатлык китерсен!

2. Балалар,бүген без сезнең белән натюрморт ясап, үзебезнең күргәзмәне ачарбыз.Ләкин бу темадан ерак китмичә, һәрберегез үзенчә натюрморт ясый. Кәефләрегез ничек?

Мөстәкыйль эшчәнлек.

3. Анализ. Бүгенге шөгыльдә сезгә нәрсә ошады? Нинди рәссам белән таныштык? Кем үзенең рәсеме белән канәгать, минем янга килегез.

-Сез барыгыз да бик тырыштыгыз, һәрберегез күңел җылысын биреп эшләдегез, шуңа күрә күргәзмәбез бик матур килеп чыкты. Әйдәгез кунакларны күргәзмәгә чакырыйк. Рәхим итегез!

**Гәрәева И.С.**

**Миркасимова Г.Г.** **1**

**категорияле тәрбияче..**

**Калфагымның чит-читләре ука белән чигелгән...**

**( декоратив рәсемләү)**

**Максат:** калфакларның популяр композицияләрен ачыклап,чәчәк бәйләмен төгәл ясарга өйрәтү; тасма-бизәкне ныгыту.

-милли киемгә, татар халык орнаментына карата кызыксыну уяту ; һөнәрчелек эшенә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү, балаларның эстетик зәвыгын үстерү.

-балаларның бәйләнешле сөйләмен үстерү, сүзлек запасын баету, яңа сүзләр кертү: ука, сәйлән, нәкыш.

**Җиһазлау**: ак калфак силуэты, сары гуаш, пумалалар; музей экспонаты-калфаклар.

**Шөгыль барышы.**

- Балалар без бүген рәсем шөгыләндә чын рәссамнар, бизәүче осталар булырбы. Кемнәр алар рәссамнар, алар нишли? (рәсем ясыйлар, бизәк төшерәләр, сәнгать әсәрләрен иҗат итәләр.)

( Ишек шакыйлар. Татар халык киемендәге курчак малайны алып тәрбияче керә.)

- Балалар, кем безгә кунакка килгән? ( Татар малае.) Ул миңа бик таныш күренә. Ул нәрсәдер әйтергә тели бугай ( тәрбияче курчакны "тыңлый" ) Малай исеменнән сөйли.

- Мин Габдулла Тукайның " Су анасы" әкиятеннән килдем.

"Исегездәдер, мин бер заман су анасыннан
Аалтын тарак урлап кайттым, шуннан ,
Озакланмый су анасы безнең өйгә килде.
И орышты , бик орышты әни шуңа мине.
Шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
Я иясе юк дип, әйберләргә тими башладым.
Тик бу хәлне су анасы онытмады.
Өебездән бик күп әйберләр югалды.
Бер заманны, эссе һава, мин су керәм
Чү, басмада су анасын тагын күрәм.
Тоткан ул бер кулына алтын тарагын,
- "Әгәр бик күп калфаклар бизәп китерсәң син миңа,
Кире бирермен әниеңнекен мин сиңа!"
Ах, харап эш! Ничек итеп калфаклар бизәргә?
Ярдәм сорап килдем, дуслар, мин сезгә."

- Әйе, хәл яхшыдан түгел, тик кайгырма, без бүген калфаклар бизәргә җыелдык. Балалар, сез әзерме малайга ярдәм итәргә. .

<u>Психогимнастика.</u>

- Балалар, малайның начар гадәте өчен ачуланыйк, орышыйк, ә хәзер елмаегыз, гаҗәпләнегез. Күзләрне зур итеп ачыгыз, нык итеп йомыгыз, күзләрне ачып елмаерыз.

- Ә хәзер, ачыклыйк әле, нәсә соң ул калфак? (татар хатын кызларының баш киеме.)

- Әйе, элекке заманнарда хатын кызларга баш киемсез йөрергә ярамаган. Шуңа күрә хатын кызлар үзләренә матур милли баш киеме – калфакны уйлап чыгарганнар. Аны кызыл, яшел, зәңгәр, чия төсендәге бәрхет тукымалардан теккәннәр. Аларга уку (алтын, көмеш җепләр), сәйлән (бисер) белән искиткеч матур, нәфис бизәкләр чиккәннәр. Калфакларның бизәкләре төрле-төрле булган. Иң киң таралган композиция – чәчәк бәйләме, бодай башагы, йолдыз, ярым ай мотивлары.

Бәрхертләрдән тегелгән,
Ука белән чигелгән.
Нәкышләре көмешләргә,
Алтыннарга күмелгән, -

дип шигырьләр дә иҗат иткәннәр. ( Ука, нәкыш, алтын-көмеш сүзләре аңлатыла. Ука – алтын-көмеш җепләр. Нәкыш – бизәк дигән сүз, алтын-көмеш – кыйммәтле металлар. Нәрсәләр алтын- көмеш була? Әңгәмә барышында калфак рәсемнәре, иллстрацияләр күрсәтелә.)

- Сез калфак кигән кызларны кайларда очратканыгыз бар? ( бәйрәмнәрдә үзебез киеп биибез, җырлыйбыз; телевизордан, китаптан...)

- Борынгы калфаклар музейларда саклана. Хәзерге вакытта да калфакчы осталарыбыз бар. Мәсәлән, Рәфана ханым Фәйзуллина, Луиза Фәсхетдинова.

Физкультминут.

- Ямьле илдә без, иң матур гөлләр,
Гөрләп үсәбез, без – бәхетлеләр.
Алсу гөлләргә күмелгән, безнең тирә як.
Алсу гөлләрдән дә матур, безнең бала чак.

Үрнәкнең бизәк композициясен ачыклау., фикер алышу.

- Калфак бизәлешендә татар халык орнаментының нинди элементларын күрәсез? Маңгай өлешендә нинди бизәк? (тасма бизәк: дулкынлы сызык һәм лалә чәчәге. Баш арты өлешендә - чәчәк бәйләме, бәйләмендә ромашка, кыңгырау чәчәк, йөрәк сыман бизәк һәм яфраклар).

Бизәкне ясап күрсәтү.

- Балалар. Без сезнең белән калфакчыклар- калфак бизәү осталары булырбыз. Осталар алтын җепләр белән чиккәннәр, ә без алтынга охшаш сары төс белән бизәк төшерербез. Игьтибар белән мине күзәтегез.

- Пумаланың бөтен өслеге белән маңгай өлешен билгелибез – ике туры сызык үткәрәбез. Поласа эченә дулкынлы сызык сызабыз. Аңа лалә чәчәкләре урнаштырабыз. Чәчәкләрне пумаланың очы белән генә ясыйбыз.

Өске өлештә чәчәк бәйләме урнаша. Уртадан сабак чыгарам. Ике якка симметрияле итеп ике яфрак ясыйм. Сабакны өскә таба дәвам итәм – уртага ромашка бизәген ясыйм. Тагын сабакны дәвам итәм, һәм, симметрияле итеп , ике якка ике сабакта кыңгырау чәчәкләре ясыйм, сабакта икешәр яфрак урнаша. Төп сабакның очына йөрәк сыман бизәкне урнаштырам. Менә чәчәк бәйләмен ясадык. Хәзер пөхтә итеп буярга кирәк.

Балаларның мөстәкыйль рәсемләве.

Тәрбияче малай карчак белән эшләрне күзәтеп йөри, индивидуаль ярдәм күрсәтә, мактый.

Йомгаклау.

- Менә балалар , кунак малае да безнең белән татар бизәге турында белем алды, бизәргә дә өйрәнде дип уйлыйм. Әйдәгез әле, бергәләп тагын бер кат кабатлыйк. Нәрсә белән шөгыльләндек? Калфакны нинди бизәк белән бизәдек? Сезгә калфакларыгыз ошадымы.

Малай: - И балалар, рәхмәт сезгә алтын куллар,
Су анасы, сизәм, көтә. Киттем дуслар.

**Күңел ачу кичәләре.**

**Фәйзиева Р.К.**

**1 категорияле тәрбияче.**

**Җир бәйрәме.**

**(өлкәннәр төркеме өчен музейда үткәрелгән күңел ачу кичәсе)**

**Максат:** 1. Җирнең ничек барлыкка килүе турында мәгълүмат бирү, каен агачының файдасы турында белешмә бирү.

2.Агачлар, йорт кошлары, йорт хайваннары турындагы белемнәрен ныгыту.

3.Татар халык йолалары белән таныштыру. Агачларга,табигатькә сакчыл караш, йорт хайваннарына карата ярату хисе тәрбияләү.

Шөгыль барышы.

Кошлар сайраган тавыш, мал-туар көтүдән кайткандагы тавыш ишетелә. Җырлый-җырлый залга балалар керә.

Җыр “Кунак әби” Г.Гәрәева сүзләре.

Әтәч кычкырып каршы ала.

Шигырь: Бари Рәхмәт, “Бала белән әтәч”.

-Әтәчем! Әтәчем!
Ник иртә торасың?
Йокыдан син безне
Иртүк уятасың.
-Мин ятмыйм – кунаклыйм,
Йокыга бик сак мин.
Төлкедән – карактан
Тавыкларны саклыйм.

- Торасың да иртүк
Кычкырасың бик күп
Кикри-күк, кикри-күк,
Кикри- күк, кикри- күк.
- Мин сиңа кычкырмыйм,
Әбиең торсын дим,
Коймаклар пешерсен,
Самовар куйсын дим.

Җыр “Әтәч” З.Гыйбадуллин музыкасы, Н.Гайсин сүзләре.

Өйдән әби килеп чыга.

- И-и, кунаклар бар икән. Алинә оныгым үзенең дуслары белән авылга әбисе янына кунакка кайткан икән. Исәнмесез , балакайлары.

Алинә: Әбекәй, хәлең ничек, авырмыйсыңмы?

Әби: Шөкер генә әле балакай. Исән-сау гына яшәп ятам. Ерактан килдегез балалар, әйдәгез узыгыз, утырыгыз, азрак ял итеп алыгыз.

( Балалар агач төпләренә утыралар.)

Әби: Менә балакайлар, җир өстенә тагын ямьле яз килде. Табигать йокыдан уянды, бөтен дөнья яшеллеккә күмелде. Мин яз айларын бик яратам.

Хәзер Кәви Нәҗминең “Яз килде” шигырен сөйлим.

Яз килде, яз килде,
Яз тәрәзәдән керде.
Сулар шаулашып ага,
Агачлар яфрак яра.
Көньяктан кошлар кайта,
Сагынып туган якка.
Сыерчыкка ояны
Бик тиз ясап куялар.
Яз килде, яз килде,
Табигатькә җан килде.

1 бала: Ә мин умырзая турында Г.Әхтәмованың шигырен сөйлим.

Язын ява ләйсән яңгыр.
Бөреләр уяналар.
Урманнарда кар астыннан
Калка умырзаялар.

Җырлы-бию “Умырзая”

Кошлар, сыерчык сайраган тавыш ишетелә.

Әби: Балалар,минем ояма яңадан көнъяктан сыерчыклар әйләнеп кайтты, алар иртәдән кичкә кадәр сайрыйлар.

Бала: Әбекәй, ә без “ Сырчык” дигән җыр беләбез.

Җыр “ Сырчык”.

Әтәч: (тибенә,җим эзли) Әбекәй, ә минем өчен җирдәге җимнәрдән дә тәмле нәрсә юк. Җир булмаса мин нәрсә эшләр идем, ни ашар идем, кайда тибенер идем? Әбекәй, ә җир ничек барлыкка килде икән?

Әби: Хәзер мин сезгә җирнең ничек барлыкка килүе турында сөйлим. Тыңлагыз.

Борын заманда дөнья тоташ судан гына торган. Кешеләр әле булмаган. Суда балыклар һәм су кошлары гына яшәгән. Шунда бер үрдәк чума-чума су коенган. Су төбеннән борынына кабып җир кисәге алып чыккан. Шул җир кисәге көннән көн, елдан-ел зурая барып җир хасил булган. Аннары кешеләр , кыргый хайваннар барлыкка килгән. Кешеләр үзләренә файдалы кыргый хайваннарны кулга ияләштереп йорт хайваннары иткәннәр. Җирдә иген игәргә, җиләк-җимеш, яшелчә үстерергә өйрәнгәннәр.

Борынгы бабаларыбыз җиргә табынганнар, аңа җанлы итеп караганнар, аны хөрмәтләп, зурлап төрле йолалар, бәйрәмнәр уздырганнар.

Җир кардан арынгач Җир бәйрәме уздыра торган булганнар. Бу бәйрәмдә киләсе елларның иминлеген-муллыгын теләгәннәр. Җирдә иген мул булып үссен өчен "Җир, җир, көчем бир" – дип сораганнар.

Әтәч: Әбекәй, балалар, әйдәгез әле без дә әбинең ишек алдында Җир бәйрәме үткәрик. Мин җирне бик яратам (тибенә, җим эзли)

- Кик-ри-күк! Кик-ри-күк! Сезнең барыгызны да Җир бәйрәменә чакырам!

Алинә: Әбекәй , ә без җир турында җыр беләбез.

Җыр. "Кара туфрак – Туган җыр" Рус халык җыры.

1 бала: Рәхмәт сиңа , җылы кояш
Якты нурлар сибәсең.
Рәхмәт сиңа, кара туфрак,
Безгә байлык бирәсең.

Әби: Балалар, җир турында мәкальләр дә бик күп бит.

- Җире байның иле бай.
- Җирне сөйгән ач булмас.
- Җирең яхшы булса, амбарың ашлык белән тулыр.

Әби: Җир бәйрәмендә бик күп уеннар уйналган дидек. Әйдәгез әле, без дә уйнап алыйк.

Уен "Утыр, утыр, Мәликә".

Әби: Хәзер менә уртада нинди агач тора, ул кешегә нинди файда биргән? Әйе балалар, каен агачын бик яратканнар, аңа багышлап җырлар җырланган, шигырьләр язылган.

Җыр “Ак каен” З.Ярмәки сүзләре, М.Вәлиев музыкасы.

Әтәч : Кикри-күк! Кикри-күк! Әбинең ишек алды нәрсәгә ошаган?

Балалар: Урманга охшаган.

Әтәч : Ә урманда нинди агачлар үсә соң?

Балалар: Имән, каен, юкә, усак, чыршы. Нарат, тал, шомырт...

(Балалар агач маскалары кияләр)

2 бала: Минем исемем – имән,
Мин күптән яшәп киләм.
Җилләргә, давылларга-
Берсенә дә баш имәм.
3 бала: Минем исемем - каен,
Үсәм һәр урман саен.
Буем үсә бик озын,
5 бала: Ә мин – чыршы, беләсез,
Чыршы булмый энәсез.
Җәен, кышын яшел мин,
Арттырам урман ямен.
Нәни кызлар, малайлар-
Дусларым, якыннарым.
7 бала: Сындырмыйк шомырт агачын
Моңсу булыр урманым
Шомырт кебек елтыр күзле
Ул минем – сез дусларым!
Бергә: Без үсәбез һәркайда
Без кешеләргә файда.

Ак кәгазь кебек тузым.
4 бала: Ә мин юкә исемле.
Юкә ул чәчәк төсле.
Һәрвакытта хуш исле.
Бал кортлары киләләр,
Миңа безелдәп кенә.
Иң тәмле балын җәеп
Алып китәләр сезгә.
Яңа елда аларга
Кунак булып барырмын.
6 бала: Тал бөгелә, тал бөгелә.
Тал бөгелә җилләрдә
Бөгелүчән зифа таллар
Үсә безнең илләрдә.
Шуңа күрә агачларны
Сындырмагыз , саклагыз!
Аланнарга., урманнарга
Агачлар утыртыгыз
8 бала: Саклагыз табигатьне!
Агачлар да куаклар да
Матур булып үссеннәр.

Исән-имин үсә алар
Кешеләр тимәсеннәр.
Шуңа күрә бөтен кеше
Сакласын табигатьне
Кечеләр дә, олылар да
Бозмасын булган ямьне.

Уен "Без дә" ( Әтәч уйната)

Әтәч : Карагыз әле, әбинең ишек алдында нинди йорт хайваннары яши соң?

Балалар: Ат, сыер, сарык, каз, тавык, чебиләр, эт, мәче.

Ә хәзер без сезгә Роберт Миңнуллинның " Безнең авыл зоопаркы" дигән шигырен башкарабыз.

1 бала: Шәһәр малайларының күргәне юк гомергә
Бездәге җәнлекләрне, бездәге кош-кортларны.
Теләсәләр күрергә,
Килсен алар авылга. аптырашта калырга!
Алар бездә өй саен, күреп була көн саен.

2 бала: Атлар бездә көн буе кешегә эшләшәләр.
Колыннар да туйганчы уйныйлар, тешләшәләр.

3 бала: Әтәчләр һәм тавыклар тары чүпли савыттан
Ә сарыклар,бәрәннәр киртәгә сыенганнар,бергәрәк җыелганнар
Чебешләр һәм бәбкәләр, качып канат астында йокларга җыелганнар

4.Бирегә кайчагында мәче дә кереп чыга,
Биредәге дусларын маэмай да күреп чыга.

5. Авылыбызда өй саен менә шундый зоопарк,
Зоопарктан ким түгел, безнең дә абзапарк!.

Әби: И-и-и-,балакайларым,бигерәкләр дә матур итеп сөйли беләсез икән! Авылда яшәүче әбиләрегезне дә сагына торгансыздыр инде? Менә минем дә оныгым нәкҗ сеәнең кук, и сагынам да инде үзен.Оныты плар торам икән , тәмле итеп коймаклар пешереп куйган идем бит мин.

Әби балаларны коймаклар белән сыйлый Бәйрәм тәмамлана).

**Гәрәева И.С.**

1

**категорияле тәрбияче..**

**Капка төбендә кичке уен.**

Авыл күренеше. Уртада капка. Капка артында өй күренә. Уңда кое. Сулда өй. Өй эчендә өстәл. Өстәлдә самовар, чынаяклар.

Кыз белән малай керә.

Кыз*:* Әйдә, безгә килегез!
Түребезгә үтегез!
Кунак булып китегез!
Бергәләп ял итегез!

Малай*:*Күмәк бию,уен-көлке,
Була кичке уенда.
Кызлар,егетләр җыела
Бүген капка төбендә.

- Лиана, бүген кичке уенга чыгасыңмы?

Кыз*:* Әйе. Көтү кайткач , әнигә малларны җыярга булышам да, чыгам. Ә кайда җыелабыз соң?

Малай: Әлмәндәр бабайларның капка төбендә. Мин югары очларны чакырам.

Кыз: Ә мин түбән очларны чакырыйм.

(Чыгалар. Урамда көтү кайткан тавыш ишетелә. Малай тавышы: -Кызлар, егетләр, әйдәгез кичке уенга!)

Көянтә-чиләкләр асып, әби керә. Чиләкләрен өй янына куя.

Әби*:* Әлмәндәр, Әлмәндәр дим! Тизрәк чык әле! Анда нишләп йөрисең?

Әлмәндәр*:* Оча белмим инде, аяк белән йөрим. Ник карыйсың?

Әби*:* Күңелемә ярыйсың.

Әлмәндәр*:* Ник?

Әби: Син ни әйтер дип. Әлмәндәр, хәтерлисеңме, теге чакта, ясаган идең капка. Син ясаган шул капка шыр ачык ике якка. Мин сиңа бик ачулы, шундый капка буламы? Ачылуын ачыла, ә менә ябыламы?

Әлмәндәр: И, җанкисәгем. Бигрәк вакланасың син. Күңелебез ачык икәнне кешеләр күреп китсен. Капкалары ачык ич, дип, кереп хәл белеп китсен. Өенә күрә капкасы, чиләгенә күрә көянтәсе.

Әби*:* Әй, кара инде моңа, гомер буе акыл керә белмәде. (өйгә кереп китәләр.)

Бер ишектән малайлар, икенче ишектән кызлар кереп, кара-каршы басалар.

Малайлар*:* Исәнмесез, саумысыз,
Нигә кәҗә саумыйсыз?
Әтәчегез күкәй салган,
Нигә чыгып алмыйсыз?

Кызлар: Әй, Әпсәлам, Әпсәлам,
Сәлам бирдек, Әпсәлам!
Сездән безгә тиештер бит.

Малайлар: Вәгаләйкемәссәлам!

Кыз*:* Шуннан?

Малай: Утырган да шуган!

Кыз: Шуннан?

Малай: Тугыз ким уннан!

Кыз: Шуннан?

Малай: Кишер белән суган!

Малай: Әйдәгез, бер уйнап алыйк!

Кыз: Нинди уен уйныйбыз?

Малай*:* Әйлән-бәйлән уенын!

Әйлән-бәйлән уены. “Уртага чык”.

Түгәрәктә бергә җырлап әйләнәләр.

Без бәхетле шат балалар.
Уйныйбыз әйлән-бәйлән.
Айрат, әйдә чык уртага,
Кемне сайларсың икән?

Айрат түгәрәк эчендә җырлап йөри. Кыз янына килә.

Алена янына киләм,

Аңа кулымны бирәм.

Әйдә, дустым, чык уртага

Бергә биибез, диям.

Райнур, Марат уртага чыгалар. Зиләне, Миләүшәне чакырып, әйләнәләр.

Уен барганда әби белән бабай, өйдән чыгып, карап торалар.

Бабай: И, күрмичә дә торабыз. Безнең капка төбенә яшь балалар күңел ачарга килгәннәр икән.

Әби: И-и, сөбханалла, балаларга күз тимәсен, барысы да бии, барысы да җырлый. Чып-чын артист диярсең.

Бабай: Бераз шаяртып алыйм әле, үзләрен.(малайларны үрти)

"Үртәвеч" уены.

- Пәрәмәч дип әйт әле!
- Пәрәмәч!
- Ике күзең тәгәрмәч!
- Сөт дип әйт әле!
- Сөт!
- Борын астыңны сөрт!
- Көлегез, көлегез, көл капчыгы тегәрбез.

Әби: Көлмә кешедән, авызың өшегән.

Бабай: Көлмәгез!

Балалар: Елыйкмы!

Бабай: Еламагыз, җырлагыз!

Менә мондый такмакны беләсезме?

Җырларга да мин оста,

Биергә дә мин оста,

Эти-әни эшкә кушса,

Мин авыру, мин хаста.

Малай: Без андый малай түгел,

Без мондый малай түгел,

Кая барсак та ярыйбыз,

Күгәргән калай түгел!

Бабай: Әнә килә автомобиль,

Төягәннәр йомычка.

Җырларга җыр табалмасаң,

Биреп торам бурычка.

Әби: Нишләп синнән бурычка җыр алсыннар ди алар. Үзләре дә күп беләләрдер әле, әйе бит, балалар! Әйдәгез, бабагызга такмаклар җырлап күрсәтегез әле.

Такмаклар җырлау.

Кыз: Кердем алма бакчасына,

Алма җиргә коелган.

Җырламыйча түзә алмыйм,

Җыен дуслар җыелган.

Балалар: Бакчаларда ике түтәл,

Берсен суганга күтәр.

Җырласаң, шатлыгың арта,

Җырлап күңелең күтәр.

(тыпырдап әйләнәләр).

Кыз: Җырла, җырла, дип әйтәсез,

Җыр чәчмәдем бакчага.

Җыр чәчмәсәм дә бакчага,

Сатып алмыйм акчага.

Балалар: Аклы ситсы күлмәк тектем,

Ләкин калмады ише.

Ялкаулык башка төшә ул,

Ялкау булмасын кеше.

(тыпырдап әйләнәләр).

Бабай: Вәт ичмасам, муладислар. Дөрес әйтәсез, оланнар.

Ялкау булмасын кеше.

Яманны яман көтә,

Эшләмәсәң, рәхәт китә.

-Менә без карчыгым белән гомер буе эшләдек тә, күңел дә ача белдек. Әле шул арада әбиегез матур-матур сөлгеләр чигәргә дә өлгерә иде. Йөзембикә, карчык, чиккән сөлгеләреңне алып чык, балаларга бүләк ит әле.

Әби: Әйе шул, бер истәлек булыр.

Әби сөлгеләр алып чыга, балаларга күрсәтеп сөйли:

Чиккән сөлге – бүләк балаларга,
Күзләремнән күчкән нурларым.
Ничәмә төс, ничәмә җыр анда –
Һәр төсендә минем кулларым.

Ефәк җепләр белән сөлге чиктем.
Уртасында чәчәк, гөл генә.
Шушы сөлгеләрем белән, кызлар,
Биеп бирегезче бер генә.

Сөлгеләр белән бию.

Әби*:* Менә рәхмәт, балалар, күңелемне күрдегез.

Бабай: Кара әле, кара әле бу малайларны-шаяннарны: кашыклар кыстырып килгәннәр. Әллә ботка ашарга дип килдегезме?

Әби: И-и, нишләп ботка ашасыннар ди инде алар. Хәзерге балалар агач кашыклар белән ашамыйлар, ә уйныйлар.

Кашыклар белән бию.(оркестр).

(2 кыз, 2 малай бии. Малайларда 2шәр кашык, ә кызларда бубен, 2 урындык кирәк).

Бабай: Капка төбенә килгәнсез, ә “капкалы” уенын беләсезме соң?

- Нинди уен ул, бабакай?

Бабай: Әйдәгез, өйрәтим әле үзегезгә. Парлашып, почмакларга басыгыз. 1 пар уртада калсын. Уртадагы пар капкаларга кереп-чыгып, биеп йөри. Музыка туктатуга, кайсы пар уртада кала, шуңа җәза бирелә. Алар үз һөнәрен күрсәтергә тиеш.

Капкалы уены.

1 пар. Уртада кала.

Такмаклар җырлыйлар.

Иртән торып тышка чыксам,

Кырмыска утын кисә.

Кара сарык гармун уйный,

Сыер танцевать итә.

Сезнең дә бар мәчегез,

Безнең дә бар мәчебез.

Безнең мәче сезгә килсә,

Зинһар, ишек ачыгыз.

2 пар. Тизәйткеч әйтә.

Эчтем, эчтем, су эчтем,

Чәй эчмичә, су эчтем.

Чәй эчмичә, су эчкәнгә,

Бик авырта шул эчем.

Табышмак әйтә.

Ике туган су коенырга киттеләр. (чиләкләр).

3 пар. Бармак уены.

- Монда май бар иде.

Май кая киткән?

- Песи ашаган.
- Ә песи кая киткән?
- Салам астына кереп киткән.
- Ә салам кая киткән?
- Сыер ашаган.
- Ә сыер кая киткән?
- Көтүгә киткән. Төбәй! Төбәй! Төбәй!

Парлы бию. “Чабата белән яулык.”

4 пар. *Җыр. “*Кәтүк түти.”

Керәшен халык киемендәге кыз башкара.

Малай татарча бии.

Кәтүк түти, иртүк торып,

Суга киткән.

Кайтып җиткәч, йыгылган да

Суын түккән.

Кәтүк түти, ник җылыйсың

Авызың җәеп?

Синдә түгел кызларда да

Була гаеп.

Кәтүк түти, тәҗел-тәҗел

Кая бардың?

Марҗый тутаң туйга киткән,

Сыерын саудым.

Кәтүк түти, иртүк торып,

Мичкә җаккан.

Утыны чи булгангамы,

Җанмый җаткан.

Кәтүк түти, йөри торгач,

Алҗып беткән.

Хәл алырга утырган да,

Йоклап киткән.

5 пар. Кыз шигырь сөйли.

Ботка да, ашта та

Бик тәмле.

Каян шундый тәм икән?

Әһә, белдем, үзе шундый

Тәмле икән тәлинкәм!

Б:абай Ә бу егетне әтәч булып кычкыртыйк.

Малай*:* Кик-ри-күк! (3 тапкыр әтәч тавышы ишетелә башлый).

Әби: И, сизми дә калганбыз. Таң ата бугай. Балакайлар, сезгә дә кайтырга вакыт.

Бабай: Рәхмәт, балалар! Безнең күңелне ачтыгыз. Яшь вакытларны искә төшердегез. Туган телебезне онытмагыз, уеннарыбызны рәхәтләнеп уйнагыз.

Адаштырмас маягыбыз – мирас,

Юлда юлдаш – туган телебез.

Туган телне, җирне сөйсәк кенә,

Матур булыр алгы көнебез.

Тормышны яратыйк, дуслар!

Бәхетле булыгыз!

Карчык, ә син балаларны коймаклар белән сыйлап җибәр.

**Олы көн.**

**( “Керәшен фольклорына” багышланган ял кичәсе.)**

Кичә кассетага яздырып алынган керәшен көен тыңлау белән башлана.

Алып баручы: И керәшен карендәшем минем,
Халкымның бер асыл бизәге.
Синең көйне бер тыңлаганнарның
Гомерлеккә өзелә үзәге.
Арумысез, кадерле дуслар, туганнар!

Бәйрәмебез күңелсез бит,
Күңелсездер сезгә дә,
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә
Кирәк барыбызга да.

Керәшен халкы нинди генә авырлыклар кичерсә дә үз асылын, борынгы үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, җыр-моңын, телен бүгенгә кадәр китереп җиткерә алды. Без бүген сезгә бик олы бәйрәмнәрнең берсе булган “Олы көн” бәйрәменә чакырабыз. Бу бәйрәм керәшен халкының барысының бик яраткан, көтеп алган бәйрәме. Бәйрәм җиткәнче өйләрне юалар, матур пәрдәләр коралар.Күкәй маналар. Олы көнгә каршы урын җәеп йокларга ятмыйлар. Сәгать 12 тулып узгач , балалар күкәй җыя башлый.

Әби: Әй, Питер дим, Питер! Тиздән балалар күкәй җыярга керерләр. И-и-и искә алырга гына калды ул вакытларны, рәхәтлекне, бәхетле чакларны.

Бабай: Әйе, Наташа , шулай!

Ишек шакыйлар, балалар керә. Исәнләшәләр.

Әби: Арумысыз, балалар! Питер дәдәгез белән көттек без сезне. Балалар! Без бәләкәй чакта черли белә идек. Сез черли беләсезме? Белсәгез әйдә әле, черләп күрсәтегез әле.

Малай: Чер-чер малларыгыз күп булсын,
Абзар тутырык булсын.
Чер-чер, тавыкларыгыз күп булсын,
Колга тутырык булсын.,
Көн саен салып торсын,

Чер-чер-чер.

Әби: Менә балалар, сез болай черләгәч малларыбыз да , тавыкларыбыз да күп булыр. Килегез әле балалар, күкәй салыйм янчыкларыгызга.

Балалар: Рәхмәт сезгә, сау булыгыз, исән-сау гына яшәгез.

( Балалар чыгып китә)

Әби: Менә балалар күкәй дә җыйды. Печтә ягып коймак пешерергә кирәк. Тиздән күрше авыллардан бәйрәмгә килә башларлар.

( Әби белән бабай чыгып китә).

1 бала : Карап тормый ара еракка,
Дуслар килә безгә кунакка.
Дуслык безнең тормыш үзәге,
Дуслык безнең бәйрәм бизәге.

Җыр "Ай әле бик еракта идек без"

2 бала : Җырлый әле, җырлыйк әле.
Җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаган күңел,
Мәңге ачылачак түгел.

Җыр: "Әкрен кирәк. Иплэп кирәк."

Алып баручы: Әйдзгез, балалар,күңелле итеп бер уйнап алыйк әле.

3 бала: Безнең ялан күлле-күлле.
Ясле бакчасы гөлле,
Ясле бакчалары гөлле.
Уйнаулары күңелле.

Уеннар. 1. Күкәй тәгәрәтеш.
2. Күкәй кабып йөгерү.

4 бала: Нинди җыр ул ишетелә таулардан,
Ишетелә җиргә эллә кайлардан,
Күңелләрне айкандыра, кузгата,
Матур уйлар, татлы уйлар уйната.

5 бала Биючеләр биегәндә идәннәре

бөгелә,

Ярышларда җиңеп чыктык,

Керәшен халык биюе.

Безнең биисе килә.

6.

Җирдә нинди илләр юк,
Нинди генә телләр юк,
Һәркем сөйли үзенчә.
Сөйләшсәләр безнеңчә

Эреп китәм май кебек.
Йөзем тулган ай кебек,
Яктырганнан яктыра
Күңелдә таң аттыра.

Григорий Радионов шигырьләре укыла:

1. “Койрыклы балыклар”
2. “Нәни өйдә, нәни җыр”.

Алып баручы : Күңелле итеп җырладык, биедек, әйдәгез бергәләп рәхәтләнеп бер уйнап алыйк.

Уен “Йөзек салыш”.

( Төрле милләт киемнәре кигән кунаклар - балалар килеп керә. Кунаклар һәм балалар капма-каршы такмак җырлыйлар. )

1. Кенәген дә бергә-бергә,
Бүген дә бергә-бергә,
Иртәгә дә бергә-бергә,
Берсе көнгә дә бергә.

2. Тыпыр-тыпыр тыпырдашып,
Бергә басыйк әле.
Уйнап көлеп, җырлап биеп,
Күңел ачыйк әле.

3. Уйныйбыз да җырлыйбыз да.
Гармун кулларыбызда.
Алсу гөлләр чәчәк атсын.
Йөргән юлларыбызда.

7 бала: И дусларым сезнең белән,
Шат минем күңелләрем.
Тагын шулай шатлык белән,
Үтсә иде гомерләрем.

Алып баручы: Без ныклы, тырыш, уңган, хезмәт , дуслык сөюче керәшен халкы. Нинди генә җил давылда да үзебезнең гореф-гадәтләрне саклап калуыбыз белән горурланабыз. Һәрвакыт шулау дус һәм тату яшәргә язсын.

Бергә яшәү, бергә яшәү ,
Бергә яшәү күңелле.
Бергә яшәүләр күңелле,
Шул күтәрә күңелне.
Җыр “Яратам”.

**Йомырка бәйрәме.**
**(өлкәннәр төркеме)**

Бала: Май аеның ни икәнен
Белми торгансыздыр әле.
Безнең якта – май ае,
Күкәй җыю бәйрәме.
Һәрбер йортта иртә таңнан
Төсле күкәйләр пешә.
Иң матуры, иң өлгере
Кем беренче җитешә?
Өйдән-өйгә йөреп шулай,
Күкәй җыя һәр бала,
Менә шушы күркәм йола,
Күкңй бәйрәме була.

Алып баручы: безнең бабаларыбызның онытыла торган бәйрәмнәре, аларның гореф-гадәтләре, ниһаять яңадан әйләнеп кайта башлады. Татар авылларында яз айларында йомырка бәйрәме уздырганнар. Шул көнне балалар өйдән-өйгә,йомырка җыйганнар. Бу көн турында халыкка алдан үк белдерткәннәр, шуңа күрә хуҗабикәләр кичтән йомырка кызартып күчтәнәчләр әзерләп куя торган булганнар. Иртән сабыйлар- “ Аягың җиңел булсын”-дип тели-тели,авыл буйлап өй саен кереп йөргәннәр. Бер үк вакытта алар күршеләре,туганнары, авылдашлары белән танышканнар.Өлкәннәр дә

сабыйларны сыйлаганнар...кем баласы исәнләшә һәм рәхмәт әйтә белә, кыюлы,зирәкле,аның үз-үзен тотышы турында белешкәннәр.Җыелган йомыркаларны кырга алып чыгып,балалар төрле уеннар уйнаганнар, сыйланганнан калган йомыркаларны җир өстенә сибеп киткәннәр. Шулай иткәндә,игеннәр мул була,ел җиңел килә дип уйлаганнар. Ә хәзер безнең йомырка бәйрәме башлана..

Әби: Кызларым, бүген яшьләрне , балаларны йомырка җыярга чыгаралар дип әйткәннәр иде. Күчтәнәчләрне әзерлим әле.(Балаларның җыр тавышы ишетелә).

Кызлар: Килеп җитәләр ,ахрысы. (Балалар ишек шакыйлар)

Бала: Кыт-кытыйк, кыт-кытыйк, әби-бабай өйдәме?

Әби: Өйдә,өйдә!Әйдәгез,түрдән узыгыз,сезне килерләр дип көттек.

Бала: Әссәламегаләйкүм йорт хуҗалары!

Әби-әби-әбекәй, җетрәк бир безгә күкәй.

Безгә бирсәң өч күкәй, тавыгыгыз салыр йөз күкәй.

Әби: Мәгез,мәгез, сезгә дип әзерләп куйдым.

Бала: Табакка каймак кирәк,

Май,күкәй,каймак кирәк.

Күмәчең дә кызганма,

Озак яшә,сызланма. ( Әби күчтәнәчләр бирә)

Алып баручы: Балалар , сый-хөрмәт күп җыелдымы? Күрсәтегез әле?

Бала: Безне бик зурладылар, сый-хөрмәт күп җыелды.Еллар тыныч,уңышлар мул булсын,тазалык,саулык белән яшәргә язсын.

Бала: Әбекәй,безгә сезнең өйдә күңел ачарга,жырлап-биергә рөхсәт итмәсезме икән?

Әби: Балалар,рөхсәт, рөхсәт. Бергә күңелле булыр.

Бала: Рәхмәт,әбекәй,әйдәгез күңел ачабыз.

“ Эх,күңел ачабыз” татар халык җыры.

Бала: Йорт хуңалары бик матур биеделәр.Менә сезгә күчтәнәчләр.(йомырка бирә)

Бала: Кашык кабып йөгерәм дип,мактанырга ашыкма.

Син менә йөгереп кара,күкәй салып кашыкка.

Уен “ Кашыклы йомырка”.

Тәрбияче:Әйдә дуслар килегез,күңел ачу көнебез.

Татарча матур итеп, биибез дә җырлыйбыз.

Уен “ Эх, Зиләм-Зиләйлүк”.

Әби: Балалар,сез бик матур итеп җырлыйсыз да,биисез дә икән. Минем дә яшь чакларым исемә төшеп китте.(Ишек шакыйлар-Гөлчәчәк керә)

Гөлчәчәк: Исәнмесез,балалар.Бәйрәмгә соңга калам дип торам.Матур җырларыгыз, шат тавышларыгыз урамга ишетелеп тора.

Алып баручы: Гөлчәчәк,түрдән уз,бергәләр бәйрәм итәрбез.

Балалар: Әйдәгез” Капкалы”уйныйбыз.

( Уен “Капкалы”)

Бала: Гөлчәчәк,син бик матур кәрзин алып килгән идең.Аның эчендә нәрсәләр бар соң?

Гөлчәчәк: И-и-и,балалар! Онытып та торам икән.Мин бит сезгә бик матур уеннар алып килдем.менә түбәтәй.

(“Түбәтәй”, “ Кульяулык”уены.)

Бала: Э хәзер “ Яшьләр уены”уйныйбыз. Кызлар,малайлар ,капма-каршы тезелеп басыгыз.

Челтәр элдем читәнгә,

Челтер-челтер итәргә.

Мин килмәдем буш китәргә

Килдем алып китәргә.( Уен кабатлана)

Бала: Җырларыбыз юлдаш булсын, яңгырап торсын,

Эшләрегез уңган булсын,

Илебезне бизәп торсын.

“ Матур булсын” җыры башкарыла.

Әби: Кадерле балалар. Минем сезгә зур үтенечем бар.Табигатьне саклагыз, елгаларның суы саекмасын,болыннарыбыздан киек казлар китмәсен.

Гөлчәчәк: Әби-бабайларга, яклаучысы булмаганнарга ярдәм итегез.
Дөньялар тыныч булсын,зәңгәр күкне болыт капламасын.Үләннәр һәрчак яшел торсын,игеннәр һәрчак мул уңыш бирсен.Барлык изге теләкләребез кабул булсын.
Балалар: Амин,шулай булсын.
Жыр “Кояшлы ил”.

**Әкияткә сәяхәт.**

**Максат:** -балаларның хайваннар, кошлар, үсемлекләр турындагы белемнәрен ныгыту, иҗади күзаллауларын үстерү, уйлау сәләтен ныгыту;
-сөйләм телен баету;
- “ш”,”ч” авазларының дөрес әйтелешенә ирешү.” Йомры икмәк” әкиятен искә төшерү,әкият уйнарга өйрәтү, бирелгән рольләрне килештереп, охшатып уйнауларына, дөрес итеп, кычкырып, тулы җөмлә белән җавап бирүләренә ирешү;
-балаларның күңел ачу кичәсендә актив катнашуларына, кәефләренең күтәренке булуларына ирешү.

**Шөгыль барышы:**

(“Матур булсын” җырының көе уйнатыла.)
Тәрбияче: Тыңлагыз әле,балалар. Нинди көй икән ул? Эйе,әкият иленнән килә шундый серле, тылсымлы көй. Балалар без дә әкият иленә кунакка барабызмы?... Ә нәрсәгә утырып барабыз? ( Балалар җавабы-атта, велосипедта,самолетта...Хәрәкәтләр ясала, музыка уйный. Тәрбияче урман рәсеме элә, кошлар тавышы белән кассета куела) Балалар,без кая килеп җиттек?
Балалар: Урманга.
(Тәрбияче кошлар тавышына игътибар иттерә, урманда нәрсәләр яшәгәне турында әңгәмә уздыра)

Тәрбияче: Безнең барасы юлыбыз ерак. Әйдәгез сәяхәтебезне машинага утырып дәвам итик.(балалар утырган килеш машинада барган хәрәкәтләр ясыйлар)

Тәрбияче: Карагыз әле , балалар,кая килеп җиттек без. Нәрсә бу? (чишмә рәсеме,су агышы ишетелә)

Балалар: Бу чишмә.

Тәрбияче: Бик дөрес, бу чишмә. Бу тылсымлы чишмәдер, изге чишмәдер. Әйдәгез әле юынып алыйк. (“Йомшак су,йөгерек су” шигыре укыла,балалар шигырьнең сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар,” чишмә “суы эчәләр)

Тәрбияче: Ә хәзер сәяхәтебезне ,балалар ,поездга утырып дәвам итик. Поезд нинди тавышлар чыгара? Әйе, “Ч” ди поезд.( “Ч” авазының дөрес әйтелеше кабатлана. Йорт янында тукталалар)

Тәрбияче: (Сәерсенгән кыяфәт белән) Бу нинди йорт икән? Кем яши икән анда? Әйдәгез шакып карыйк!

Әби: И.....кемнәр килгән безгә? Исәнмесез, балалар? Әкияткә кунакка килдегезме? Бик яхшы. Әйдәгез,утырыгыз, мин сезгә әкият сөйлим. Ә, әкиятнең исемен үзегез белегез, мин сезгә табышмак әйтәм.

Үзе түгәрәк,үзе тәмле,

Аш белән дә ашыйлар, чәй белән дә ашыйлар.

Балалар: Йомры икмәк.

Әби: Әйе,балалар,йомры икмәк. Әйдәгез әле йомры икмәкне бергәләп пешерик.

Әби: Балалар, ипи пешерү өчен нәрсә кирәк?

Балалар: Күкәй. (Әби күкәйне кәсәгә сыта, балалар һәрбер хәрәкәтне һавада куллары белән күрсәтәләр)

Әби: Тагын нәрсә кирәк?

Балалар:Су,

-Он,

-Болгатабыз,

-Камыр басабыз.

Әби: Түгәрәк булсын ,тәмле булсын, хуш исле булсын...Мичкә тыгыйм.(Мич эчендә битләре ясалган, яулыклар бәйләнгән туп куеп калдырылган була) Балалар, әйдәгез әле, ипи пешкәнче “Бармак”уены уйнап алыйк.

Баш бармак – бау ишә,

Имән бармак-имән кисә,

Урта бармак – ут яга,

Атсыз бармак ат җигә.

Чәнти бармак-чәй эчә.

Ярый, балалар,ипидә пешкәндер. Карагыз, әле, балалар, нинди тәмле булып пешкән безнең ипи. Матурмы, түгәрәкме, хуш ислеме, кайнармы безнең икмәк? (Балалар җавап бирә) Тәрәзә төбенә куеп торыйк,суына төшсен икмәгебез.( Йомры икмәк тәрәзә төбеннән тәгәрәп китә.Тәрбияче икмәкне алып хәрәкәтләр ясый)

Тәрбияче: Бара икән йомры икмәк тәгәрәп, бара икән...Аның каршына килеп чыккан...

Балалар: Куян (Куян костюмы кигән бала сикерә-сикерә йомры икмәк каршына килеп баса)

Куян: Мин куян, мин сине ашыйм.

Балалар: ( бармакларын болгап,бертавыштан)

Ашама, куян , ашама!

Тәрбияче: Күрәсезме, куян, балалар ашама диләр. Без сине үзебез сыйларбыз. Син йомры икмәккә тимә. Балалар , әйтегез әле, куян нәрсә ярата? ( Балалар җавап бирә.Тәрбияче кәрзин белән яшелчәләр алып чыга, аларны берәм – берәм балаларга күрсәтә. Яшелчәне дөрес атаган бала куянны кишер белән сыйлый)

Тәрбияче: Куян сыйланды, әйдәгез, аңа җыр бүләк итик. “ Ак куянкай” җырын җырлап ишеттерик әле.

(Әкият дәвам итә. Аюга –татар халык биюе, бүре белән “ Җиләк җыям “уены оештырыла. Төлке киеме кигән бала керә.)

Төлке: Мин төлке, хәйләкәр төлке. Ә син нәрсә?

Йомры икмәк: Мин - йомры икмәк.

Төлке: Син нинди матур, хуш исле! (Йомры икмәкне ялый, иркәли) Әле син матур итеп җырлый да беләсеңдер?

Йомры икмәк: Әйе, мин хәзер сиңа балалар белән “Песи-нечкәбил” дигән бик матур җыр җырлап күрсәтәм. (Балалар җырлый)

Төлке : Кил әле  якынрак, җырла әле тагын беркат, минем колакларым бик начар ишетә.

Тәрбияче: Балалар,бирикме йомры икмәкне төлкегә?

Балалар: Юк,ул аны ашый.

Тәрбияче: Әйдә, төлке, алайса,уйнап карыйк .Йомры икмәкне куып тота алсаң сиңа бирербез. (Балалар түгәрәккә басалар, түгәрәк икмәкне кулдан – кулга күчерәләр,музыка уйный)

Төлке: Уф, арыдым, ярар инде,алайса, ашамыйм.  Миңа сезнең белән калырга рөхсәт итегез.

Тәрбияче: Балалар,калсынмы?

Балалар: Калсын,калсын. ( Әби килүе күренә)

Тәрбияче: И, кем килә анда?  Әби түгелме? Әйдәгез әле йомры икмәкне яшерик. (Икмәкне агач артына яшерәләр)

Әби: ( Елый-елый) И-и балалар,тәмле итеп ипи пешергән идем, ипием өйдән чыгып качкан. Сез күрмәдегезме? ( Бер бала йомры икмәкне табып китереп бирә)

Бала:  Мә,әби, икмәгеңне.

Әби: Рәхмәт, балакаем.

Тәрбияче :  Әбекәй, синең күңелеңне күтәрер өчен “ Яратам” дигән җыр җырлап күрсәтик әле.

Әби: И-и-и,балалар,рәхмәт инде.менә шуның өчен мин йомры икмәкне сезгә калдырам. Бергә уйнагыз, җырлагыз,биегез. Әле минем сезгә дип пешергән коймакларым да бар. ( Әби балаларны коймаклар белән сыйлый).

**Гареева И.С.**

**1 категорияле тәрбияче.**

**Комплекслы шөгыльләр.**

**Миркасыймова Г.Г.**

**1 категорияле**

**әрбияче.**

**Тема:”Маһруй әбидә кунакта”.**

**Максат:** бүгенге көндә әби-бабаларыбызның мәгънәле тормышын, гореф-гадәтләрен балаларның күңеленә салып калдыру. Халкыбызның телен хөрмәт итү, җыр-уеннарына мәхәббәт тәрбияләү, балаларның зирәклеген артыру, баету. Әби-бабаларыбыз иҗат иткән әйберләргә хөрмәт тәрбияләү.Татар халык бизәкләре белән танышуны дәвам итү һәм кызыксыну уяту. Үсемлек мотивларыннан бизәк төзергә, элементларны бер-берсенең эченә урнаштырырга өйрәтү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Сүзлек өстендә эш:** кулъяулык, лалә.

**Җиһазлар:** музейдагы өй күренеше. Магнитофон, кассета, сандыкта кулъяулыклар, ябыштыру өчен кирәкле әйберләр.

**Шөгыль барышы:**

Т.- Балалар, без хәзер Маһруй әбиләргә кунакка барабыз.

Музей ишеге төбендә ишек шакыйлар. Ишекне ачучы юк,эчкә керәләр.

Исәнмесез-саумысыз... (исәнләшәләр)
Нигә ишек ачмыйсыз?
Шакый-шакый арып беттек
Нигә каршы алмыйсыз?

Бабай килеп чыга. Исәнләшә.

Б.-Исәнмесез, балалар. Кайсы бакчадан килдегез?

Б-р.-“Салават күпере” бакчасыннан, “Кояшкай” төркеменнән.

Б.-Һай, балакайларым, әйдүк, әйдүк, түрдән узыгыз, утырыгыз. (утыралар).

Т.-Әбекәй”безгә вакытыгыз булганда кунакка” килеп чыгыгыз, дигән иде.

Б.-Рәхмәт, рәхмә, килеүгезгә, әйдәгез әле, йортка дога кылып алыйк.

(Бабай ике учын йөзенә якын китереп дога кыла.)

Т.(әкрен генә аңлата)-Балалар, бабабыз үзенең догасы белән бу йортның нигезенә тынычлык, монда булган барлык кешеләргә тыныч тормыш, тазалык тели.

Бала.-Бабай, ә әбекәй үзе кайда соң?

Б.-И-и, әле генә теге, яңа магазин-суп-супермаркетка чыгып киткән иде. Озакламас, алла боерса. Әбиегез кайтканчы әйдәгез яшь чакларны искә төшереп уеннар уйнап алыйк.

Бала.-Без әби белән бабай турында такмаза беләбез.

Б.-Я, әйдәгез, сөйләгез.

Б-р.(хәрәкәтләр белән)

Әби коймак пешерә
Бабай кабык төшерә
Сыерлары бакыра
Бозаулары бакыра
Кәҗәләре сикерә

Үгезләре үкерә
(Шыгыр-
шыгыр)Дөбер-дөбер
Шакы-шокы
Бабай чыгып йөгерә.

Б.-Әй, булдырдыгыз. Үзегезне үртәп алыйм әле.

-Пәрәмәч дип әйт әле!

Б-р.-Пәрәмәч!

-Ике күзең тәгәрмәч.

-Сөт дип әйт әле!

Б-р.-Сөт!

-Борын астыңны сөрт.

Б-р.-Көлмә кешедән, авызың өшегән.

-Көлегез, көлегез, көлке капчыгы тегәрбез.

Б-р.-Көләбез.

-Көлмәгез.

Б-р.-Елыйкмы?

-Еламагыз, уйнагыз.

Бала.-Әйдә алайсаң, бергәләп уйныбыз. Уйнар өчен кулъяулыклар кирәк бит.

Т.-Балалар, кулъяулык сүзен дөрес итеп әйтик әле. (3 тапкыр бергә әйтелә.) Кулъяулык- ничә сүздән тора? 2- кул һәм яулык. Кулъяулык сүзендә “к” авазы кайда ишетелә. Җөмләне дөрес итеп әйтегез.

Бала.-Кулъяулык сүзендә “к” авазы сүз башында һәм сүз ахырында ишетелә.

Т.- Бик дөрес. Ә уйнар өчен кулъяулыклар каян алабыз соң?

Б.- И-и, әбиегезнең сандыгында ниндиләре генә сакланмый аның. Элек бит кызлар егетләргә армияга киткәндә дә, бәйрәмнәрдә дә кулъяулыклар чигеп бүләк итәләр иде. Әбиегезнең миңа чиккән кулъяулыклары шул сандыкта истәлек булып саклана инде. Хәзер, уенга кирәк булгач, бирим әле.

(Сандыкны ачмакчы була. Сандыкта йозак.)

Б.- И-и, балакайларым, сандыкны әбиегез йозак белән бикләгән икән.

Бала.- Ә без йозакны ачу серен беләбез.

Б.- Я, сөйләгез.

Б-р.-(хәрәкәтләр белән)

Сандыкта йозак тора
Кем ача, кем ача?
Боргалаштыргалыйбыз,
Тартып-сузып карыйбыз.
Тагын сузып алабыз
Ачкыч таптык
Йозакны ачтык.

Бабай йозакны ача, сандыктан балаларга җитәрлек кулъяулыклар бирә.

**Уен.** Балалар түгәрәк ясап басалар, кулларында кулъяулыклар. Бабай уртада яулык җыючы була. Музыка уйный. Музыка туктаганда яулык җыючы кем яулыгын ала, шул яулык хуҗасына “җәза” бирелә.

Т.-Бу яулык хуҗасына нинди җәза бирәбез?

Б-р.- Башын түшәмгә тидерсен!

- Шигырь сөйләсен. Ул бик матур шигырь сөйли.

Бала. Шыгыр-шыгыр суык йөри

Суык бабай кар көри

Балаларга тау шуарга

Көртләр өям, кил, күр,- ди.

“Җәза” бирелгән баланы җырлатырга, биетергә, такмаза сөйләтергә була.

Б.- Бик күңелле уен уйнадыгыз. Хәзер нишлик икшн?

Бала.- Бабакай, әбекәй кайтканчы әллә без дә кулъяулык бизәп карыйкмы?

Б.- Әйдәгез, менә өстәлләр дә әзер.

Т.- Балалар, кулъяулыкларыгызны күрсәтегез әле, кайсы кулъяулыкны бизик микән? (Арадан берсе сайлана)

Т.- Балалар, бу кулъяулыкта ниниди бизәкләр соң?

Б-р.- Татар халык бизәкләре.

Т.- Без сезнең белән кайбер татар орнаментларын беләбез.

- Чәчәкле үсемлеккә нинди чәчәкләрнең мотивлары керә соң?

(Ак чәчәк, лалә, роза, мәк, канәдер, кыңгырау, лотос чәчәкләренең һәм яфракларының мотивлары)

- Нинди төсләр кулланганнар бизәкләрдә?

(Кызыл, алсу, сары, яшел, зәңгәр...)

Стиле буенча орнамент симметрияле була. Орнамент ул- элементлар чиратлашу, кабатланудан торган бизәк. Кулъяулыкның бер почмагына гына эшләнә.

Без, сезнең белән бүген лалә чәчәген кисәргә өйрәнербез һәм татар халык бизәкләре белән кулъяулык бизәрбез.

Лалә чәчәге рәсеме күрсәтелә. – Нәрсәгә охшаган? Әйтелә.

Лалә сүзе бергәләп 3 тапкыр кабатлатыла. Бер тизәйткеч тә әйтеп карыйк.

Лә-лә-лә-Бик матур чәчәк лалә.

Өстәл артына урындыкларны алып утырабыз. Кайчы, клей белән сак эш итү турында аңлатыла. Һәрберегез лалә трафаретын ала, куеп сыза, кисә һәм бизәкләрне кулъяулыкка урнаштыра.

Урындыктан бер адым читкә китеп:

Физкультьминут: (хәрәкәтләр белән): Без инде зурлар,

Күп эшли безнең куллар,

Без идән дә юабыз,

Без керләр дә уабыз.

Гөлләргә су сибәбез ,

Менә нинди булган без,

Менә нинди уңган без.

Балалар эше татар халык җыры астында эшләнә.

Кулъяулыкларның эше беткәндә, әби кайтып керә. Исәнләшә.

Әби- И-и кунаклар бар икән. Озак йөрелде, ахры. Ярый әле тик утырмагансыз, булдырган.

(Әби, бабай мактый.)Т.- Әбекәй, без бу кулъяулыкларны кунакларга бүләк итәбез.Ә бабыкай һәм әбекәй хөрмәтенә “Кулъяулыклар белән бию”

Әби- Бигрәкләр дә матур биедегез. Бабагыз чәй эчердеме соң?

Б-р.- Юк.

Әби- Кунак килеп чыкса дип, пешергән кош телем бар иде, әйдәгез, бергәләп чәй эчәбез.

Т.- Юк инде әбекәй, рәхмәт, безне бакчада көтәләрдер.

Әби- Күчтәнәчне биреп җибәрәм.Чәй эчәрсез.

Балалар саубуллашып чыгып китәләр.

**Абдуллина Л.К.**

**2 категорияле йөзү инструкторы**

**Чулман елгасына сәяхәт.**

**Максат:** йөзү шөгыльләрендә алган сулыш алу-чыгару, су өслегендә шуышу, чуму, калкып чыгу күнекмәләрен ныгыту; хәрәкәтләрне төгәл үтәргә, физик күнегеләрне аңлы рәвештә, кирәклегенә, файдасына төшенеп шөгыльләнергә өйрәтү; татар халык фольклоры һәм җирле-региональ компонент кулланып табигать һәм җирле атамалар турында белемнәрен ныгыту; экологик һәм әхлак тәрбиясе бирү, оешканлык, кыюлык, игътибарлылык, мөстәкыйльлек, тәртип тәрбияләү.

**Алымнар һәм ысуллар:** эшләп күрсәтү, аңлату, ярдәм итү, кабатлау, ярышу, сигналлар, командалар, ориентирлар куллану, уеннар, музыка, персонажлар.

**Кулланылган җиһазлар:** су сиптерү өчен җайланма, зонт, кояш, туплар, librariesтакталар, обруч, йөзеп йөри торган балыклар, сачоклар, бата торган предметлар, каурый, шариклар, чүп (кәгазь, буш бутылка, конфет кәгазе һәм башка, балалар өчен зыяны булмаган предметлар) чүп җыяр өчен чиләк, магнитофон.

**Җиһазлау:** су буе күренеше, су өстендә чүпләр ята, су тирәли үсемлекләр, тау бите, Ак мәчет.

**Шөгыль барышы.**

Балалар елга буена килләләр. су өстендә чүпләр. Караңгы шомлы тынлык. Су буенда Су кызы елап утыра.

**А. б.:** Кем син?

**Су кызы:** Мин – Су кызы. Менә шушы елгада яшим.

**Балалар:**Ә ник елыйсың соң син?

**Су кызы:** Кичә су буена шәһәрдән ял итүчеләр килделәр, үзләрен бик ямьсез тоттылар,яр буена, суга чүпләрен ташлап калдырдылар. Мин төне буе чүп җыйдым, тик җыеп бетерә алмадым. Күрәсезме ничек ямьсез?

**А.б.:** Әйе, ямьсез шул, күңелсездә.Балалар әйдәгез без тиз генә яр буеннан, су өстеннән чүпләрне җыеп алыйк.

**Балалар:** Әйдәгез.Балалар бортик тирәли һәм суга кереп су өстендәге чүпләрне җыештырып алалар.

**А.б.:** Менә ничек чиста, матур матур булды елгабыз.Шул вакыт су аккан тавыш, кош тавышлары ишетелә, ут яндырыла, кояш чыга, табигать җанланып, уянып китә.

**А. б.:** Балалар, әйдәгез әле табигать, шәһәребез, безгә килгән кунаклар белән исәнләшеп алыйк әле.

**Балалар:** Исәнме табигать,
Исәнмесез апалар,
Исәнме ак кала,
Мең яшәр Алабуга.

**Су кызы:** Рәхмәт сезгә балалар, елгамны чистарттыгыз, бар табигать уянды. Балалар ,ә менә сез әйткән, 1000 яшьлек Алабуга шәһәре ниниди елга буена урнашкан ул?

**Балалар:** Кама- Чулман.

**Су кызы:** Балалар, сез миңа бик ошадыгыз, бик акыллы күренәсез, рәхәтләнеп,уйнагыз, йөзегез, күңел ачыгыз.

**А. б.:** Әйдә, синдә, безнең белән уйнарга.

**<u>Сулыш гимнастикасы</u>**

1. Каурыйларга өрү;
2. Кечкенә шарларга өрү;
3. Су суыту.

**Терәк-хәрәкәт аппараты өчен гимнастика**

**А.б.:** Әйдәгез балалар “Көзгеле” уены уйнап алабызмы? Әйдәгез борт буена басыгыз, мин сезгә нәрсә күрсәтәм, сез дә шуны ясагыз.

1. Муен-җилкә өлеше өчен күнегүләр.
2. Куллар өчен.
3. Аяклар өчен.

4. Фонтан ясыйбыз.
5. Сикерү.

Шул вакыт Су кызы яңгыр яудыра башлый.

“Яңгыр яу” уены.

Кояш чык, чык, чык

Майлы бртка бирермен

Майлы ботка казанда

Тәти кашык базарда

Тәти кашык саф алтын

Кирәкми безгә салкын. (Уен 2 тапкыр кабатлана).

**А.б.:** Балалар яңгыр китте бугай, әйдәгез, тагын уйнап алабызмы?

**Балалар:** Әйдәгез.

**Уеннар:** “Поезд тунельдән чыга”.

“Аучы һәм үрдәкләр”.

“Су астында ни күрдең?”

“ Су астында ни ишеттең?”

Су астыннан предметлар җыю.

Су өслегендәге балыкларны тоту.

**А.б.:** Балалар караңгыланып китте, кояш та качкан, тагын яңгыр явырга җыена бугай, әллә өйгә кайтабызмы. Балалар башта карагыз әле ,су буе чиста калдымы бездән, чүпләр юкмы?

**Су кызы:** Балалар, сез бик акыллы булдыгыз, бик күңелле, матур ял иттегез, артыгыздан җыештырып та киттегез. Су буена тагын килегез, йөзегез, уйнагыз, коеныгыз. Сау-сәламәт балалар булып үсәрсез. Балалар саубуллашып бассейннан чыгып китә

**Тема: Композитор Салих Сәйдәшев.**

**Максат:-** Милләтебезнең күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
- Шәхесләрнең иҗатына карата кызыксыну уяту, аларга карата ихтирам тәрбияләү.

**Экспонатлар:** Салих Сәйдәшев портреты,гармун,җыр тәлинеәсе,тәлинкә уйнаткыч.

## ЭКСКУРСИЯ ТЕКСТЫ:

Салих Сәйдәшев-татар халкының атаклы композиторы (портреты күрсәтә) Салих кече яшьтән үк җыр һәм музыка ярата. 9 яшендә тальян гармунында уйный, пионинода уйнарга өйрәнә.Салих музыка мәктәбендә бик тырышып укый. Соңрак ул үзе оркестр оештыра. Татар көйләрен оркестр белән башкара.

Салих Сәйдәшев күп көйләр яза.Аның җырларын хәзер дә халык яратып тыңлый.

Безнең музейда да гармун бар.Аны тәрбияче Миркасимова Гөлшат Габдулла кызы алып килде. Аның әтисе Габдулла абзый гармунда уйнарга яраткан һәм бик оста уйнаган да.

Салих Сәйдәшев та 9 яшендә гармунда уйнарга өйрәнгән,дидек. Әйдәгез,без дә бармаклар белән гармунда һәм пионинода уйнап алыйк.(бармаклар белән хәрәкәтләр ясыйлар)

Бу әйбер,экспонат- җыр тәлинкәсе.Бу тәлинкәләргә көйләр һәм җырлар язганнар.
Җыр тәлинкәләрен тәлинкә уйнаткычларында тыңлаганнар.Бу әйбер-тәлинкә уйнаткыч дип атала.

Салих Сәйдәшев балалар өчен көйләр язган.Сез кечкенәләр төркемендә аның “ Безнең дәү әни” җырын тыңладыгыз.( Г.Насрый сүзләре) Хәзер тагын бер тапкыр искә төшереп тыңлап үтик.

Ә хәзер тагын бер көй тыңлап үткәрәбез.Яхшылап тыңлагыз һәм аның нинди көй булуын әйтегез әле. Әйе,балалар,бу марш..Бу Салих Сәйдәшев язган “Совет Армиясе маршы “.Хәзер без маршка атлап йөреп күрсәтербез.

Уртанчылар төркемендә сез Салих Сәйдәшевнең “Яз килде”(Ә.Ерикәй сүзләре)һөм “ Зәңгәр күл” ( Г Насрый сүзләре) тыңладыгыз.Хәзер музыка җитәкчебез,Фирания Әнәсовна безгә бу җырларны уйнап һәм җырлап күрсәтер.

Салих Сәйдәшев үзе кыш көне ,декабрь аенда туган ( 1900 – 1954). 3 декабрь- татар халкының бөек композиторы Салих Сәйдәшевне искә алу көне.

Аның улы, Нәүфән Сәйдәшев, әтисе турында менә нәрсәләр сөйли:

- “Бала чактан ук күнелдә уелып калган , әтием янында һәрвакыт кешеләр булыр иде. “ Кайчан ял итә икән ул?”- дип уйлый идем мин. Мин 11-12 яшьлек малай бер нәрсәне яхшы аңладым: әтиемә халыкның ихтирамы бик зур икән! Дворникмы.яки,сугыштан ашыгыч кына кайткан генералмы, солдатмы-барысы да әтиемне үз итәләр.Әтинең дуслары бик күп.Әтинең бервакытта да шәхси дошманнары булмады- бу нәтиҗәгә дә мин үсмер вакытта килдем.Әти олы җанлы, сабыр кеше. Ул һәркемгә якты чырайлы.Пөхтә киенә,вакытында кырына, чисталыкны ярата- кыскасы ,матур кыяфәтле,саф күңелле кеше. Сүзгә бик оста иде. Төрле кызыклы вакыйгаларны, мәзәк хәлләрне мавыктырып сөйли белә.Аны тыңлаучылар рәхәтләнеп көлә иделәр”.

Хәзер тагын бер көй тыңлагыз әле. Бу нинди көй ? Бу көй астында нәрсә эшләргә була?

“ Вальс”.Кар бөртекләре булып биеп була. Әйдәгез,без дә бергәләп хәрәкәтләнеп алыйк.

Экскурсиябезне Салих Сәйдәшевның бөек язучыбыз Габдулла Тукайга багышлап язган

“ Тукай маршы”н тыңлау белән тәмамлыйбыз.

**Тема : Әбиемнең ишек алдында.**

**Максат**: Балаларның җәй вакыты, йорт хайваннары турында күзаллауларын ныгыту өчен сөйләм, музыкаль рәсемләү кебек эш төрләреннән файдалану; балаларның активлыгын үстерү. Аларның иҗади ачылуларына мөмкинлек бирү.

Әзерлек эше: Җырлар, ритмик һәм бию хәрәкәтләре, шигырьләр өйрәнү, авыл турында сөйләү, табигать күренешен күзәтү. Аппликация күнекмәләренә өйрәтү.

Җиһазлау: Кошлар тавышы язылган пластинка, күмәкләшеп ясаган аппликация эше, чеби һәм тавык башлыклары, быргы.

**Шөгыль барышы.**

1. Оештыру өлеше:

- Балалар , кемнәрнең әбиләре бар?
- Сез әбиегезне яратасызмы?
- Әби турында нинди сүзләр әйтеп була? (ягымлы.,уңган, әйбәт, кадерле, дәү әни).
- Кемнәрнең әбиләре авылда яши?
- Авылга кунакка барасыгыз киләме?
- Әйдәгез , балалар , әбиләргә кунакка поезд белән кайтабыз. Утырыгыз вагоннарга....

Уен “Паравоз” (Бер бала быргы кычкырта, алга баса, калган балалар бер-бер артлы тезелеп басалар . Кулларын алга- артка хәрәкәтләндерәләр һәм җырлап атлыйлар:

Паравоз, паравоз,
Без авылга барабыз.
Тиз алып бар авылга
Авылга, авылга.

Паравоз, паравоз,
Без әбигә барабыз
Тиз алып бар әбигә,
Әбигә, әбигә.

Әби балаларны каршы ала.

Тәрбияче : Менә килеп тә җиттек , балалар. Әйдәгез әби белән исәнләшәбез.

Әби: Исәнмнсез, минем кадерлеләрем.Сез нинди матурлар, шат күңеллеләр. Шундый ерак арадан әбиегезне үзегезнең җыр-биюләрегез белән шатландырырга дип килдегезме? Хай. Рәхмәт төшкерләре. Әйдәгез әле һөнәрләрегезне күрсәтегез , мин сезнең җыр-биюләрегезгә кул чабып торырмын.

Уен “Чүгәләү”

Таралышып басабыз, башларны иябез ля-ля-ля...
Кулларны чәбәклибез, чәп-чәп чәбәклик, ля-ля-ля...
Тып-тып-тыпырдап, бииләр аяклар, ля-ля-ля...
Кулларны селкибез, кошлар күк җилпибез, ля-ля-ля...
Без биеп бетердек, тагын бер баш идек, ля-ля-ля...

Әби: Бигрәк матур биедегез, балалар. Ә сез минем ишек алдында кемнәр яшәгәнен беләсезме? Менә бу табышмакларга җавап табып карагыз әле.

1. Кыт-кыт-кыт кытак, балаларын чакыра, канат астына җыя. (Тавык).
2. Йомры йомшак, сары йомгак, йөгереп йөри чирәмдә. (Чеби)

Әби: Дөрес, балалар, булдырдыгыз.

Тәрбияче: Әби, безнең балалар да чебиләр булып йөри беләләр. Чебиләр турында шигырьләр да беләләр.

1 бала: Өй алдында чебиләр,
Чеп-чеп диеп йөриләр
Кечкенә канатлары,
Муеннары сап-сары.
Күпереп тора йоннары,
Ул аларның туннары.

2 бала: Тышта бик җылы булса да
Тун кигәннәр чебиләр
Яңа гына тусалар да
Йөгерешеп йөриләр.

3 бала : Акыллы кыз Гөлфия
Чебиләрне бик сөя.
Энисе эштә чагында
Ул аларга җим сибә.

( Әтәч кычкырган тавыш ишетелә)

Әби койма башыннан әтәчне алып килә.

Әби: Менә балалар минем әтәчем дә бар әле. Ул ошыймы сезгә.

4 бала: Башында кызыл тарак,
Ә койрыгы гел урак.
Ни була ул дисезме?
Әтәч аның исеме!

5 бала : Иртән бик иртә тора
Канат кагып кычкыра
Кикрикүк, кикрикүк.
Тор иртәрәк, эшең күп.

Тәрбияче: Әле әтәч турында җыр да беләбез без , җырлап та күрсәтик.

Җыр “Әтәч”

Әби: Пес, пес, пес. Балалар сез дә чакырыгыз әле. Кая югалган песием.

- Пес, пес,пес.

- Менә бит ул пескәем. Балалар песи нәрсә ярата беләсезме?

- Әйе , дөрес, сөт. Менә хәзер мин аңа сөт салам, сезне тыңлый-тыңлый эчсен.

6 бала: Әби сезнең песиегез чуар тун кигән,
Ялтырап тора күзләре, койрыгы бер дигән.
Көн дә ул безгә керә дә, каймак, сөт сорый,
Каймак биргәч безгә карап койрык болгый.
Әби сезнең песиегез шундый шаян, шук,
Сырпалана, тәгәри ул, әйтерсеңлә туп.

7 бала: Мыеклы, сакалы юк,
Туны бар, пәлтәсе юк.
Сыйпый аны һәммәсе
Аның исеме мәче.

8 бала: Минем пескәем матур
Һәр иртә битен юа.
Урамда тавык куа
Ул шаян да, ул наян.
Мондый булган ул каян.

9 бала: Песи, песи, пескәем
Уеннан һич туймыйсың
Тычканнарың күрерләр,
Һәм үзеңнән көлерләр.

Әби: Бигерәк яратасыз икән песине, никадәр шигырьләр беләсез икән. Песинең сөт эчеп тамагы туймады, сезнең шигырьләрне тыңлап күңеле булды. Мыраубатыр җыр да тыңларга ярата. Ул үзе дә бик оста. Ничек итеп җырлый ул, беләсезме?

Җырлы – уен. "Сары – песи"

Песи башлыгы кигән бала уртада йөри, икенче бала түгәрәкнең тышында тычкан башлыгы киеп йөри, җырлап бетергәч песи тычканны куа.

Әби: Булдырасыз балалар. Ә хәзер "Мах-мах-мах" дип чакырып карыйк әле, кем килер әле?

-Хау, хау,хау!

Әби: Бу минем этем. Аның исеме Акбай. Ул минем йортымны саклый. Эт турында кешенең дусты, йортның сакчысы диләр. Сез этләр белән дусмы? Алар турында ниләр беләсез?

10 бала: Бар минем маэмаем
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә
Күп ишетә, күп күрә.

11 бала: Тешләмәсен Акбаем
Сезгә өрә маэмаем .
Ташлар ыргытмагыз, ди
Мине котыртмагыз, ди.

12 бала: Бакчага кәҗә кергән
Кәбестәне кимергән
Ишетмәгән , күрмәгән.
Акбай йоклап сизмәгән.

Әби: Булдырасыз , уңганнар. Менә мин сезгә тагын бер табышмак әйтәм белерсез ме икән?

Соскы борын бакылдык
Күп сөйләшә такылдык.
Аңа әйтәләр үртәп
Корсак-батыр син .... (үрдәк)

Әби: Дөрес әйтәсез, балалар. Минем ишек алдында үрдәкләр дә бар. Менә аларның бәбкәләре . Ә сез үрдәкләр турында ниләр беләсез?

13 бала: Үрдәк йөри күл буенда,
Бәбкәләре бар янында.

Бип-бип-бип, дип
Йөдәтәләр һәр адымда.
14 бала: Яшел чирәм, соры бәбкә
Аяк терәп шуны тарта
Чирәм кинәт өзелгән дә
Авып киткән үзе артка.

15 бала: Ай-яй матур бәбкәләр
Сары күлмәк кигәннәр
Әниләренә ияреп
Су буена килгәннәр.

Җыр “Ун бәбкә”

Әби: Әйдәгез балалар якынырак килегез, минем ишек алдында кемнәр яшәгәнен яхшырак күрегез. И-и үрдәкләремнең сулары беткән,чәчәкләр дә сусаганнар. Яңгыр кирәк. Ягез әле бергәләп яңгыр чакырыйк.

Яңгыр яу-яу-яу
Игеннәр яхшы булсын
Үләннәр дә күп булсын
Сыерлар да тук булсын
Безгә эчәргә сөт булсын.

“Болыт” керә, әйләнеп йөри. Яңгыр тавышы яңгырый, балаларны куа, алар качалар.

Әби: Һәй җылы яңгыр яуды, хәзер нинде кояш кирәк. Әйдәгез кояшны чакырыйк.

Кояш чык, чык,чык.
Тәти кашык бирермен.
Майлы ботка бирермен.
Тәти кашык базарда
Майлы ботка казанда.

Әби: Кояш безне ишетте, якты нурларын сипте. Күбәләкләр оча, кошлар сайрый башлады. (кошлар тавышы яңгырый).

Минем ишек алдында еш була торган бер кош турында табышмак әйтим әле:

Урмый, чәчми, ни көтә?
Ил өстендә көн итә.

Язын кайткан сандугачны

Оясыз да калдыра

Аның исеме ничек? (Чыпчык)

Җыр "Чыпчык."

Тәрбияче: Әбекәй , без балалар белән матур карандашлар белән буяп келәм ясадык, шуны сиңа бүләккә калдырабыз. Бергә кайтырга вакыт.

Әби: Рәхмәт балалар. Минем дә бик тәмле пешеп кенә чыккан коймакларым бар. Сезгә күчтәнәчкә бирәм. Бергәләшеп кайткач ашарсыз.

Тәрбияче: Әйдәгез, балалар әби белән саубуллашыйк . Вагаоннарга утырып юлга чыгыйк.

Паровоз, паравоз

Без бакчага кайтабыз

Тиз алып кайт бакчага

Бакчага, бакчага.

**Җиһангирова З.Ф.**

**2 категорияле тәрбияче.**

**Тема: Яхшы гадәт юлдаш булсын.**

**Максат:** - яхшы холык, уңай гадәтләр тәрбияләү;

-бер-береңә, дусларыңа ,олыларга ихтирамлы, кешелекле, ярдәмчел булырга өндәү;

-сүзлек запасын баету;

-зурлар сүзен игьтибар белән тыңлау, сөйләгәндә бер – береңне бүлдермәскә өндәү.

**Шөгыль барышы:**

Шөгыль музейда үтә .Балаларны Галимә әби каршы ала. Исәнләшәләр. Галимә әби янына тезелеп утыралар.

1.Галимә әби: Бигрәк әдәпле балалар икәнсез. Галимә әбиегезнең шулай хәл - әхвәлләрен сорашканыгыз, искә алып килгәнегез өчен зур рәхмәт сезгә. Яхшылыкка гына омтыласыз икән, әфәриннәр. Алага табада яхшы гадәт юлдаш булсын. И-и-и безнең күрше Габдулла оныгы бигрәк тә яман гадәтле иде. Ничек дисезме ? Менә тыңлагыз анық турында шигырь дә язган идем.

Әнисе аны уята да уята,
Ә ул һаман иренеп тормыйча ята.
Бит кулын да юмаган
Урынын да җыймаган.
Чәчен дә тарамаган
Көзгегә карамаган.
Өстәлдәге ашамлыкны
Кайсын этә,кайсын төртә,
Ник алай?
Кире ягы белән торган ул малай.
“Киен тизрәк” диләр
Ятып елый идәнгә
Тыңламый әтисен дә

Тыңламый әнисен дә,
Сүз тыңламый интектерә
Бабасын,әбисен дә.
“Тор”-дисәң утыра ул,
“Утыр”-дисәң тора ул.
Кешедәгесен тартып ала,
Үз кулындагысын бирми.
“Бир!”- дигән сүзне белә
“Мә” дигән сүзне белми.
Җылыда салкын кирәк,
Салкында – җылы кирәк,
Белмим,аңа ни кирәк?

Мондый баланы нинди диләр? Ни өчен? Габдулла оныгының нинди начар гадәтләре бар? Яхшы гадәтләрме? Сез нинди начар гадәтләр беләсез? Балалар баксачында, гаиләдә нинди яхшы гадәтләр бар? Тәрбияче апаларның, дусларыгызның нинди яхшы гадәтләре бар? Ә үзегезнең? Сезнең начар гадәтләрегез бармы? “ Начарлыктан тыйган- әдәп, һәлак иткән – гадәт” дия торган иде минем әнием. Сез дә балалар начарлыктан тыелыгыз,әдәпле булыгыз.

2.Балалар, яхшы һәм начар гадәтләр турында нинди мәкальләр , әйтемнәр беләсез?

Чир китәр-гадәт китмәс.

Кеше холкын күзәт,үзеңнекен төзәт.

Яман гадәт йогышлы була.

Әдәпленең күлмәге сәдәпле,үзе матур гадәтле.

Өйрәнгән гадәт калмас.

Холкы начардан-дуслары качар.

-Әфәрин,балалар. Без яшь чакта бик матур ,күркәм гадәтләр бар иде. Дини бәйрәмнәр алдыннан бөтен гаиләбез белән йорт-куралтыларны чистарта, агарта идек. Әтиебез хуш исле мунча ягып җибәрә иде. Әниебез кунаклар килер дип, төрле тәмле-томнар ,чәкчәкләр пешереп куя иде. Кичен көн дә шаулап торган самовар артына тезелешеп чәй эчә идек. Табын артына әти утырмыйча, без балалар утырмый идек. Ә кунаклар килсә әти-әнине борчып табын янына килергә рөхсәт итми иде. Әтиебез кырыс кеше булса да, бик гадел кеше иде. Яхшы гадәтләрне , дини бәйрәмнәрне ихтирам итә иде.

3. Физкультминут “ Чума үрдәк,чума каз”.

4. Галимә әби: Балалар, начар гадәтләр кешегә каян килә икән? Үзеңдә язшы холык, гадәтләр тәрбияләр өчен ни эшләргә кирәк? Габдулла оныгына начар гадәтләре булмасын өчен нинди киңәшләр бирәсез? (Балалар җавап бирә. Тәрбияче белән әби ярдәм итә.)

-өлкәннәр киңәшенә игьтибарлы булырга, алар кушканны үтәргә.

-балалар бакчасы кагыйдәләрен үтәргә.

-көндәлек режимны бозмаска.

-дусларыңның яхшы киңәшләренә колак салырга.

5.Дидактик уен “ Кирлемән”.

Балалар тәрбияче әйтәненең киресен әйтәләр.

Зур-кечкенә,киң-тар,озын-кыска.,чиста-пычрак,коры-юеш,яңа-иске,биек-тәбәнәк,матур-ямьсез,чирле-сәламәт,каты-йомшак,
тәртипсез-акыллы, яхшы-яман, ялкау-уңган,уңай-кире.

6.Дидактик уен “ Әниегезнең каефе нинди?”.

Тәрбияче атаган ситуациядә олыларның кәефе нинди буласын балалар мимика белән күрсәтәләр.

-Әниегезнең туган көненә рәсем бүләк итсәгез.

-Бүлмәгезне җыештырмасагыз.

-Тәрбияче апагыз сезне мактаса.

-Әниегезнең сүзен тыңламасагыз.

-Киемнәрегезне тәртипләп куйсагыз.

-Бакчада һәм кунакта тәртипле булмасагыз.

-Аш артында аяк селкетеп утырсагыз,ашаудан канәгать булмасагыз.

-Йокларга яткач сөйләшеп ятсагыз.

-Дусларыгыз сезне яратса.

-Кечкнәләргә ярдәм итсәгез.

7.-Галимә әби: балалар,ни өчен кешегә яхшы гадәтләр кирәк икән?

Мин сезгә һәрвакыт шундый әдәпле, матур гадәтле булуыгызны телим. Мине искә алып килүегез, төпле җаваплар бирүегез миңа бик ошады,шатландырды. Зур рәхмәт сезгә,оланнар. “ Гадәтләр чәчсәң – холык урырсың, холык чәчсәң – язмышыңны урырсың”-дип әйтә картлар.Бәхетле булыгыз,балалар! И,раббым,нарасыйларга тәүфик, әдәп, иман,апаларына тазалык, сабырлык бир. Юлларыгыз уң булсын,яхшы гадәтләрегезне онытмагыз.

## Тема : Әбиемнең серле сандыгы.

**Максат**: Балаларны халкыбызның гореф-гадәтләре, мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итү, халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү; бәйләнешле сөйләм телен үстерү; сүзлек запасын баету; музейның экспонатлары турындагы белемнәрен ныгыту

Әзерлек эше: 1. Музейга экскурсия: экспонатларны карау. Татар халык уенын уйнау.

2. “Милли киемнәрне бизәү” – музейда рәсем шөгыле

.Җиһазлау: Сандык, аның эчендә калфак, мәкальләр китабы, йөзек; бишек һәм япмасы; өй күренеше, магнитафон язмалары, көянтә- чиләк.

## Шөгыль барышы:

Балалар музейга кереп утыра. Кызын җитәкләп әни керә. (Тәрбияче әни ролендә).

Әни: Исәнмесез, кунаклар бар икән, кызым. Без килгәнче иптәшләрең алдан өлгергән.

Бала: Алабуганың истәлекле урыннарында йөрдек, бик арыдык.

Әни: Әйе шул, истәлекле урыннар бик күп, балалар, аларны сез дә беләсезме соң?

Балалар: Ак мәчет, И.И.Шишкин музее , Надежда Дурова һәйкәле,Марина Цветаева музей-йорты, нефтьчеләргә һәйкәл.

Әни: Бик матур шул Алабуга.

Бала: Ә мин, Алабуга турында бик митур бер җыр да беләм.

Җыр: “ Күңелле безнең шәһәр”.

Әни: Кызым,кара әле,безнең әбиебезнең өендә дә истәлекле-тарихи әйбер бар бит. Әбиеңнең садыгы турында әйтүем .

Бала: Әни , әбиемнең серле сандыгы мине күптән кызыксындыра, әйдә бергәләп ачып карыйк,кызлар да күрер.

Әни: Әбиеңнен серле сандыгын ,
Бер ачасы иде,нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме,
Нинди серләр саклый икән ул?

Бала: Әбиемнең серле сандыгын,бер ачасы иде,ачасы.
Әби-бабайлардан калган йолаларны,
Күңел җәүһәрләрен
Бер ачасы иде,ачасы.
Әбиемнең серле сандыгы
Кызыктыра мине күптәннән.
Ачыйк,әнием,әбекәйнең сандыгын
Яшь буынга мирас булып
Бер хәзинә калсын үткәннән. /Сандыкны ачалар/

Әни: Ай-һай, ниләр генә юк монда! Төрле китаплар да бар. Менә монысын карыйк әле.

Бала: Бигрәк зур, калын үзе!

Әни: Хәтерләүдән курыкма , син,

Үткәнеңне онытма, син,

Бел, син, ерак бабаларың

Ничек итеп көн күргәнен

Ни икәнен, ни чиккәнен.

Нинди җырлар, нинди моңнар,

Безгә калдырып киткәнен.

Әни : Балалар, карагыз әле, нәрсә сүрәтләнгән бу китап тышында?

Балалар: Яз, (Яз турында рәсемгә сөйлиләр) .(Язгы бәйрәмне - 8 март, Г.Тукайның туган көнен, Нәүрүзне әйтәләр)

- Яз көне дөнья яшәрә, ямьләнә, кояш көлә тамчылар тама.

Әни: Әйдәгез, балалар, бераз күңел ачып алыйк.

Җыр “Тамчылар бии”

1 бала: Көннәр аяз, күктән алсу

Нур сибеп кояш көлә,

Җиргә тама көмеш тамчы

Сагынып киткән яз килә!

Җырлы-биюле уен “Тамчы”

Там, там, тамчы, там,

Тамуыңны яратам.

Тамган тамчыларга карап,

Мин җырларга яратам.

Там, там, тамчы, там.

Тамуыңны яратам.

Тамчы тамса матур язлар,

Килеп җитә түгелме?

Әни: Бу сандыкта милли киемнәр дә бар икән (калфак ала).

2 бала: Сандыкта ятты озак,

Әбием чиккән калфак.

Ул калфакны әбием

Кадерләп кигән һәрчак.

3 бала: Милләтемнең нуры анда,

Ука, чугы, чачагы.

Кадерләп саклармын үзем,

Әбиемнең калфагын.

Әни: Менә бишек япмасы да бар, бик матур, бишек турында нәрсә беләсез соң?

Балалар: Бишектә нәни балаларны тибрәтеп, җыр җырлап йоклатканнар.

“Бишек җыры” Г.Тукай сүзләре.

Әни: Менә бу китапта мәкальләр язылган.

4 бала: Матурлыкка бай ул тормыш,

Адым саен анда матурлык,

Барлык батырлыкның, матурлыкның

Иҗат итүчесе – халык бит.

Мәкальләр әйтәләр:

- Иң матур тел – туган тел,
Әткәм- әнкәм сөйләп торган тел.

- Олыласаң олыны – олыларлар үзеңне.

- Дөресен әйткән – котылыр,
Ялган әйткән – тотылыр.

- Иртә көлсәң кешедән
Кич көләрләр үзеңнән.

- Белемле көн күргәндә,
Белемсезгә төн килгән.

Әни: Мәкальләр нәрсәгә өйрәтәләр?

Балалар: Олыларны хөрмәт итәргә, белемгә омтылырга, туган илне яратырга өйрәтәләр.

Әни: (Сандыктан йөзек чыгара) Бусы...

Балалар: Йөзек. (ни өчен кирәк икәнен сөйлиләр.)

Әни: Әйе, ә тагын аның белән уйнап була.

Уен “Йөзек салыш”

(Җәзага балалар үз һөнәрләрен күрсәтәләр)

Әни: Менә, балалар, бүген шушы сандыкны ачып берничә генә әйберне карадык, ә күпме белдек, үткәннәрне искә төшердек, күз алдына китердек.
5 бала: Кызлар әбинең сандыгында әйберләре күп әле, тагын карарбыз. Әйдәгез , биеп тә алыйк.

Татар халык биюе “Су буе”

Балалар көянтә-чиләкле , татар костюмы киеп биегән кызның биегәнен карау.

**Кульяулыклар чигү.**

**( 2нче кечкенәләр төркеме).**

**Максат:** балаларны татар халык бизәкләре булган кыңгырау, ромашка чәчәкләре белән таныштыру,төсләрне белүне ныгыту , композиция тойгысы формалаштыру: квадратта бизәкләрне симметрияле итеп урнаштырыга өйрәтү,сөйләм телен үстерү.
-ябыштыру күнекмәләрен : пумаланы дөрес тоту, клейны аз гына алу, салфеткадан файдалана белүне өйрәтүне дәвам итү.
-“сандык,кульяулык, ромашка,кыңгырау”сүзләрен әйтергә, “ң”авазының артикуляциясенә игьтибар итү.
- татар халык бизәкләре белән таныштырганда музей элементларын - йорт күренешен,сандык,чиккән кульяулыклар- куллану; балаларда аларга карата кызыксыну тәрбияләү, сөйләм телен баету ( сыйфатлар куллану, яңа сүзләр өйрәнү), зурларга карата хөрмәтләү хисләре тәрбияләү.

**Шөгыль барышы.**

Тәрбияче: Балалар,без әбигә кунакка килдек.Тик нишләптер,ул бик күңелсез, әллә авырамы икән? Сорыйк әле.
Әби: И, бәбекәйләрем, килеп тә җиткәнсез, исеменән дә чыккан бит сезне чакырганым, исәнмесез, узыгыз әйдә.
(Балалар ярым түгәрәк булып утыралар).
Тәрбияче: Әбекәй,бик кәефсез күренәсез.

Әби: Менә, балалар, оныкларыма да булыр,сезгә дә күрсәтермен дип, кульяулыклар чиккән идем .Оныкларым бик күп,барысына да җитмәс дим,шуңа борчылам.

Тәрбияче: Балалар ,ничек итеп әбигә булышабыз, ничес итеп ярдәм итәбез?

(Балалар җаваплары тыңлап үтелә)

Тәрбияче: Әбекәй,без сиңа,матур итеп кульяулыклар бизәп бирербез , оныкларыңа да җитәр.

Әби: И, рәхмәт, төшкерләре, булдырсагыз бик сөенер идем. Менә,үзегезгә чиккән кульялыкларымны күрсәтим әле.

( сандыктан бер – бер артлы 3-4 кульяулык алып күрсәтә)

Тәрбияче: Балалар, “сандык” сүзен кабатлыйк әле. Ә хәзер,“ кульяулык” сүзен кабатлыйк .Авыр сүз,чөнки, “ кул”,”яулык” сүзләре кушып төзелгән. Кечкенә, кулга тота торганны аңлата. Нинди төстәге кульяулыклар?

Тәрбияче: Рәхмәт, әбекәй, истәлекләрең белән таныштырдың, без сиңа кульяулык турында шигырь сөйләп күрсәтик.

1бала: Кулга сыя,зур түгел ул,
Ә исеме-кульяулык,
Балалар гел кирәк ул,
Кульяулык ул-чисталык.

2бала:Кульяулыгым бигрәк матур,
Бүләк итте әбием!
Үзе чиккән яшь вакытта,
Ничек мактанмыйм инде!

3бала:Читләрендә бар чәчәкләр,
Төсләре төрле-төрле,
Кульяулыкны әби миңа,
-Югалтма!-диеп бирде.

4бала:Мин аны кадерләп саклыйм,
гел йөртәм үзем белән,
Әбием иркәли мине.
Ягымлы сүзе белән.

Әби: И,бик матур булды,балакайларым.

Тәрбияче: Балалар,әйдәгез,әбигә бүләкләр әзерли башлыйк.

(Өстәлләр янына киләләр. Физкультминут “ Бармаклар ял итә”)

Тәрбияче: Балалар,сезнең алда кәгазь битләре,без аларның нәрсә итеп күз алдына китерербез икән?

Дидактик уен “ Нәрсәгә ошаган”.

Тәрбияче: балалар,без бүген төрле бизәкле кульяулыклар карадык,нәрсә өчен кирәклеген беләбез, әбекәйне сөендерик,аңа кульяулык бизик.Һәрберебезнең алдында кирәкле әйберләр бар.Башта кәгазь битендә бизәк төзик.

Дидактик уен " Бизәкне төзе".(Тәрбияче алдан әзерләнгән зур квадратка (30х30) бизәкне төзергә тәкьдим итә. Әзерләнгән үрнәкнең уртасына ромашка чәчәге ябыштырып күрсәтә,аны мольбертка элә.Шулай эш алып барыла)

Тәрбияче: Балалар,кисточка белән ничек эшлибез,искә төшерик эле.(Балалар җавабы, тәрбияче җавапларны төзәтә, аңлатулар кертә)

Тәрбияче: Инде ,әйдәгез,бергәләп ябыштыра башлыйк. Кемгә ярдәм итәргә кирәк- мин булышырмын.

Мөстәкыйль эшчәнлек музыка астында алып барыла.

Тәрбияче индивидуаль ярдәм итә.

Әзер булган кульяулыклар әбигә бүләк ителгән.

## Театрализованное этическое представление по мотивам русской народной сказки «Колобок»

**воспитатели по обучению русскому языку**

**Козлова С.А.,Сайфутдинова А.А.**

**Цель:** закрепить знания о музейных экспонатах: миска, ложка, сито, молочник, солонка; дать детям понятие о том, для чего они предназначены. Воспитывать культурно – этические и нравственные качества. Обогащать и развивать речь .

**Картина I**

**Ведущий:** На лесной опушке в маленькой глубинке в близи танайских лесов жила – была одна старушка. И была у нее внучка Настенька. А Настенька в городе Елабуга жила. И старушка решила Настеньке на день рождение испечь Колобок.

**Старуха:** У внучки Настеньки скоро День рождение. Испеку я ей на праздник колобок. А для этого мне нужна посуда: миска, ложка, солонка, молочник. А все это есть у нас в чулане. И все то, что лежит у меня на столе, тоже из чулана. С этой посудой нужно обращаться бережно. Потому что все эти вещи старинные.

А теперь начину месить тесто. Для этого мне нужно взять молоко, соль, яйцо, муку. Перемешаю. Тесто округлю и выложу на сковороду и в печь, чтобы наш Колобок испекся вкусным и румяным.

**Ведущий:** Старуха пошла домой. Из дома выходит Колобок (ребенок).

**Старуха:** Иди Колобок к Настеньке. Да ты по дороге не зевай: кто в беде – тем помогай, вежливые, волшебные слова не забывай!

**Колобок:** А какие это слова?

**Старуха:** А давай у ребят спросим. Ребята, назовите, пожалуйста, Колобку все волшебные, вежливые слова, какие вы знаете?

( ответы детей: пожалуйста, будьте любезны, извините, здравствуйте, досвидание, спасибо.)

**Колобок:** Спасибо ребята! Теперь пора в путь!

**Старуха:** Ну что же, счастливого тебе пути!

**Картина II**

**Ведущий:** Бежал, бежал Колобок, вдруг видит – заяц сидит. Только что проснулся. Глаза протирает.

**Колобок:** Здравствуй, Зайка!

**Заяц:** Привет! Куда это ты в такую рань бежишь?

**Колобок:** Да вот к внучке Настеньке на день рождение спешу.

**Заяц:** Вот здорово! Возьми меня с собой!?

**Колобок:** Как же я тебя возьму, если ты не сделал того, что по утрам полагается.

**Заяц:** А что полагается делать?

**Колобок:** А ты у ребят спроси. Ребята! Что по утрам после того, как проснулся, делать нужно? ( ответы детей: умываться, чистить зубы, причесываться и т.д.)

**Колобок:** Ну, понял теперь, что тебе полагается сделать?

Заяц: Понял! В моем зеленом лесу недалеко течет прозрачная, небольшая речка, называется Кривуша. Я сейчас быстро сбегаю,умоюсь!

**Картина III**

**Ведущий:** Умылся Зайка, зубы почистил, и пошли они вместе. Вдруг навстречу Волк – грязный – прегрязный! Шерсть свалялась, хвост давно не чесан, когти не подстрижены! Хотели они такого неряху стороной обойти, да тот им дорогу перегородил.

**Волк:** Вот красота, какая! Сам завтрак мне в лапы идет! Будет у меня рагу из Зайца, а Колобок на десерт.

**Ведущий:** Бедный Зайка от страха в кусты забился, а Колобок храбрым оказался, и говорит Волку:

**Колобок:** Нельзя нас есть! Я не твой, а внучкин; именной! А Заяц со мной идет Настеньку с днем рождения поздравить.

**Волк:** Ух ты! А меня возьмете?

**Колобок:** А ты не будешь нас пугать? Будешь с детьми дружить? В нашем детском саду дети очень дружные. А у тебя поведение не совсем хорошее.

**Волк:** Нет, не буду детей пугать и буду со всеми дружить. Даже с ними в наш прекрасный лес по ягоды ходить. Только возьмите меня с собой!

**Колобок:** Куда же мы тебя такого грязного возьмем? Ты весь народ в городе распугаешь! Не готов ты в гости идти!

**Волк:** А что же делать? Очень уж мне на день рождение хочется…

**Колобок:** А ты у ребят спроси, что нужно сделать перед тем, как идти в гости!

**Волк:** Ребята! Посоветуйте, что мне делать? Очень уж я в гости хочу! На день рождение…

(дети советуют: умыться, причесаться, не кричать, быть вежливым)

**Волк:** Ну вот, умылся, когти подстриг. Теперь можно?

**Колобок:** А ты в зеркало смотрелся?

**Волк:** Ух ты! Какой лохматый! А расчески у меня нету… Ребята, дайте мне, пожалуйста, расческу! ( расчесывает шерсть)

**Волк:** Ну а теперь можно?

**Колобок:** Нет, ты в карманы забыл заглянуть!

**Волк:** ( заглядывает в карманы) Пусто!

**Колобок:** Вот то –то! А что воспитанные дети в кармане с расческой носить должны? (носовой платок)

**Колобок:** А у кого – нибудь , есть платок? Покажите. ( в зависимости от ответа Колобок или хвалит: Молодец; или ругается: Ай – ай – ай!) Платок и расческу нужно всем носить! (дает Волку носовой платок). Вот держи, а впредь не забывай!

**Картина IV**

**Ведущий:** Вот идут они дальше. Смотрят на поляне ульи стоят, пчелы гудят и Медведь Михаил Потапыч тут же сидит, мед ест, лапу в бочку засунет и с шумом облизывает, чавкает.

**Медведь:** Эй, малышня, куда топаете?

**Заяц:** Здравствуйте ,Михаил Потапыч!

**Волк:** Пропустите нас, дядя Миша! Мы в гости идем.

**Колобок:** К внучке Настеньке на день рождение!

**Медведь:** Ух, ты! А меня возьмете!

**Колобок:** Как же мы тебя возьмем, если ты за столом вести себя не умеешь? Вон, мед прямо лапой ешь!

**Медведь:** Вот беда. А кто же меня научит? Я же не грамотный!

**Волк:** А ты к ребятам за помощью обратись, они все правила этикета знают, сами нравственно воспитаны. Мне помогли и тебе помогут.

**Медведь:** Ребята, посоветуйте, как себя за столом вести, пожалуйста.

(дети советуют: не класть локти на стол, не вертеться, сидеть прямо и т.д.)

**Медведь:** Спасибо вам ребята! А теперь мне можно с вами идти? Я даже своим медом поделюсь, я не жадный.

**Колобок:** Вот теперь можно.

## Картина V

**Ведущий:** Идут они дальше. Вышли на поляну. А там цветов видимо – невидимо. Решили букет нарвать, внучке Настеньке, на день рождение подарить. А как же, без подарка, никак нельзя? Вдруг слышат кто- то плачет.

**Медведь:** Ой! Это же Лиса плачет! В капкан попалась, бедная!

**Лиса:** Помогите мне ,пожалуйста!

**Колобок:** Что же нам делать? Как горю помочь?

**Медведь:** Отойдите подальше! Я вмиг капкан открою, одной левой лапой!

**Лиса:** (плачет) Ох, Михаил Потапыч! Капкан этот не простой, а заколдованный. Его еще Баба Яга в прошлой сказке поставила…

**Медведь:** Да ну!!!

**Волк:** Как же быть?

**Лиса:** А вот как! Нужно загадки отгадать, тогда капкан и откроется…

**Заяц:** Да ведь мы не умеем загадки отгадывать! Мы же в школе не учились!

**Волк:** Давайте опять у ребят помощи попросим.

**Колобок:** Ребята, вы нам поможете загадки отгадать?

(дети: да)

**Колобок:** Только надо побыстрее , а то черстветь начинаю.

**Лиса:** Не знаю, умеете ли вы…Слушайте первую загадку

(зрители отгадывают загадки, которые нужно заранее подготовить с учетом возраста детей)

**Медведь:** Ну, что? Не открылся?

**Лиса:** Нет. Наверное заело.

**Колобок:** Мне кажется, здесь что – то другое. А давайте к загадкам еще и песенку споем. О дружбе. Может это поможет?

(поют песню «Вместе весело шагать»)

**Лиса:** Спасибо вам ребята! Спасибо, друзья! Возьмите и меня в гости к Настеньке.

**Колобок:** Ну что же, идем, веселее будет.

**Картина VI**

**Ведущий:** Солнце к полудню, наши друзья в город пришли. А внучка Настенька их уже ждет, встречает.

**Настенька:** Здравствуйте, друзья, добро пожаловать!

**Звери** (хором)**:** Поздравляем с днем рождения!

(водят вокруг Настеньки хоровод и поют)

**Звери:** Как на Настеньки именины испекли мы колобок…

(вдруг плачут)

**Колобок:** Вы что это?

**Заяц:** Да-а-а, нам тебя есть жалко.

**Волк:** Ты такой добрый…

**Медведь:** И вежливый…

**Настенька:** Подождите, а зачем нам колобка есть? У меня целый стол накрыт! На столе и блины, и пироги, и каравай! Прошу к столу. И ты колобок садись. Мы тебя есть не станем! Я тебя лучше чаем угощу.

(дети садятся за стол)

**Старуха:** Ну вот, все хорошо, колобок с друзьями до Настеньки дошел. Я желаю внучке Настеньке, да и всем вам здоровья. Чтобы вы росли послушными, умными детьми.

А эту посуду мне пора отнести обратно в чулан. Пусть и другие ребятки, кто приходит ко мне в гости, знают, как нужно пользоваться этой старинной посудой.

**Исламгулова Д.И.**

**2 категорияле**

**физкультура**

**җитәкчесе..**

## «Камыр батыр” әкияте буенча эшләнелгән физкультура шөгыле.

**Максат**: Балаларны халкыбызның гасырлардан килгән зирәк акылы,моңлы күңеле,җор теле тудырган иҗат җәүһәрләре ,матур гореф-гадәтләре белән таныштыру.балаларны рухи яктан бай,физик яктан сау-сәламәт булып үсүенә зур әһәмият бирү.Уеннар аша балаларда җитезлек,өлгерлек,түземлек,чыдамлык,туган телгә,туган илгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Дәрес эшкәртмәсе:**

Зал матур итеп бизәлгән.авыл өе күренеше.Балалар тавышы ишетелә.

Кыз: Дусларым,әйдәгез уйныйбыз.

Малай: Нинди уен уйныйбыз соң?

Балалар:”Ал кирәк,гөл кирәк” уенын.

“ Ал кирәк,гөл кирәк” уены.

( Балалар ике төркемгә бүленәләр.бер якта-кызлар, икенче яктан-малайлар.Кулга-кул тотынышып басалар.Уенны малайлар башлый:

Ал кирәк,гөл кирәк
Безгә матур кыз кирәк.
Сәгатендә,минутында
Килеп китсен.....(исем)

Чакырылган кыз йөгереп килеп балаларның кулларын “ өзеп”чыкмакчы була.”Өзә”алса үзе белән иптәш алып китә,ә “ өзә”алмаса үзе шунда кала.Уен дәвам итә)

Кыз: Әйдәгез,хәзер “ Почмак алыш” уйныйк.

“ Почмак алыш” уены.

(Балалар залның төрле урыннарында басып торалар.Алар “ Әбиләр”.Бер бала әбиләр янына килеп,мунча сорап йөри:

-Әби,мунча бир әле?

-Мунчам буш түгел әле.

-Әби,мунча бир әле?

-Ташы төшкән.

-Әби,мунча бир әле?

-Мунча салырга агач юк.

Аннары тиз генә “ һап,һап!”дип берничә мәртәбә кычкыралар, вакытта балалар урыннарын алмашалар.Мунча сораучы бала шул арада бер баланың урынын алып өлгерергә тиеш,кем урынсыз кала,шул уенны дәвам итә.)

Кыз: дусларым,ярый инде,өйгә кайтырга вакыт.( Өй янында әби белән бабай боегып утыралар)

Әби: Нинди күңелле итеп уйныйлар. Булмады шул бер улыбыз яки кызыбыз. Мин аны алларыма утыртып яратыр ,сөяр идем. Карт,карт,сиңә әйтәм, әллә камырдан берәр бәби ясыйбызмы соң?

Бабай: Әй,юк сүз сөйләмәсәнә,картаеп беткәч нинди бала ди инде ул. Мин суга барып кайтыйм әле.( Бабай чиләкләрен тотып чыгып китә)

Әби: Ул нәрсә дисәдә дисен, ә мин барыбер камырдан берәр бала әвәлим әле.

( Әби камыр баса, бала сыны ясый.Әби камыр басканда музейдан алынган җиһазлар белән куллана, исемнәрен аерып әйтә Бала сыны килеп чыга)

Әби: Син минем иң акыллым,уңганым,матурым булырсыә.Кара нинди матур килеп чыкты.Син инде,улым,ятып тор,мин сыерымны гына савып керим әле.

( Әби чыгып китә.Камыр Батыр урыныннан сикереп төшеп уйный башлый. Әби сыер савып өйгә керә.баланы күреп чиләген төшереп җибәрә.)

Әби: Нәрсә бу? Үз күзләремә үзем ышанмыйм.Бу бит минем улым-Камыр - Батырым.( Әби малайны ашата,эчертә)Улым,әйдә,мин сине үзебезнең авыл малайлары белән таныштырам.Балалар,килегез әле,таныш булыгыз,бу минем улым Камыр-Батыр.Дус булыгыз,тату уйнагыз.Әйдәгез әле,мин сезгә бер борынгы татар халык уены өйрәтәм,ул

“ Бүкән” дип атала.

Уен “ Бүкән”

Балалар парлашып түгәрәк ясыйлар.Берәүләре алга,икенчеләре алар артына басалар.Алдагы балалар чүгәлиләр,алар “ бүкән” булалар, Ә артта басып торучылар “ бүкәнне саклаучылар” .Бер бала парсыз кала.Ул сакчы алдына килеп сүз башлый:

-Җиз бүкән сатлык микән?

Сатып бирмәссез микән?

Сакчы:

-Җиз бүкәннеме сатам,

Узышып карыйк алдан.

Алар түгәрәк буйлап икесе ике якка йөгереп китәләр.Кем беренче булып килеп җитә,бүкән аныкы була.Парсыз калган бала икенче сакчы янына барып сөйләшә башлый.

Әби: Әйдә,улым,өйгә кайтыйк.

Камыр-Батыр: Әти-әни,минем бераз дусларым белән урамда уйныйсы килә.Рөхсәт итәсезме?

Әби: Ярый,бәбкәм.Ләкин иптәшләреңне рәнҗетмә.Кал,уйна.

Малайлар: Әйдәгез,көрәшәбез.

(Малайлар сөлге тотып көрәшә башлыйлар.Камыр-батыр елата,аннан икенчесен,

өченчесен...Алар әби янына эләкләргә йөгерәләр)

Малайлар:Әби,сезнең улыгыә минем кулымны авырттырды..Ә минем аягымны авырттырды.

Әби:Улым,нишләвең бу,шулай ярыймени?

Камыр-Батыр: Алар җебегән,пешмәгән булганга мин гаеплемени?Чебен тисә,чер итәләр бит алар.

Әби: Алай ярамый,улым,көн саен сиңа зарланалар.Әллә булмаса дөнья гизәргә чыгасызмы,улым. Кешеләр белән аралашырга,үз-үзеңне тотарга өйрәнеп кайтырсың.

Камыр-Батыр: мин риза.Әзерлә,әнием,миңа төенчек.

(Ул урамга чыга,аны балалар уратып алалар) Дусларым, минем Алабуганы карыйсым килә.Үзенең 1000 еллыгына ул бик үзгәргән,матурланган диләр.Әйдәгез,бергә сәяхәткә.

(Юлда төрле сынаулар үтәләр)

“ Аякларны ныгытабыз”

-Бер-бер артлы аяк очларында һәм үкчәләрдә йөрү.

“ Танай урманында”

-Агач төпләрен атлап йөриләр.(тезләрне биек итеп күтәреп атлау)

-Агач ботакларын як-якка аралап узабыз(кулларны як-якка сузалар)

-Агач ботаклары астыннан атлау.(ярымчүгәләп атлау)

-Урман сукмагыннан йөрү.

Сулыш алу-чыгару күнегүләре:

-Җилкәләрне күтәреп төшерәбез.

-Башны уңга,сулга борабаз.

Алып баручы: Бик озак юллар уздык.Ардыгызмы балалар? Әйдәгез,бераз ял итеп алыйк.

” Башмакчы”дигән уен уйнап алабызмы?

“ Башмакчы”уены.

Алып баручы: Ярар,әйдәгез,балалар авылга,өйгә кайтыйк,әнә алда авылыбыз күренә.

Камыр-Батыр: Исәнмесез,әтием-әнием.Мин сезне бик сагындым.

Әби: И,улым,кайттыгызмы? Арыдыгызмы? Ниләр күрдегез? Кая,кая тикшереп карыйм әле күргәннәрегезне-белгәннәрегезме?Тыңлагыз әле минем табышмакларымны.

Ургып чыгып җир астыннан
Биешәләр тамчылар.
Төрле төсләрдә үзләре
Күргән кеше таң калыр.(Фонтан)
-Манарадагы алтын ай
Нурларын сибеп балкый.
Мөселман абзый-агалар
Шушында дога укый.(Мәчет)
-Бу бинаны сөйлиләр
Төзегәннәр дип бер төндә.
Ерак гасырлардан безгә
Ул мирас булып килә.( Ак мәчет)
-Күп бәйрәмнәр монда уза,
Ә Сабантуй-иң зуры.
Монда халык,уен,шау-шу,
Монда күге хозури.(Мәйдан)
-Чыккан ул Тойма буена
Табигатькә соклана.
Күргәнен ясап та куя,
Кулына алып пумала. ( Шишкин һәйкәле)

Әби: Әфәрин,балалар.Шәһәребез турында бик күп нәрсәләр беләсез.Минем улымны,Камыр-батырны да күпкә өйрәткәнсез.Шәһәребезне яратыгыз,саклагыз, дус-тату яшәгез.

Сезгә-бәхетнең зурысын,
Таңнарның яктысын.
Җәйләрнең ямьлесен,
Дусларның тугрысын телибез.

Бабай:

Ак бәхетләр юлдаш булсын сезгә,
Күтәренке булсын күңелегез,
Саулык,бәхет,куанычта гына,
Гөрләп үтсен бөтен юлларыгыз.

**Сибәгатуллина Р.И.**

**1 категорияле логопед.**

**Тема: [С], [С'] авазлары (өлкән логопед төркеме)**

**Максат**: [С], [С'] авазларының дөрес әйтелешен, сүз иҗеге турында белешмәләрен ныгыту. Бу авазларны аера, сүзләдә таба белергә өйрәтүне дәвам итү.Туган телгә, халкыбызның үткәненә ихтирам тәрбияләү.

Җиһазлау: “Өй” экспозициясе экспонатлары.

**Шөгыль барышы.**

1.Оештыру өлеше:

- Балалар, бүген без шөгылебезне бакчабызның Туганякны өйрәнү музеенда үткәрәчәкбез. Бу өйдә әби-безнең дәү әниебез яши. Ул үзе әле өйдә юк, оныкларына кунакка киткәндер.

Йортка кергәч, һәрвакыт исәнләшәләр . Без дә исәнләшик әле. Рәхим итегеә эскәмияләргә утырыгыз.

2. [С],[С'] авзлары турында сөйләшү.

а) Ә хәзер балалар, Игътибар белән тыңлагыз,
Безгә нинди авазлар кирәк.
Шул турыда уйлагыз.

Дәү әниебез бик бай,
Оныклары бик күп лә:
С̲ара, С̲әлим, С̲әлимә,
С̲алих, С̲аймә, С̲авилә.

б) Артикуляциясе искә төшерелә.

[С] авазы – кыен аваз,
Яши ул бик күп сүздә.

Аны дөрес әйтү өчен

Тел тештән чыкмый бер дә.

Яши ул каз ысылдавында,

Яши ул су тавышында.

Аны әйткән вакытта

Тел тора аскы теш артында.

- Әйдәгез, искә төшерик әле: каз ничек ысылдый? Краннан су ничек ага? Краннан су каты ага, акрын ага.

в) “[С] авазын тап”

- Әбинең өендә [С] авазы кайсы әйберләрнең исемнәрендә бар? Башта күзләр белән, анан соң бармаклар белән күрсәтегез.Соңыннан ул әйберләрне атарбыз һәм янына барып күрсәтербез.

Әйе, сандык, сөлге, өстәл, сәгать, тастымал, самавар, шикәр савыты, эскәмия, стена.

- Ә мондый агач караватлар (башсыз) сәке дип аталган. (Сүзне аерым-аерым һәм бергәләп әйтү.)

- Карагыз әле, стенага рам белән нәрсәләр эленгән?

- Аларны без “фото” дип кенә атамыбыз, алар – фоторәсем, фотосүрәт. Әйдәгез сүзләрне бергәләп һәм аерым-аерым әйтәбез.

г) Уен “Иҗекне чәбәклә” (басып).

д) Уен “Аваз кайда яши?” (сүзләрдә [С] авазларның урынын билгеләү: сүз башында , сүз уртасында , сүз азагында.)

е) Уен “Калын – нечкә” (кайсы сүзләдә [С] , кайсы сүзләдә [С'] авазы икәнен билгеләү.)

ж) Уен “Искә төшер”

- Без әби оныкларына кунакка киткәндер дидек. Әйдәгез аларның исемнәрен искә төшерик әле.

з) Уен “Җөмлә төзе”. Терәк сүзләр: сәгать, сандык, сөлге.

3. Йомгаклау.

а) Сораулар бирү:

- Без бүген , нинди авазлар турында сөйләштек?

- Ул авазлар әбинең өендә нинди сүзләрдә яши?

б) Уен “Табышмак әйтәм- җавабын тап”.

- Эчендә, су да бар, ут та бар,

Ул үзе һәр йортта бар? (Самавар)

(Вакыт калса табышмакны өйрәнергә дә мөмкин)

в) Бүләкләр.

- Әби сезгә бүләкләр дә әзерләп куйган. Бу нәрсә силуэты? Төркемегезгә кайткач, самаварны матур итеп төсле каләмнәр белән буярсыз.

**Козлова С.А.**

**1 категорияле рус теле тәрбиячесе.**

**Тема: Беседа о народах Поволжья.**

**Цель:** дать детям сведения о родном крае, о народах Поволжья (Мордовии,Чувашии,
Татарстан); воспитывать дружеские отношения к людям разных национальностей. Развивать речь, любознательность.

Словарная работа: Поволжье,Республика,чуваш,удмурты,национальность.

Наглядность: иллюстрации, национальные костюмы с музея, карта Татарстана; куклы,игры.

**Ход занятия:**

1.Организационный момент: Садится тот,кто назовет национальность .

2.Беседа о народах Поволжья.

-Как называется республика,в котором мы живем?

-Какие народы живут в нашей республике?

-Каких национальностей дети ходят к нам в детский сад?

-Почему наш край называется Поволжье?

-Что вы знаете о реке Волга?

3. Рассказ воспитателя о Татарской,Чувашской,Мордовской республике с показом иллюсрации.демонстрацией национальной одежды .

4.Мордовская народная игра “ Раю-раю”.

“ Раю-раю пропускаю, а последних оставляю.

Сама мать пройдет и детей проведет».

5.Дидактическая игра « Подбери костюм».

Дети подбирают татарскую,мордовскую,чувашскую национальную одежду для куклы.

6.Заучивание пословиц:

« Дружба и братство дороже богатства»

«С другом жить – нигде не тужить».

7.Обощение занятия:

-О чем говорили на занятии? Какаие национальности живут в Елабуге

## Дидактик уеннар эшкәртмәләре.

**1.Дидактик уен “ Савыт-сабаны җый”. ( 5-6 яшь)**

**Максат:** татар халык орнаменты белән таныштыруны дәвам итү:лалә чәчәге, тукранбаш,яфрак мотивлары белүләрен ныгыту. Сүзлек запасын баету - чүлмәк,чынаяк, чәй тәлинкәсе,савыт-саба.Киселгән вак өлешләрдән бер бөтенне җыярга ярдәм итү.Балаларда милли сәнгать белән кызыксыну уяту.

**Уен барышы**: Балалар,күрегез әле,Гөлчәчәк ялгыш савыт-сабаларын төшереп ваткан.Хәзер нишләргә инде аңа? Нишләп була? (Балалар үзләренең

фикерләрен белдерәләр, ярдәм итәбез,вак өлешләрдән савыт-саба җыябыз).Балалар савыт-сабаның исемен һәм орнамент мотивларын кабатлыйлар.

**2. Дидактик уен “ Дәвамы ничек?”. (6-7 яшь).**

**Максат:** Балаларны ак чәчәк,дәлия,кыңгырау, канәфер, тукранбаш чәчәге белән таныштыруны дәвам итү.Балаларга эстетик тәрбия бирү,татар милли сәнгатенә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

**Уен барышы :**

Балаларга өйрәнгән чәчәкләрнең ярты силуэты тәгьдим ителә.Балалар орнаментны искә төшереп чәчәкне ясап бетерергә тиеш.

**3.Дидактик уен “ Сүзләр дә атлап йөриләр”.**

**Максат:** музейда саклаңган җиһазларның исемнәрен дөрес итеп әйтергә һәм сүзләрне иҗекләргә бүләргә өйрәтү. Татар милли костюмына һәм борынгы көнкүреш әйберләренә кызыксыну уяту.

**Уен барышы**: Тәрбияче “йон” сүзен атый һәм балаларга аның бер иҗектән торуын,шуңа күрә бер генә адым атларга һәм сүзне дөрес итеп әйтергә кирәклеген әйтә.Шулай ук калфак,читек,сөлге,сандык,каба ,алка ... сүзләренең –ике, түбәтәй,кульяулык,альяпкыч ,беләзек сүзләренең өч иҗектән торуын аңлата.Балалар шул сүзләрне дөрес итеп ,иҗекләр санынча адым ясыйлар.
Шулай ук 4-5 иҗекле сүзләр белән уен оештырыла.

**4.Дидактик уен “Бизәнү әйберләре төзе”.**

**Максат:** татар халык бизәнү әйберләре ( алка, беләзек, муенса, сәйлән) белән танышу; аларны үрнәкләргә карап ,үз фантазияңа таянып,хәтер буенча төзү. Балаларга эстетк тәрбия бирү,татар халкының милли киемнәренә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Уен барышы**: - үрнәк буенча төзү.

-әзер элементлардан иҗади төзү.

- хәтер буенча төзү

-кет тизрәк?

**5.Дидактик уен “ Милли киемнәргә бизәк төзе”**

**Максат:** халкыбызның мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итү, милли киемнәр темасына сүзлек запасын баету( камзол,читек,түбәтәй,альяпкыч); 2-3 сүздән торган җөмлә төзергз өйрәтү. Халкыбызның милли мәдәниятенә мәхәббәт, эстетк зәвык тәрбиясе бирү.

**Уен барышы**: Тәрбияче: Балалар,бу серле тартмада милли киемнәрдән бизәкләр сибелгәннәр.Аларны җыярга миңа ярдәм итмәрсез микән? ( уен барышында киемнең исемнәре кабатлана,шулай ук нәрсә эшләгәне тулы җөмлә белән аңлатыла.)

**6.Дидактик уен “ Көйне таны”**

**Максат:** Бию көе төрләрен ( полька,вальс,татар халык биюе),җыр һәм маршларны аера, әсәрнең өлешләрен ( кереш өлеш,тәмамлау өлеше,җырның башы,кушымта) ишетә һәм аера белергә өйрәтү.Татар орнаментларына соклану, аларның исемнрен истә калдырырга ярдәм итү.

**Уен барышы:** Төрле бию көйләре, җыр һәм маршлар уйнала.балалар аларны дөрес итеп аерырга һәм атарга тиеш. Дөрес җавап биргән балалар татар орнаменты белән бүләкләнәләр.

**7.Дидактик уен “ Бу нәрсә?”**

**Максат:** балаларны кием-салым белән таныштыру; тану,күрсәтү,исемнәрен истә калдыру,кулланышын ачыклау.Балаларныҗ хәтерләрен, игьтибарларын үстерү; милли киемнәргә мәхәббәт,соклану хисләре тәрбияләү.

**Уен барышы:**

1 вариант- Тәрбияче кулына серле сандык,бергәләп ачалар.Сандык эчендәге киемнәрне берәм-берәм алып танышалар.Тәрбияче балага киемнең исемен әйтеп алып бирергә куша.Бергәләп кабатлыйлар,нәрсә өчен кирәклеген әйтәләр.

2 вариант- Киемнәрне алып, исемнәрен әйтеп курчакны киендерү.

**8.Дидактик уен “ Нәрсәдән ясалган?”**

**Максат:** Балаларга предметларның ясалуына карап төркемнәргә берләштерергә өйрәтү ( тимер, резина, агач, пыяла, пластмасс); сүзлек запасын активлаштыру,сөйләм телен үстерү; күзәтүчәнлек, игьтибарлык тәрбияләү.

**Уен барышы**: Балалар тәрбияче белән бергәләп музейда булган энспонатларны, җиһазларны карыйлар һәм төркемнәргә бүләләр.( агачтан ясалган җиһазлар...Тимердән ясалган җиһазлар...

**9. Дидактическая игра “ Кому что подарим?”**

**Цель:** дать детям понятия о том, какими предметами обихода пользовались в старину и пользуемся в наше время; закрепить знания о музейных экспонатах.

Обогащать словарный запас детей: деревянная ложка,маслобойка,серп, жерновка, кумган, керогаз.

**Ход игры**: Воспитатель выставляет на фланелеграфе фигурку бабушки ( с левой стороны), фигурку девочки ( с правой стороны).

## Этикеткалар.

**/Нәрсәгә дә булса ( мәсәлән, товарга, экспонатка)тагылган,беркетелгән,аларның исемнәре, сорты,бәясе,күрсәтелгән ярлык/**

### Калфак

Өч төрле булалар: борынгы зур калфаклар, уртача зурлыктагы калфаклар, кечкенә калфаклар. Зур калфаклар атластан, ефәктән яки бәрхеттән тегелә, бер очы артка таба салындырылып киелә.

Урта зурлыктагы калфак та шундый ук материядән тегелә, ләкин ул артка таба түгел, бәлки бер якка салындырылып киелә. Йөрергә чыкканда хатын-кызлар зур калфакның да, уртача зурлыктагының да өстеннән шәл бөркәнәләр.

Кечкенә калфак төрле төстәге бәрхеттән, манчестердан тегелә, энҗе ука алтыннар белән чигелгән бу калфакны күбрәк яшь хатыннар, кызлар кияләр, өстеннән юка яулык яки газовый шарф бөркәнәләр.

**Кәттәши.**

Кәттәши яки такыя түбәтәй кебек баш киеме, ләкин баш түбәләре түгәрәк түгел, ә яссы итеп тегелә.

Аны матур төстәге бәрхеттән, атластан, ефәктән кысасына катырып куеп тегәләр. Кәттәшиләр чигелмәгән шома гына булырга, энҗе белән, ука белән чигелгән булырга да мөмкин.

Кәттәши такыяны күбрәк яланбашка яки яулык өстеннән яшьләр, кызлар кия.

**Яулык**

Яулыклар юка материядән, бизәкле дә, бер генә төсле дә була. Кызлар, яшь хатыннар яулыкларын калфаклап, артка чөеп (битнең түбән өлешен иякләрне ачык калдырып) бәйлиләр. Ә өлкән яшьтәге хатыннар артка чөеп түгел, бәлки яулыкның ике почмагын ияк астыннан төйнәп бәйлиләр. Йөрергә чыкканда, хатын кызлар яулык өстеннән чуклы матур ефәк шәл бөркәнәләр.

**Изү.**

Татар хатын-кызларының изү яисә күкрәкчә дип аталган бизәнү әйберсе безнең өчен бераз ят булып тоелыр. Көрәк сыман формадагы мондый күкрәкчәләр күлмәкнең ачык изүен каплап торган. Күкрәкчәне укалы тасма,ефәк,төрле-төрле вак тәңкәләр ,йомры төймә,мәрҗән ,асылташлар белән бизәп ,тыгыз киндер тукымалардан ясаганнар. Әлеге бизәкләр ,изү озынлыгына

карап,икешәр-өчәр рәт итеп тегелгән. Гәрчә төрледән – төрле булсалар да, Казан хатын – кызларындагы изүләр бай бизәлеше белән башкалардан шактый нык аерылган. Мондый изүләр күлмәк якасыннан башлап бөтен күкрәкне каплап торган, аларны тасма белән муенга бәйләп куйганнар.Изүне кияүдәге хатын-кызларның барысы да кияргә тиеш булган.

XYIII гасырда XIX йөз башында күлмәкләрне ак киндердән теккәннәр һәм ачык изү тирәсен төсле җепләр белән чигеп бизәгәннәр.Тора-бара чуар ситсадан тегелгән күлмәкләр пәйдә булган. Чуар тукыманы чигеп булмый бит – күлмәк изүен төрле тасмалар белән бизи башлаганнар. Аннары инде әлеге изү – кхкрәкчәләр барлыкка килә.Безнең халыктан тыш, мондый изүләр бары бер халыкта гына – тугандаш Башкортстанда гына очрый.

**Күлмәк**

Хатын-кызлар күлмәге күп төрле материядән: ситсы, ефәк, йон, поклин һәм хәтта парчадан тегелергә мөмкин. Авылча күлмәкләр бизәкле материядән, ә шәһәрчәләр, күбесенчә, чуар булмаган бертөсле материядән тегелә. Озынлыгы аяк йөзенә кадәр җитә һәм итәгенә берничә бала итәкләр тотыла. Борынгы заман биюләре өчен күлмәк бик озын итеп, ә хәзерге заман биюләре өчен кыскарак итеп тегелә.

**Камзул**

Татар хатын-кызлары күлмәк өстеннән еш кына камзул кияләр. Камзулны күп төрле материядән: ефәктән, бәрхеттән, атластан, поплиннан һәм парчадан тегәләр. Камзулны күлмәк нинди материядән булса, шундый ук материядән итәк очларына, якаларына кыйммәтле мех тотып яки энҗеләр белән чигәргә була. Кызлар итәк очы билдән түбәнрәк булган кыска камзул, ә өлкәнрәк яшьтәгеләр озын, итәге тезгә җитеп торган камзул кия. Хатын-кызлар камзуллары күп вакытта төймәләнми, яки бер генә төймәгә эләктерелә, яки каптырма белән каптырыла.

**Альяпкыч**

Альяпкыч күбрәк авылча  киенгән вакытта кирәк. Олырак хатын-кызлар эш вакытында, ә яшь хатыннар һәм кызлар һәрвакыт, хәтта бәйрәм көннәрдә дә альяпкыч кияләр. Эштә кия торган альяпкычлар төрле төстәге материядән тегелә, кызлар күкрәк турысы һәм итәк очлары төрле төстәге җепләр белән чигелгән ал альяпкыч кияргә яраталар. Альяпкыч күбрәк канатлы итеп тегелә.

## Чулпы

Татар кызлары чәчләрен кечкенәдән чулпы тагып үрәләр. Чулпы һәр ике толымга да тагыла. Татар хатын-кызлары чәчләрен җиңелчә май белән белән майлап, туры ачып, шома итеп тарыйлар һәм ике толым итеп үрәләр, толым очларына чулпы тагалар. Татар кызлары чәчләрен кечкенәдән чулпы тагып үрәләр. Чулпы һәр ике толымга да тагыла һәм билдән түбәнрәк салынып тора. Чулпыны ювелир эшләренең осталары эшли, аның төрлесе  улла:  ул төрлеләре алтын йөгертелгән калайларга көмеш тәңкәләр тагып эшләнә, икенчеләре кыйммәтле ташлар беркетеп, унлап, егермеләп көмеш тәңкәләр тагылып ясала. Чулпы чәчнең шомалыгын, толымнарның артка җибәрелгән хәлен саклый һәм биегәндә матур итеп чыңлап тора.

## Беләзек

Беләзек чулпы кебек үк татар хатын-кызларының бизәнү әйберсе. Беләзекнең төрлесе: бронзадан, көмештән, алтыннан һәм башка металлардан ясалганнары  улла. Бик кыйммәтле ташлар белән бизәлгән беләзекләр дә  улла. Беләзекләрне  ул генә кулга да, ике кулга да кияләр, кайчакта һәр кулга да икешәр беләзек киючеләр дә  улла.

Бизәнү әйберләреннән яшь хатын-кызлар шулай ук алка, муенса тагарга, йөзекләр кияргә яраталар

## Алкаларым – асылташ.

Бай хатын-кызлар да, әллә ни бай булмаганнары да, бәйрәмнәрдә генә түгел,гадәти көннәрдә дә алка тагып йөргәннәр. Күп очракта алар без күрүгә

іяләшкән алкаларга охшамаганнар да әле.Борынгы заманда кайбер мәҗүси халыкларның алкалары түгәрәк булган һәм колакны бөтен килеш каплап торган, чөнки ул вакытта кешеләр үз башларындагы һәр тишекне, куышлыкны сакларга кирәк дип уйлаганнар. Имеш, авыз,колак,борын, күз аша явыз көчләр керергә яисә сәламәт көчләр чыгып китәргә мәмкин дип уйлаганнар. Алкалар бизәнү әйберләре булып та, хатын – кызларны явыз көчтән саклар өчен хезмәт иткән.

## Муенса.

Муенса – иң борынгы бизәнү әйберләреннән.Таш гасырларында аны ирләр дә, хатын – кызлар да тагып йөргән. Һәм ул, бизәнү кирәк-ярагы булудан бигрәк, бәла-казадан,яман чирләрдән саклау өчен тагылган. Иң борынгы муенсалар хайван тешләреннән , әкәм-төкәм кабыкчыкларыннан ясалган.

Мең еллар дәверендә муенсаларның формалары да үзгәргән.Тора-бара алар бары тик хатын-кыз бизәнү әйберләренә генә әйләнеп калган.

Казан татарларында муенса көндәлек бизәнү әйберсе саналган.Аны олысы-кечесе бердәй яратып таккан. Муенсаларның иң киң таралганы мәрҗәннәр. Бер яки берничә җепкә тезелгән энҗе,сәйләннәр, әлбәттә, кызларга бик килешкән. Еш кына аларга яка чылбыры да беркеткәннәр.Көмеш белән каймаланган эре асылташлар муенсаны бик затлы һәм матур күрсәткәннәр.Алар кояш нурларында җемелдәгәндә ,өйтерсең, хатын-кыз муенында төсле утлар кабынган.

XIX гасыр ахырында татар хатын-кызлары вак асылташлардан, чын һәм ясалма энҗедән , ак, кызыл,яшел,сары сәйләннәрдән, төсле пыялалардан тезелгән муенсаларны яратып такканар. Алар – бүген дә кызларыбызның аерылгысыз бизәге.

## Яка чылбыры.

Хатын-кызларның әлеге гадәттән тыш бизәнү әйберсе яка чылбыры (воротниковая застежка) дип атала. Бу чылбыр- асылмалы бизәкле прәшкә. Ул

бастырып тегелгән якаларга тагыла. Бизәнү әйберсе булу белән бергә, күлмәкне яка белән тоташтыру хезмәтен дә үтәгән.

Яка чылбырларының нинди төрләре очрамаган! Күлмәк якасы каптырмасында 2-3 асылма бизәк эленеп торса, димәк ул яшҗ кызларныкы. Әгәр инде бизәкләр саны күп булса ( кайчак ул 9 җиткән), әлеге яка чылбыры өлкән хатыннарныкы. Яка чылбыры, алкалардан аермалы буларак, бәйрәмнәрдә генә тагылган. Аны кунакка барганда, Коръән укыганда кигәннәр.

Иң эре чылбыры да үзләренең нәфислеге белән аерылып торган. Вак кына алтын,көмеш тамчылары челтәрләп эшләнгән нечкә тимерчыбыклар белән каймаланган. Алар зур ташлар белән аралашып, төрле төсләргә кереп ялтыраган. Монда инде оста куллы ювелирларның талантына,зәвыгына гына сокланасы кала.

Яка чылбыры-чын татар бизәнү әйбере. Аны иң башта болгар бабаларыбыз уйлап тапкан.

Киемнең фасоны үзгәргәч,аларны кирәксенми башлаганнар, шуңа күрә татар халкының әлеге борынгы бизәнү әйберсен бары тик Сынлы сәнгать музее күргәзмәләрендә генә күреп була.

## Хәситә

Хәситә камзул эченнән күлмәк өстеннән киелә. Хәситәне күбрәк өлкән яшьтәге татар хатыннары кияләр. Түшне бизи торган бу хаситә сул җилкә өстеннән уң култык астыннан җибәрелеп киелә һәм махсус эләктергеч белән эләктерелә. Хаситәнең төрлесе 30-35см. озынлыкта, 5-10 см киңлектәгеләре дә була. Ул болай тегелә: каты материяне төрле төстәге кыйммәтле ташлар, алтын, көмеш тәңкәләр белән бизиләр. Хәситәнең баш-башы нечкәреп килә һәм арка турысында каптырыла.

## Читек

Читек татарларның күн аяк киеме.Хатын-кызлар аякларына төрле төстәге нәфис күннән теккән матур итеп чигелгән читек кияләр.Читекләр яшел,

караңгы кызыл, зәңгәр һәм башка төстәге күннәрдән, ефәк җепләр белән чигелеп тегелә.

Кызлар һәм яшь хатыннар биек үкчәле, каты табанлы читек, ә өлкән яшьтәге хатыннар йомшак табанлы, тәбәнәк үкчәле читек яки читек өстеннән резин галошлар кияләр.Картлар кунычы тезгә җитеп торган.

## Башмак

Башмаклар матур төстәге берәр күннән һәм бәрхеттән тегелеп, алтын, көмеш җепләр белән чигелгән, энҗеләр, укалар белән белән бизәлгән була. Мондый башмакларны күбрәк шәһәр татарлары кия.

## Чигү

X1X гасырның икенче яртысында өйдә тукылганкиндерне акрынлап фабрика тукымалары алыштыра. Тукылган бизәкләр урынына кул белән чигү кулланышка керә. Баштарак кечкенә-кечкенә бизәкләрне генә тамбур белән чиккәннәр. Тора-бара, тамбур энәсе һәм киергеләр кулланыла башлагач, осталар урын-җир җәймәсе, тәрәзә пәрдәсе, намазлык, кашага кебек зур-зур әйберләрне дә чигәргә тотынганнар.

X1X гасырның 70 елларында Казан губернасының авыл һәм шәһәрендә Европа тамбур машинасы да күренгәли башлый. Хәлле гаиләдән чыккан кәләш бирнәләрендә дә шундый машиналар була. Машина белән чигү күпкә җиңелрәк һәм тизрәк, югыйсә, мондый бизәкләр дә кул белән чиккәннән бер дә аерылмый. Чигелгән әйберләр нәкъ шушы чорда базарга чыгарыла башлый, заказ белән эшләнә. Аеруча Казан сөлгеләре дан ала-алар бөтен Россиядә, Урта Азиядә, Себердә танылалар.

Татар чигүчеләре-чиратылган ефәк җепләр, баераклары-алтын һәм көмеш ука җепләр кулланып та чигәләр.Йөз еллар дәвамында төрле бәйрәмнәр, туйлар түрендә йөргәнгәме-чиккән сөлгеләрнең кадере элеккечә кимемәгән.

Башкарырга уңайлы һәм күрер күзгә күркәм булгангадыр, чигү сәнгате әле дә яши. Тамбур бизәкләре исә хатын-кыз күлмәкләре, блузкалары һәм яулыкларына аерым бер матурлык өстәп тора.

## Тәңкәләр.

Бүген без сезнең белән тагын бер ювелир әйберсе-тәңкәләр белән танышалар. Татарларда алар киң кулланылган һәм кайларда гына очрамаган! Алар яка чылбырына да, беләзекләргә дә, чулпыларга да, муенсаларга да куелган. Һәм бу тикмәгә генә түгел. Элекке заманнарда Казан татарларының борынгы бабалары тәңкәләрдә магик көч барлыгы турында әйткәннәр. Алар төрле бәхетсезлекләрдән, авырулардан саклый дигәннәр.

Тәңкәләр бер-берләренә охшашлар һәм шул ук вакытта гаҗәеп күп төрле. Алар түгәрәк тә, квадрат формасында да, ярымшар рәвешендә яки өчпочмаклы да, ромбик, йолдызчыклар сыман да …

Беришләрен оста бары тик металлдан ( гадәттә көмештән) генә ясаган. Икенчеләрен эреле-ваклы асылташлар белән бизәгән. Көмеш белән каймалаган асылташлар аеруча матур күренгән. Үтә күренмәле тау хрустале, зәңгәрсу-яшел аквамарин, шәмәхә аметист, кызгылт-көрән сердолик, ачык зәңгәр фирәзә-бу асылташларны осталар Уралдан кайтарткан.

## Кәзәки.

Кәзәки шәһәрдә яшәүче татарларның тышкы киеме. Кәзәки күбрәк караңгырак төстәге материядән тегелә. Кәзәки тегелеше белән озын камзулга ошый, ләкин кәзәки җиңел була һәм итәге бик нык клешланып тормый. Кәзәкинең якасы утыртма итеп тегелә. Кәзәки сул якка каптырыла, өч кесәле итеп тегелә: ике кесә як-яктан өченчесе сәгатҗ яки карандаш салыр өчен күкрәктә була.

## Билбау.

Билбауны , гадәттә эш киеме өстеннән буып кияләр. Ләкин яшҗләр бәйрәмчә киенгән чакта да билбау буалар. Билбауны төрле төстәге материядән 30-40 см. киңлектә тегәләр. Кайбер очракларда аннан да киңрәк билбаулар була. Билбауның буе 5м. җитә. Эш киемен буа торган билбаулар караңгы төстәге материядән була. Мондый билбауны билгә очларын яшереп буалар, ә инде очы чуклы булса, билбауның ике очын як-яктан асылындырып төшерәләр.

### Түбәтәй.

Түбәтәй татарлар өчен иң хас баш киеме.Түбәтәй төрле төсләрдә булырга мөмкин, ләкин күп вакыт ул артык ачык булмаган караңгырак төсләрдәге бәрхеттән һәм башка шундый материядән тегелә.

Үзенең формасы, катылыгы белән түбәтәй берничә төрле була. Элек шәһәрдә яшәүче баерак татарлар бәрхеттән ефәк тотып тегелгән, алтын-көмеш укалар белән бизәлгән түбәтәйләр кигәннәр.

Түбәтәйнең энҗе, мәрҗән , алтын һәм көмеш белән чигешләре чәчәкне хәтерләтә. Чуклы түбәтәйләр дә була. Чуклы түбәтәйләрне күбрәк яшүсмерләр кия.

### Эшләпә.

Авыл татарлары җәйге кояштан саклану өчен киез эшләпә кияләр. Мондый киез эшләпәнең читләре төшебрәк тора, түбәсе түгәрәк була.

### Чалбар.

Чалбар караңгы төстәге йон яки башка төрле материядән тегелә. Татарлар артык киң чалбар кимиләр. Элекке заманда ярлылар буй-буй итеп өйдә тукыган киндердән тегелгән чалбарлар кигәннәр. Туйларда кия торган чалбарлар кыйммәтле материядән тегелгән.

### Хатын – кызларның шәһәрчә киеме.

Хатын –кызлар шәһәрчә биегәндә берничә бала итәкле ачык төстәге ефәк,атлас яки поплин материядән тегелгән озын күлмәк кияләр.Күлмәкнең җиңнәре озын, ә җиң очлары киң итеп  һәм бала итәк тотып тегелгән, якасы утыртма яка була. Күлмәк  өстеннән караңгы төстәге һәм тыгыз материядән тегелгән ука, мех тотылган яки энҗе белән чигелгән камзул кияләр. кызлар чәчләрен ике толым итеп үрәләр, һәр ике толымга да чулпылар тагалар. Башка калфак кияләр.

Кызлар аяклары артык биек булмаган үкчәле каюлы читекләр кияләр.

**Хатын – кызларның авылча киеме.**

Хатын – кызлар авылча биегәндә берничә бала итәкле озын күлмәк кияләр. Күлмәк чуар , вак бизәкле  яки бер генә төрле ситсыдан, штапельдән , ефәктән һәм башка материядән тегелә. Кайбер биюләрдә  төсе ачык төстәге күлмәк, ә кайберләрендә тоныграк төстәге күлмәк кияләр. Авылча күлмәкнең җиңнәре озын һәм якасы утыртма була. Күлмәк өстеннән милли чигешләр белән чигелгән канатлы ак альяпкыч кияләр.

Чәчләр ике толым итеп үрелә, чулпылар тагыла. Башка ике яулык бәйләнә. Беренчесе артка таба чөеп бәйләнә, ә икенчесе анның өстенә булавка белән эләктерелеп куела.Кызлар аякларына артык биек булмаган үкчәле каюлы читекләр кияләр.

**Ирләрнең шәһәрчә киеме.**

Ирләр ак,зәңгәр,яшел,сары,сирәк кенә кызыл ,ал материядән тегелгән туры якалы күлмәк, караңгы төстәге чалбар, кара  ярымботинка яки чигүле итекләр кияләр.

Ирләрнең камзул – кәзәкие караңгы материядән тегелгән, ә түбәтәйләре кара яки башка берәр төстә чигелгән һәм чигелмәнән гади генә була.

**Ирләнең авылча киеме.**

Күлмәк ачык төстәге материядән киң итеп тегелгән, туры якалы була.Күлмәк өстеннән кызыл яки башка төстәге билбау буыла. Билбауның ике очы ике яктан салындырып куела.

Авылча биегәндә егетләр киң чалбар, кара яки ачык төстәге чигүле читек кияләр. Камзул күп вакытта кара төстә була, озын җиңле яки кыска җиңле итеп тегелә. Түбәтәй кара яки башка төстә чигелгән һәм чигелмәгән була.

**Файдаланылган әдәбият:**


1.Борһанова Р.А. Туган як табигате белән таныштыру. Балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен кулланма.-Казан : Хәтер,1997.

2. Борһанова Р.А. Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру программасы.-Казан: Хәтер, 1997.

3.Балалар бакчаларында тәрбия һәм укыту программасы. /Төзүчеләр:КВ.Закирова, Р.А.Борһанова/ Казан:Хәтер, 2000.

4. Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары.-Казан: Татар.кит.нәшр.,1995.

5..Гильфанова Н.С. Татар сынлы сәнгате.-Казан: Татар.кит.нәшр., 1999.-6-9б.

6. Закирова К.В. Уйный – уйный үсәбез.- Казан: Мәгариф, 2005.

7. Закирова К.В.,Гаффарова С.М. Әткәм-әнкәмнең теле.-Казан: Мәгариф,1997.

8.Закирова К.В.,Низамов Р.А.Гаиләдә, балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы.- Казан : Мәгариф, 1997.

9.Закирова К.В., Низамов Р.А., Кадыйрова Р.Ә. Гаиләдә һәм балалар бакчаларында әхлак тәрбиясе.- Казан: Мәгариф, 1999.
10. Исмәгыйлова С.Г. Гәлбакчада туган тел. Балалар бакчасында эшләүчеләр өчен тәкъдимнәр, материаллар.-Алабуга, 1997.
11.Крутына Н. На пути к музею.// Дошкольное воспитание.-2002.- № 5.-с. 13-22.
12. Казыйханов В.С. Әхлак дәресләре. -Яр Чаллы: Иҗат,1997.
13. Казыйханов В.С. Әхлак дәресләре. Укытучылар , сыйныф җитәкчеләре һәм тәрбиячеләр өчен дәрес эшкәртмәләре.-Чаллы: Өзлексез педагогик белем бирү институтуы, 1998.
14. Карачунская Т.Н. Музейная педагогика и изобразительная деятельность в ДОУ. Интегрированные занятия.-Моска: Творческий центр, 2005.
15.Мой родной дом.Программа нравственно-патриотического воспитания дошкольников.
/Редактор-составитель: Арапова-Пискарева Н.А./ Москва: “Мозайка-Синтез”, 2004.
16.Муравьева Г. Музейная педагогика.// Мәгариф.-2005.-№ 8.-с.52.
17. Морозова С.,Соловьева Е.,Трунова М.. Музейная педагогика.//Ребенок в детском саду .-2007.-№2-5.-с.78-84
18. Рыбалова И. Ознакомление с родным городом как средство патриотического воспитания.// Дошкольное воспитание.-2003.-№ 6 –с.45-57.
19.Сенновская И..Дошкольники и музей. // Дошкольное воспитание.-2002.- № 5.-с.98-101.
20.Тиханчикова Т.,Симбирева Д. Музейная педагогика.// Ребенок в детском саду.-2006.- №4.-с.69-72.
21..Шәймарданов Р.Х., Сибагатуллина Ә.Т., Сибагатуллин Р.Г. Татар халык педагогикасы.- Чаллы, 1997.
22..Әхмәтҗанова Р.К. Матурлык иленә сәяхәт.- Казан: Мәгариф, 2001.

## Эчтәлек.

Балаларның танып-белү эшчәнлеген һәм әхлак – патриотик сыйфатларын үстерүдә
музей педагогикасының роле..........................................................................................2
Тәрбия – укыту процессында төп чаралар...................................................................4-6
Тематик-экспозицион план.............................................................................................7
Перспектив план..........................................................................................................8-11
Балаларның белемнәрен тикшерү.............................................................................12-13
Шөгыльләр эшкәртмәләре....
1нче бүлек- сөйләм үстерү шөгыльләре......................................................................14-35
2нче бүлек – сынлы сәнгать шөгыльләре
......................................................................35-40

3нче бүлек – бәйрәмнәр,күңел ачу кичәләре.................................................................40-52
4нче бүлек –комплекслы шөгыльләр.........................................................................52-72
Дидактик уеннар...............................................................................................................72-73
Этикеткалар.................................................................................................................................74-78
Файдаланылган әдәбият...........................................................................................79
Эчтәлек………………………………………………………………………………… ..80